Җ.Г. ЗӘЙНУЛЛИН

# Шәрык алынмалары сүзлеге

Җ.Г. ЗӘЙНУЛЛИН

# Шәрык алынмалары сүзлеге

КАЗАН • «МӘГАРИФ» • 1994

ББК 4*81.2 Гар.+Фарс.
З87

*Бу китапны чыгаруда*
*күрсәткән ярдәме өчен*
*«Актай» предприятиесенә*
*(директоры Г.М.Зыятдинов)*
*рәхмәт белдерәбез.*

**Җ. Г. Зәйнуллин**

З87 Шәрык алынмалары сүзлеге. — Казан: Мәгариф, 1994. — 143 б.
ISBN 5-7761-0243-х

З $\frac{4602030000-080}{П\ 86(03)-94}$ БЗ—61—97—94 ББК 4*81.2 Гар.+Фарс.

ISBN 5-7761-0243-х

©"Мәгариф", 1994

# ТӨЗҮЧЕДӘН

Татар әдәбиятының борынгы мирасы бик бай. Кызганычка каршы, бу мәдәни байлыкның күпчелек өлеше һаман да кулъязма хәлендә кала бирә. Шуңа күрә әдәби ядкярләребез белән киң катлам укучылар танышудан мәхрүм булып киләләр. Соңгы елларда бу өлкәдә сизелерлек хәрәкәт башланды дияргә була. Тарихыбызга, мәдәниятебезгә кагылышлы әсәрләр газета-журналларда да, аерым китап булып та басыла башлады.

Әдәби, тарихи ядкярләребезнең теле шактый чуар, белгеч булмаган кешегә аларны уку кыенга туры килә, ә вакыты белән аңлашылмый да. Аңлауны гарәп, фарсы һәм башка телләрдән үтеп кергән алынмаларның күп булуы кыенлаштыра. Димәк, моның өчен махсус сүзлек кирәк була.

Көндәлек матбугат сәхифәләрендә элегрәк ана телебездә актив кулланылып та, соңрак хаксызга кысрыклап гамәлдән чыгарылган матур һәм колакка ятышлы сүзләр торган саен күбрәк күзгә чалына башлады. Күп гасырлар элек сәяси, икътисади, гыйльми бәйләнешләр нәтиҗәсендә ана телебезгә үтеп кергән алынмаларның яңадан кайтарылуы, аларга яңа тормыш бирелүе күңелләрдә өмет уята.

Ниһаять, тарихи язуыбызга игътибар бирелә башлады. Мәктәпләрдә иске татар язуы укытыла. Укыту процессында файдалану һәм мөстәкыйль рәвештә мәдәниятебез, халкыбызның тарихы белән кызыксынучылар өчен дә сүзлекләрнең җитешмәве үзен сиздерә. Менә шуларны исәпкә алып төзелгән җыйнак кына бу сүзлекнең мәктәп укучыларына, студентларга һәм иске язуыбызны үзләштерүчеләргә ярдәме тияр дип уйлыйбыз.

Сүзлектәге алынмалар егерменче гасыр башында дөнья күргән татар телендәге газета-журналларыбыздан, әдәби-тарихи, сәяси эчтәлекле китаплардан һәм бүгенге вакытлы матбугат сәхифәләреннән сайлап алынды. Билгеле бер күләмдә ялгызлык исемнәренә һәм аларның мәгънәләренә дә урын бирелде.

Сүзлекне төзегәндә С. Җантуринның "Лөгать" исемле гарәпчә-фарсыча-татарча сүзлеге нигез итеп алынды (Уфа, 1911). Шулай ук бүгенге көндә мәгълүм булган Таһир Ильясиның, "Әл-мөфид" дигән гарәпчә-татарча сүзлеге (Казан, ...); Гарәп теленең энциклопедик сүзлеге "Әлмүнҗид" (Бәйрут, 1960); "Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге" (Казан, 1965); Ю. А. Рубинчикның "Фарсыча-русча сүзлеге" (Мәскәү, 1974); Х. К. Барановның "Гарәпчә-русча сүзлеге" (Мәскәү, 1977); М. А. Гаффаровның "Фарсыча-русча сүзлеге" (Мәскәү, 1977) һ. б. сүзлекләр файдаланылды.

## Сүзлекнең төзелешенә караган аңлатмалар

Сул якта алынма сүзнең хәзерге татарча шәкеле бирелде. Шартлы кыскартулар кулланылды: *г.* — гарәп теленнән алынган сүз; *ф.* — фарсы теленнән алынган сүз; *төрк.* — төрки сүз. Җәяләр эчендә алынма сүзнең гарәп телендәге тамыры — "оясы" бирелде. Бу гарәп алынмаларына гына карый. Гарәпчә сүзлекләрдә тамыр сүзләр "оя" белән бирелә. Аларның нигезендә тамыр сүзнең төп мәгънәсе сакланса да, билгеле бер кагыйдәгә нигезләнеп, ул "ояларның" эчке структуралары үзгәртелә һәм күптөрле өр-яңа сүзләр ясала.

Гарәп сүзлегеннән теге яки бу сүзне эзләп табу өчен, элек аның нигезендә яткан тамыр сүзне белү зарури. Бу җиңел түгел. Моның өчен күпмедер дәрәҗәдә гарәп теле грамматикасын белү кирәк. Шуны күздә тотып, әлеге сүзлеккә кергән кайбер гарәп алынмаларының янәшәсенә аларның нигезләрен, "ояларын" да биреп бару ярашлы дип табылды. Мондый тәртипне куллану, иң беренче чиратта, гарәп теленнән мәгълүматы булмаган укучы өчен уңайлы булыр, гарәпчә сүзлекләрдән ансат кына кирәкле сүзләрнең тамырларын табарга һәм алардан ясалган күп сүзләрнең мәгънәләрен белергә ярдәм итәр дип уйлыйбыз.

# А

Тарихи язуыбызда «Әлиф» хәрефе «А, Ә, У, Ү, О, Ө, И, Ы» хәрефләрен ясаганда да катнашкан. Шуңа күрә бу үзенчәлекләрне игътибар белән өйрәнү сорала. Махсус дәреслекләрдә андый үзенчәлекләр турында шактый гына тәфсилле итеп язылган.

**Аб** *г.* Август ае.
**Абе раван** *ф.* Агым су.
**Аба** *г.* Йон тукымадан тегелгән хатын-кызлар күлмәге. (Мондый күлмәкне шигый мәзһәбендә булган хатын-кызлар урамга чыкканда, яисә, өй эчендә ят кешеләр булганда гына кияләр. Мәсәлән, Иранда, Гыйракта, Әфганстанда, Бахрейнда һәм тагын башка берничә илдә.)
**Абруй** *ф.* Абруй, кадер-хөрмәт, йөз суы, дәрәҗә.
**Абелхәят** *ф. г.* Тереклек суы, тормыш чыганагы.
**Абунә** *ф.* Газета-журналларны яки башка берәр нәрсәне алдыру өчен алдан ук акча түләп яздырып кую.
**Абави** *г. кара:* әбәви.
**Абур-җубур** *төрк.* Бар нәрсәне бергә бутау (ризыкны); уйламыйча юкны-барны сөйләү; ыбыр-чыбыр.
**Абуһава** *ф. г.* Һава торышы, климат; һава шартлары.
**Авазә** *ф.* Имеш-мимеш хәбәре (чыбыксыз телефон). Көй.
**Аварә** *ф.* Әвәрә булып йөрү; мәш килү; бер эш белән мавыгып йөрү.

**Агуш** *ф.* Кочаклау, колачлау.
**Агях** *ф.* Белүче, хәбәрдар булучы, игътибарлы, уяу, сизгер.
**Азад** *ф.* Иреклe, хөр, бәйсез.
**Азамат, газамат** *г.* Бөеклек, дәрәҗәлелек, мәһабәтлелек; горурлык, олуглык.
**Азар** *ф.* Шелтә, әрләү, орышу.
**Азер** *ф.* Ут.
**Азерпәрәст** *ф.* Утка табынучы.
**Аинә** *ф.* Көзге.
**Айрылты** *төрк.* Ассигнование.
**Айрымсал** *төрк.* Ватылып беткән; чәрдәкләнеп беткән; булгәләнгән.
**Акар** *төрк.* Агар, агым су.
**Акшам** *ф.* Эңгер-меңгер вакыт, кич.
**Алийәт, әлийәт** *г.* Ант.
**Алиһә** *г.* Аллаһ, тәңре; хатын-кыз җенесендә тиңе булмаган бөек, олуг зат.
**Алман** *г.* Немец, германияле.
**Аләт** *г.* Җиһазлар, эш кораллары, приборлар.
**Алу** *ф.* Алыча җимеше.
**Аман, әман** *г.* Куркынычсызлык, тынычлык, иминлек.
**Амиз** *ф.* Аралаш, катнаш, кушылган.
**Амир** *г.* Боеручы, әмер бирүче; баш кеше.
**Амиранә** *г. ф.* Әмирләргә, түрәләргә охшатып боеру.
**Амин, амийн** *г.* Амин, шулай була күрсен!
**Амәнү** *г.* Иң хәвефсез, иң куркынычсыз.
**Ан** *ф.* 1. Бик кыска вакыт. 2. Ерактарак булган нәрсәгә күрсәтүче алмашлык.
**Анар** *ф.* Гранат агачы.
**Анарстан** *ф.* Гранат җимеше үсә торган бакча.
**Ансар** г. (нәсәрә) 1. Ярдәм итүче, ярдәмче. 2. Мөхәммәт

пәйгамбәрнең Мәдинә шәһәрендәге ярдәмчеләре, көрәштәшләре.
Араеш *ф.* 1. Бизәк, зиннәт. 2. Матур әйбер.
Арам *ф.* 1. Рәхәтлек, тынычлык. 2. Берни эшләмичә тик тору.
Араә *г.* (рәәә) Фикерләр, карашлар, уйлар.
Арзу, арәзу *ф.* 1. Теләк, омтылыш. 2. Ярату.
Ари *ф.* Рәхәтлек, тынычлык.
Асаеш *ф.* 1. Гомуми тынычлык, иминлек. 2. Рәхәтлек.
Асаре гатика (*фарсы изафәсе белән бирелгән гарәп алынмасы*) Борынгы әйберләр. Антиквариат.
Асийб *ф.* 1. Зыян, бәхетсезлек, чарасызлык. 2. Югалту.
Асия 1. Азиянең гарәпчә, фарсыча язылышы. 2. Фарсы телендә «тегермән» мәгънәсен белдерә.
Асйабан *ф.* Тегермәнче.
Асла, аслан *г.* 1. Һич, һичкайчан, беркайчан да. 2. Нигездә, тамырда. Әллүгатү аслия — ана теле.
Аслан *г.* (асүлә) Һич тә, һичкайчан.
Асман *ф.* 1. Күк йөзе. 2. Асманда — югарыда, һавада.
Асмане *ф.* 1. Түшәм. 2. Югарылык, биеклек (болытлар).
Астәнә *ф.* 1. Бусага. 2. Патша сараеның ишек төбе.
Атәш *ф.* Ут, ялкын, яндыргыч.
Атәшпәрәст *ф.* 1. Утка табынучы. 2. Мәҗүси.
Афзал *г.* Иң лаеклы, дәрәҗәле, иң яхшы.
Афтаб *ф.* Кояш, көн яктысы.
Афәрин *г.* Яхшы, бик күркәм, искиткеч (мактау сүзләре).
Афәрин *ф.* Яхшы, яшә! (Сокланып, мактап әйтелә торган сүз).
Афәт *г.* Бәла-каза, зыян күрү, югалту.
Ахирәт *г.* 1. Теге дөнья. 2. Соңгы көнгә кадәр дус булучы.
Ахир *г.* Соңгы, ахыргы.

Ахирел-әмер *г.* Соңгы халәттә, ахыргы чиктә. Иң соңгы эш.
Ахияр *г. ф.* Бертуган кебек якын, дус кеше.
Ашкярә *ф.* Ачык, ачык булу, билгеле булу, ачыклану.
Ашнә, әшнә *ф.* Таныш, дус-иш.
Ашпәз *ф.* Аш пешерүче, оста, пешекче.
Ашпәзханә *ф.* Аш пешерү урыны (бүлмәсе), кухня.
Ашөфтә *ф.* Борчылган, борчулы. Нык дулкынланган булу.
Аять *г.* 1. Билге, күрсәтмә, вәхи. 2. Могҗиза. 3. Коръәндәге сүрәләрнең җөмләләре, шигъри юллары.
Аһу *ф.* 1. Газәл. 2. Күркәм, гүзәл (чагыштырма мәгънәдә).
Аһәстә *ф.* 1. Акрын. 2. Йомшак.
Аһәң *ф.* Моң, көй.

## Б

Ба *ф.* Беләп. Ба шома — сезнең белән.
Баб *г.* 1. Ишек, капка. 2. Китапның бер бүлеге.
Бабелгали *г.* Элекке Төркиядә баш вәзир, Эчке һәм Тышкы эшләр министрлыклары урнашкан йорт. Европа телләрендә аны «Порта» яки «Бөек Порта» дип атап йөрткәннәр, ә кайчагында Төркия исеме урынына да кулланганнар. Гарәп илләрендә Бабелгали (Бөек Капка) буларак гамәлгә кергән була.
Бабелмәмат *г.* Үлем капкасы, үлем ишеге.
Бабелмәндәб *г.* 1. Кызыл диңгезнең көньяктагы бугазы, «Елау капкасы» яки «Яшьле капка» дип тәрҗемә ителә.

**Бавәр** *ф.* Ышану, ышаныч.
**Баг** *ф.* Бакча.
**Багбостан** *ф.* Җимеш бакчасы.
**Багый** *г.* 1. Теләүче, эзләүче. 2. Җәберләүче, рәнҗетүче, чиктән тыш азып, узынып китүче.
**Багыйс** *г.* 1. Сылтау, сәбәп. 2. Сәбәпче, этәрүче, кузгатучы.
**Бад** *ф.* 1. Җил. Баде баһар — язгы җил.
**Бадам** *ф.* Миндаль чикләвеге.
**Баде саба** *ф.* Төньяк-көнчыгыштан искән йомшак җил.
**Бади** *ф.* 1. Башлаучы, беренче. 2. Сәбәп, сәбәпче. 3. Тышкы як. 4. Җилле, җил белән бәйле, җилгә карашлы.
**Бадинҗан** *ф.* Баклажан.
**Бадия** *г.* Чүл, кыр, дала.
**Бадәи наб** *ф.* Саф шәраб, эчемлек.
**Баз** *ф.* Ачык.
**Базаргян, базиргян** *ф.* Сәүдәгәр, сатучы.
**Баздар** *ф.* Бөркет өйрәтүче.
**Бази** *ф.* Уен, мәзәк; уйнап рәхәтлек табу, ләззәт алу.
**Базу** *ф.* 1. Кул. 2. Көч-куәт.
**Баигъ** *г.* Сатучы.
**Баин** *г.* 1. Ачык булу, күренеп тору. 2. Яңадан кушылмаслык итеп хатын аеру.
**Байтар** *г.* Хайваннар дәвалаучы, ветеринар.
**Байтулла** *г.* Кәгъбә (Аллаһ йорты); мәчет.
**Бакирә** *г.* Гыйффәтле туташ.
**Бакый** *г.* 1. Мәңгелек, мәңге сакланучы. 2. Аллаһының эпитеты.
**Балига** *г.* Үсеп буйга җиткән, балигълыкка ирешкән кыз бала.
**Балин** *ф.* Баш астына сала торган кечкенә мендәр.
**Бану** *ф.* Бикә, ханым, әфәнде.

**Бари** *г.* Аллаh, бар кылучы, яратучы. Габделбари — Аллаh колы.
**Барид** *г.* 1. Салкын, суык. 2. Инандырмый торган дәлил. 3. Мәгънәсез, буш.
**Барика** *г.* 1. Яшенле болыт. 2. Өмет чаткысы (күчерелмә мәгънә). 3. Эчпошыргыч.
**Баркия** *г.* Телеграмма.
**Барәкаллаh** *г.* 1. Аллаh рәхмәтле итсен, Аллаh мөбарәк кылсын. 2. Афәрин, бик хуп, бик яхшы.
**Баруди** *г.* Дары.
**Басим** *г.* Елмаючы, көлүче.
**Басыйр** *г.* Яхшы күрүче, үткен зиhенле кеше, акыллы.
**Батыйль** *г.* 1. Ялгыш, хата, буш эш. 2. Гаделсезлек. (Шул ук тамырдан батталь — *эшсез, җил куып йөрү, ял итеп йөрү* hәм батталә — *батырлык, каhарманлык* сүзләре дә ясала).
**Батыйн** *г.* 1. Эчке, яшерен, карын. 2. Эчтә, күренми торган як. 3. Күңелдәге сер.
**Батыйнән вә заhирән** *г.* 1. Яшерен hәм ачыктан-ачык. 2. Күренеп тә, күренмичә дә.
**Батәртип** (фарсыча «ба» алкушымчасы hәм «тәртиб» гарәп сүзе) Тәртибе белән, тәртипкә яраш лы итеп. Гарәпчә әйтелеше — Бит-тәртиб — тәртип белән, тәртибе белән.
**Бахис** *г.* Тикшерүче, эзләнүче, фәнни хезмәт белән шөгыльләнүче. Баххәс сүзе дә шул ук мәгънәне белдерә.
**Бахосус** *ф. г.* 1. Атап әйткәндә, бигрәк тә. 2. Турысында, хакында, уңае белән.
**Бахур, баhур** *ф.* Җәйнең иң эссе вакыты, җәйге чиллә.
**Бахәбәр** *ф. г.* Хәбәрдар булу.
**Баhадир** *ф.* Зур куәткә ия булучы, батыр.
**Баhир** *г.* Ачык, ап-ачык, күренеп тора; искиткеч гүзәл, матур.

**Би** — бәйлек буларак гарәп һәм фарсы телләрендә гамәлдә; гарәп телендә **белән, өчен, -га, -гә, -ча, -чә** мәгънәләрен белдерә. Фарсы телендә киресенчә юклыкны белдерүче алкушымча, -сыз, -сез ролендә килә. Мәсәлән, бичара — *чарасыз*, бигайбә — *гаепсез* мәгънәсендә.
**Биаб** *ф.* Сусыз, коры җир.
**Биабруй** *ф.* Абруйсыз, намуссыз, оятны белмәгән.
**Бибәһа** *ф.* Бәясез, бик кыйммәтле.
**Бивафа** *ф. г.* Тотрыксыз, ышанычсыз, сүзендә тормаучы, оятсыз.
**Бивайә** *ф.* Өлештән мәхрүм ителгән.
**Бивә** *ф.* Тол калган хатын.
**Бигайниһи** *г.* Нәкъ үзе.
**Бигакыйбәт** *ф. г.* Югалган, һәлак булган, бәхетсез.
**Бигакыйль** *ф. г.* Гакылсыз, җүләр, ахмак кеше.
**Бигамь** *ф. г.* Кайгысыз, гамьсез.
**Бигаять** *ф. г.* Чиксез, чиктән тыш.
**Бигъсәт** *г.* Рәсми эш белән җибәрелгән миссия. Гарәпчә укылышы — **бәгъсәт**; мәбгас яки әлмәбгас — барлыкка килү, пәйда булу, чишмә башы, чыганак. Мәсәлән, Ибне Фазланның миссиясе.
**Бигыйбарәтиһи** *г.* Аның әйтүенчә, ул әйткәнчә, аның сүзе белән, үзенең сүзе белән.
**Бигянә, биганә** *ф.* Чит, ят, ялгызак.
**Бигөман** *ф.* Шиксез, шөбһәсез, уйсыз, фикерсез, уйламыйча.
**Бигөнаһ** *ф.* Гаепсез, гөнаһсыз.
**Бидар** *ф.* Уяу булу, зирәк булу.
**Бидаят** *г.* Башлангыч, башлау, берәр эшкә керешү — **фил-бидаятин** — башта, иң элек, иң әүвәл.
**Бидгать** *г.* 1. Яңалык, яңа башлангыч. 2. Динсезлек.

**Бизар** *ф.* 1. Чарасызлыктан интегү, нишләргә белмәү. 2. Туйдырып бетерү, интектерү, ачуны китерү. 3. Үпкәчел кеше.
**Бизарур** *ф. г.* (би+зарур) Юкка, кирәксезгә.
**Биззат** *г.* (*сакау «зәл» хәрефе белән язылa*) Турыдан-туры, үзем.
**Биигътибар** *ф. г.* Игътибарсыз.
**Бирадә** *ф. г.* 1. Теләмичә, теләксез. 2. Гарәп телендә «теләк белән» мәгънәсен белдерә.
**Бикадәри хәл** (*фарсы изафәсе белән бирелгән*) Көч-куәтендә булган кадәрле, көче җиткән кадәрле.
**Бикарар** *ф. г.* Карарсыз, нишләргә дә белмәү.
**Бикер, бикрүн** *г.* Саф, пакь, гыйффәтле.
**Бикяр, бикәр** *ф.* Буш, эшсез, гамәлсез, җил куып йөрү.
**Билахир** *г.* (би+әл+ахир) Соңында, азагында.
**Билвасыйт** *г.* Ярдәме, катнашы белән, берәр кеше аркылы эшләү, кемнең дә булса арадашчылыгы белән.
**Билгайни** *г.* 1. Күз белән. 2. Үзәгендә.
**Билгакес** *г.* Киресенчә, нәкъ киресе.
**Билгамәл** *г.* Эш белән.
**Билилтифат** *г.* Игътибар, илтифат белән.
**Билимкян** *г.* Мөмкинчелек белән.
**Билистинад** *г.* Таянып, ышанып.
**Билистифадә** *г.* Файдаланып, файдасын күреп.
**Билиттифак** *г.* Килешеп, уртак тел табып, күмәкләшеп.
**Билихлас** *г.* Ихласлык белән, чын күңелдән.
**Билиштирак** *г.* Катнашында, уртаклашып.
**Билиҗбар** *г.* Мәҗбүрителеп, ихтыярсыз рәвештә.
**Билкасд** *г.* Максатчан, күздә тотып, теләп.
**Билкыйс** *г.* Сөләйман пәйгамбәрнең мәгъшукасы.
**Билкыям** *г.* Басып торган хәлдә, баскан килеш.

**Билкүлли, билкөлли** *г.* Тулысынча, бөтенләе белән.
**Биллаһи** *г.* Аллаһ исеме белән ант итәм.
**Билмүвәҗәһә** *г.* Кара-каршы торып, йөзгә-йөз килеп очрашу.
**Билмөнасафә** *г.* Уртаклашып, бүлешеп, тигез итеп, урталай.
**Билмөнәсәбәт** *г.* Уңаеннан. (Мәсәлән, бәйрәм уңае белән.)
**Билмөшарәкә** *г.* Катнашында, катнашы белән.
**Билмөшаһәдә** *г.* 1. Күзәтеп, карап, күреп тору. 2. Очрашу, күрешү. **Әлмөкатәбә ныйсфүл-мөшаһәдә** — язышып, хат алышып тору, яртылаш күрешеп, очрашып торуга тиң.
**Билфигъли** *г.* Чыннан да.
**Билхак** *г.* Чынлыкта исә, чыннан да, нәкъ шулай.
**Билхасса, билхосус, бихосус** *г.* 1. Турында, хакында. 2. Атап, махсус рәвештә.
**Билхәйр** *г.* Хәере белән, яхшылык белән. **Билхәйриһи** — үзенең яхшылыгы белән.
**Биля васита** *г.* Арадашчысыз гына, турыдан-туры.
**Биля-газабин** *г.* **Биля** — инкяр итүне, юклыкны белдерә. Ачуланмыйча, усалланмыйча гына яки кабынмыйча, кызып китмичә генә.
**Билҗөмлә** *г.* 1. Барысы бергә. 2. Гомумән, тулысынча, тулысы белән.
**Бимаза** *ф.* 1. Тәмсез. 2. Уңайсызлык, тынычсызлык, кирәксезгә борчу.
**Бимар** *ф.* Авыру.
**Бимарханә** *ф.* Хастаханә, дәвалану йорты, шифаханә.
**Бимәгънә** *ф.* Мәгънәсез, буш.
**Бимәкян** *ф. г.* Урынсыз, йортсыз-җирсез.

**Бимәлял** *ф. г.* 1. Армый-талмый. Бик мул итеп, теләгәнчә, рәхәтләнеп. 2. Муллык.

**Бин** *г.* (-бну, -бәни, -ибн, -ибне шәкелләре дә шул ук мәгънәдә). Ир бала, углан.

**Бинабәрин** *г. ф.* Таянып, нигезләнеп, сылтап, шуңа күрә.

**Биназыйр** *ф. г.* Тиңе юк, тиңе булмаган.

**Бинаи рух** *г.* (*фарсы изафәсе белән язылган*) Рух төзелеше, рух нигезе.

**Бинам** *ф.* 1. Исемсез. 2. Танылмаган, билгесез, шөһрәтсез.

**Бинахак** *ф. г.* Гаепсезгә, хаксызга, нахакка рәнҗетелү.

**Бинамаз** *ф.* Гыйбадәт кылмый, намаз укымый торган кеше.

**Бинаән** *г.* Таянып, нигезләнеп.

**Бинаән галәйһи** *г.* Шуңа нигезләп, шуңа күрә, шул сәбәпле.

**Биниһая** *ф. г.* Бетмәс-төкәнмәс, иксез-чиксез.

**Биннисбәт** *г.* Карата, хакында, турысында, чагыштырмача.

**Бинноксан, биннуксан** *г.* Җитешсезлек белән, кимчелекле.

**Бинт, бүнәйә** *г.* Кыз бала, кызчык.

**Бипәрва** *ф.* Гамьсез, әдәп белмәгән.

**Бисат** *г.* Келәм, палас.

**Бисмилләһи** *г.* Аллаһының исеме белән.

**Биссәвия** *г.* Бәрабәр, бертигез, шундый ук.

**Битаб** *ф.* Көчсез, хәлсез.

**Битакать** *ф. г.* Көчсез-куәтсез, хәлсез.

**Битараф** *ф. г.* Бер якны да хуп күрмәү, ис китмәү. Бер якка да кушылмаучы, битараф кеше.

**Биттабгый** *г.* Нәкъ шулай, табигый, әлбәттә.

**Бит-тарикыйл-икътибас** *г.* Берәүдән үрнәк алып.

**Биттәвали** *г.* Бертоташтан, өзлексез рәвештә, бер-бер артлы.

**Биттəдриҗ** *г.* Бер-бер артлы, тəртибе белəн.
**Биттəмам** *г.* Тəгəллəп, тулысынча тəмамлап, бетереп.
**Биттəртиб** *г.* Тəртибе белəн, тəртибендə каралганча.
**Биттəслим** *г.* Тапшыру шарты белəн.
**Биттəфсыйли** *г.* Җентеклəп, тəфсиллəп аңлату.
**Биттəшəккүр** *г.* Яхшылык белəн, рəхмəт белдереп; рəхмəтлелек.
**Биттəҗрибə** *г.* Тəҗрибəлелек, тəҗрибə өстендə сынап карау.
**Бихак** *ф. г.* Хаксыз, дөреслексез.
**Бихар** *г.* 1. Диңгезлəр, сулыклар. 2. Шигырь үлчəме.
**Бихисаб** *ф. г.* Хисапсыз, чиксез.
**Бихозуриһи** *г.* Үзенең катнашында, үз алдында.
**Бихуд** *ф.* Һушсыз, сиземсез.
**Бихəбəр** *ф.* Хəбəрсез, мəгълүматсыз булу.
**Бихəблиллаһ** *г.* (би+хəбл+аллаһ) Аллаһының ярдəме белəн мəгънəсендə.
**Бихəдд** *ф.* Чиксез.
**Бихəсəбит-така** *г.* Көч-куəтеңдə барынча, көчеңə карап.
**Бихəсəбит-тəкъдири** *г.* Тəкъдиреңдə язылганча, язмышыңда билгелəнгəнчə.
**Бихөкмиллаһ** *г.* Аллаһының хөкеме белəн, Аллаһ кушканча, Аллаһ карамагында.
**Бичара** *ф.* Бернинди чарасы булмаган, мескен, бəхетсез.
**Бишəкки** *г.* (би+шəкк) Шиксез, икелəнүсез, бер шөбһəсез.
**Биəр, биəрүн** *г.* Кое.
**Биəдəб** *ф. г.* Əдəпсез, əдəпне белмəгəн, тəртипсез, тупас.
**Биəйихалəн** *г.* Ничек булса да, һəрхəлдə.
**Биəман** *г.* Тынычсыз, борчулы.
**Биəсас** *ф.* Нигезсез, таянычсыз.

**Биҗаваб** *ф. г.* Җавапсыз.
**Биһудә** *ф.* Файдасыз, буш нәрсә.
**Биһуш** *ф.* Һушсыз, аңсыз.
**Богдүн, бугдүн** *г.* Ераклык, аралык.
**Борадәр, бәрадәр** *ф.* Ир туган, кардәш.
**Борадәрана** *ф.* Туганнарча, ага-энеләр кебек.
**Борак, бурак** *г.* 1. Әл-Кодес шәһәрендәге еглау-сыктау башкарыла торган урын, еглау-сыктау стенасы. 2. Мөхәммәт пәйгамбәрнең Мәккә шәһәреннән Әл-Кодескә (Иерусалим) атланып барган мифик хайванның исеме.
**Борһан** *г.* Дәлил, күрсәтмә, исбатлаучы факт.
**Бостан, бустан** *ф.* Бакча, гөлбакча.
**Бот, пот** *ф.* Мөселман булмаганнарның табына торган сурәтләре, аллалары.
**Ботпарәст** *ф.* Төрле сурәтләргә, сыннарга табынучы.
**Былбыл, бүлбүл** *г.* Сандугач.
**Бәбде бәҗвин.** Иске татар телендә тапкырлау җәдвәленең исеме. Гарәп телендә һәр сан билгеле бер хәреф белән белдерелә ала (әлиф — 1, ба — 2, тә — 3,...).
**Бәвасир** *ф.* «Геморрой» — юан эчәк шеше (медицина термины).
**Бәвел** *г.* Сидек.
**Бәгудә, бәгузә** *г.* Черки, сукыр черки.
**Бәгъдә** *г.* Соңыннан, аннары.
**Бәгъдү, бәгъд** *г.* Соңрак, тагын.
**Бәгъзе** *г.* Кайбер, кайсы ки.
**Бәгъзән** *г.* Кайчак, кайвакыт, кайчагында.
**Бәгыйд** *г.* Ерак, ераклаштырылган.
**Бәгыс** *г.* 1. Күндерү, берәр эш белән җибәрү. 2. Вәкил итү.
**Бәд** *ф.* Начар, яман.
**Бәдаигъ** *г.* Матурлар, гүзәлләр.

**Ьәдасыл** *ф. г.* Яман нәселдән, затсыз чыгышлы.
**Бәдбәдийн** *ф.* Төшенкелеккә бирелүчән, пессимист.
**Бәдбәдәк, бәдбәдә** *ф.* Бытбылдык.
**Бәдбәхет** *ф.* Бәхетсез; явыз.
**Бәдбәхтанә** *ф.* Бәхетсезлеккә каршы.
**Бәдгадәт** *ф. г.* 1. Начар, бозык гадәтле. 2. Иркә, кыланчык.
**Бәдгу** *ф.* Яла ягучы, хурлаучы.
**Бәдгөман, бәдгәман** *ф.* Ышанмаучы, яман уйлы кеше, шикләнүчән.
**Бәдгөһәр** *ф. кара*: бәдасыл.
**Бәддога** *ф. г.* Яман теләк, каргыш, каргау.
**Бәддәли** *ф.* 1. Куркак, түбән җанлы. 2. Көнче.
**Бәдер** *г.* 1. Тулган ай. 2. Тарихи термин буларак та гамәлгә кергән. Мәсәлән, «Әлбәдер» планы.
**Бәдзәбан** *ф.* Усал, начар телле.
**Бәдигъ** *г.* 1. Күз явын алырлык матур, чибәр, гүзәл. 2. Тәмле телле.
**Бәдкыяфәт** *ф. г.* Ямьсез, кыяфәтсез, килбәтсез.
**Бәдкяр** *ф.* 1. Бозык, азгын. 2. Явыз.
**Бәдкярдар** *ф.* Бозык, явыз эшләр эшләүче.
**Бәднам** *ф.* Начар, яман исем. Яманат. Начарлык белән дан казану.
**Бәдрафтар** *ф.* Тәртипсез, әдәп белмәгән, үзен начар тотучы.
**Бәдретдин** *г.* (Бәдер+эт+дин) Диннең тулган ае.
**Бәдруй** *ф.* Ямьсез, шыксыз.
**Бәдсурәт** *ф. г.* Ямьсез кыяфәтле, ямьсез чырайлы кеше.
**Бәдтәр** *ф.* Яманрак, начаррак.
**Бәдхаль** *ф. г.* Авыр, начар хәлле.
**Бәдхаг** *ф.* Усаллык теләүче, явыз ниятле.

**Бəдəвам** *ф. г.* Дəвамлы рəвештə, бертоташтан.
**Бəдəви** *г.* Чүл гарəбе. Күчмə тормыш белəн көн күрүче гарəп.
**Бəдəл** *г.* Алмашка бирелə торган мал, əйбер. Алмаштыру.
**Бəдəн** *г.* Гəүдə, тəн.
**Бəдəəлмəгариф** *г.* Башлангыч белем.
**Бəзəнбаһадир** *ф.* Бик батыр, курку белмəс.
**Бəйдаə, бəйзаə** *г.* Ак төс.
**Бəйан** *г.* 1. Ачык, ачыклану. 2. Аңлату, рəсми белдерү. 3. Декларация.
**Бəйгать** *г.* Ант итү. Турылыклы булырга сүз бирү.
**Бəйин** *г.* Ачык, билгеле.
**Бəйнəлмилəл** *г.* Халыкара.
**Бəйнəлəһали** *г.* Кешелəр арасында, халык арасында.
**Бəйнəннас** *г.* Кешелəр арасында.
**Бəйт** *г.* 1. Өй, йорт. 2. **Бəйтү шигърин** — шигырь үлчəме.
**Бəйтуллаһ** *г.* Аллаһ йорты, кəгъбə.
**Бəйтүлмал, бəйтелмал** *г.* Дəүлəт милке, "малы" туплана, саклана торган урын.
**Бəйтүл мөкаддəс, Бəйтел кодес** *г.* Иерусалим шəһəренең гарəпчə əйтелеше. Изге йорт.
**Бəка** *г.* Мəңгелек. Дарел-бəка — мəңгелек йорт.
**Бəкъкаль** *г.* Яшелчə сатучы.
**Бəкъиə** *г.* Калган, артып калган, калдык.
**Бəкярəт** *г.* Сафлык, пакьлек, гыйффəтлелек.
**Бəлдə** *г.* Шəһəр.
**Бəли** *ф.* Əйе, шулай(раслауны белдерүче сүз.)
**Бəлигъ** *г.* Оста, матур, тирəн мəгънəле итеп сөйлəнгəн, җиткерелгəн.
**Бəллүр, биллүр** *г.* Кристалл, хрусталь.

**Бәляә** *г.* Кайгы, хәсрәт.
**Бәлягать** *г.* 1. Балигъ булу, үсеп буйга җитү. 2. Оста итеп сөйләү (риторика).
**Бәләди** *г.* 1. Шәһәр идарәсе хакимияте.
**Бәләнд** *ф.* 1. Биек, югары. 2. Олуг, бөек.
**Бәни** *г.* Углан, угыл бала. **Бәни ислам** — мөселманнар; **бәни Исраил** — яһүдиләр.
**Бәнәгяһ** *ф.* Кинәттән, уйламаганда, көтмәгәндә.
**Бәрайә** *ф.* Өчен.
**Бәрат** *г.* Шәгъбан аеның 15 нче көне. Бу көнне үлгәннәрне искә алу мәрасимнәре уздырыла.
**Бәраәт** *г.* Аклану, гафу кылыну.
**Бәрбадрәфтә** *ф.* Кирәксезгә сарыф ителгән, туздырылган.
**Бәрбәрият** *г.* 1. Кыргыйлык. 2. Тупаслык, вәхшилек.
**Бәрия** *г.* 1. Чүл, дала, сәхрә. 2. Җан иясе.
**Бәр тараф** *ф. г.* Читләштерү, ераклаштыру.
**Бәр фәраз** *ф. г.* Уйлап карыйк, күз алдына китерик, фараз итик.
**Бәрхак** *ф.* Чын, дөрес.
**Бәрәкәт** 1. Киңлек, муллык, бәрәкәт. 2. Белеп кенә файдалану, озакка сузу.
**Бәс** *ф.* 1. Җитте, булды. 2. Димәк, шулай булгач. 3. Гарәп теленең кайбер сөйләмнәрендә *тукта, шул гынá, җитәр, булды, бары тик* мәгънәсендә дә кулланыла.
**Бәсаләт** *г.* Куркусызлык, батырлык, егетлек.
**Бәсарәт, бәсыйрәт** *г.* 1. Күрә белүчәнлек. 2. Аңлап эш итә белү.
**Бәстә** *ф.* Бәйләнгән, баглы булу, тоташкан булу.
**Бәстәре госса** *г.* Кайгы-хәсрәт түшәге.
**Бәсыйрәт** *г.* Аң, аңлылык.
**Бәст** *г.* Түшәү, җәю.

**Бәсыйт** *г.* Бик гади, беркатлы, садә.
**Бәтый, батый** *г.* Әкрен, сүлпән. **Батыйүл-хәрәкәт** — әкрен хәрәкәт итүче.
**Бәхеш, бәхшиш** *ф.* Бүләк итеп бирелгән нәрсә.
**Бәххаль** *г.* Бик саран кеше. **Бухлүн, бәхәл, бухәләә** — *саранлык* мәгънәсендә.
**Бәхыйль, бахыйль** *г.* Саран, карун.
**Бәхре мөнҗәмид җәнүби** *г.* Көньяк боз диңгезе.
**Бәхре мохыйту атласи** г. Атлантик океан.
**Бәхре мохыйту кәбири; мохыйту һади** *г.* Тын океан.
**Бәхре мохыйту мөнҗәмид шимали** *г.* Төньяк боз океаны.
**Бәхре мохыйту һинди, мохыйту һинди** *г.* Һинд океаны.
**Бәхре сияһ** *г. ф.* Кара диңгез.
**Бәхре сәфид** *г. ф.* Урта диңгез.
**Бәхре әбъяд мотауассат** *г.* Урта диңгез.
**Бәхре әсүәд** *г.* Кара диңгез.
**Бәхре хәзәри** *г. ф.* Каспий диңгезе.
**Бәхрән** *г.* Диңгез юлы белән.
**Бәхтияр** *г. ф.* Бәхетле.
**Бәхәс** *г.* 1. Карау, тикшерү, өйрәнү. 2. Бәхәсләшү, сүз алып бару, фикер алышу.
**Бәччә, баччә** *ф.* Кечкенә бала, сабый, малай.
**Бәшарәт** *г.* (бишарәт, бәшаир, бүшр) Яхшы хәбәр, шатлык.
**Бәшир** *г.* Яхшы хәбәр китерүче, сөендерүче.
**Бәшәр** *г.* Кеше.
**Бәшәрәт** *г.* Тире, тән тиресе.

Бәшәрият г. 1. Кешелек дөньясы. 2. Табигать, холык.
Бәәс г. Зарар, зыян, куркыныч нәрсә.
Бәяз г. Аклык, ак төс.
Бәян г. Аңлату.
Бәянелхак г. Хаклыкны аңлату, дөреслекне төшендерү.
Бәүваб, бәүүаб г. Ишек, капка сакчысы.
Бәҗай ф. Тиешенчә, җиренә җиткереп, урынлы итеп.
Бәһаә г. Матурлык, күркәмлек.
Бәһа ф. Бәя, хак.
Бәһаим ф. Дүрт аяклы терлек.
Бәһанә ф. Сылтау, сәбәп.
Бәһар ф. 1. Яз айлары. 2. Бәһарән — яз вакыты, язгы көннәр (шигърияттә кулланыла).
Бәһи г. Матур, гүзәл.
Бәһрәмәнд ф. 1. Бар эше дә уңышлы булган кеше; бәхетле. 2. Файда күрүче; берәр нәрсәдән ләззәт, тәм табучы.
Бөлдан, бүлдан (бәләд сүзенең күплек шәкеле) г. Илләр, шәһәрләр.
Бөлуг г. Үсеп буйга җитү, балигъ булу, җитлегү, өлгерү.
Бөнияд г. ф. Нигез салу, төзү («бина» сүзенә нигезләнеп ясалган).
Бөнүвәт г. Угыллык.
Бөнәййәт, бүнәййәт г. Кызым, кызчыгым.
Бөрудәт г. Салкынлык, суыну.
Бирҗийс г. Юпитерның гарәпчә әйтелеше.
Бөрҗүн, бүрҗүн г. Манара.
Бөрҗүд г. Кытыршы тукымадан тегелгән кием.
Бөһтан ф. Ялган сүз, кешегә яла ягу.
Бәрих г. Үткән көн, кич. Әлбәрихә — кичәге көн.

# В [Уа]

**Ваба** *г.* Үләт, чума, йогышлы авыру.
**Вабур, вапур** (*француз сүзенең гарәпчә-фарысча әйтелеше*) Пар машинасы, пароход.
**Вабәстә** *ф.* Бәйләнгән, бәйле.
**Ва вәйла** *г.* Нинди үкенеч, ни үкенеч.
**Вагыйзь** *г.* 1. Сөйләүче. 2. Өндәүче (яхшы эшкә, гамәлгә).
**Вади** *г.* 1. Уйсулык, тарлавык. 2. Елга үзәне.
**Ваз** *ф.* Чигенү, баш тарту. **Вә аз шома** — һәм сездән, сезнең тарафтан.
**Вазаифел әгъза** *г.* Әгъзаларның вазифалары (функцияләре).
**Вазгый** *г.* 1. Куелган, тиешле саналган, шартлы, билгеләнгән. 2. Позитив.
**Вазгыять** *г.* Торыш, халәт.
**Вазыйх** *г.* Билгеле, ачык, анык.
**Вактеззоһер** *г.* Төш вакыты.
**Вактелгыйш** *г.* Кояш батканнан соңгы вакыт, кичен, кичке аш вакыты.
**Вакыйф** *г.* 1. Туктап торучы, басып торучы. 2. Хәбәрдарлык.
**Валид** *г.* 1. Бар итүче, тудыручы. 2. Ата (әти кеше).
**Валидә** *г.* Ана, әни булган кеше.
**Валидәйн** *г.* Ата-ана, әти-әни.
**Валлаһе әгъләм** *г.* Аллаһ күбрәк белә; Аллаһыга мәгълүмрәк.
**Варид** *г.* 1. Килешүче, ирешүче. 2. Килгән, ирешкән. **Әхбәре варидә** — килеп ирешкән хәбәрләр.
**Варидәт** *г.* 1. Читтән китерелгән әйберләр (импорт). 2. Керемнәр, кәсептән кергән табыш, керем.

**Варис** *г.* Мираска хуҗа булып калучы. Үлгән кешенең калган малына хуҗа булып калучы, мирас алучы.

**Васигъ** *г.* 1. Киң, иркен, җәелгән булу. Сыйдыра алу. 2. Рөхсәт ителү, булдыра алу, хәлдән килү.

**Васикъ** *г.* Ышанучы, танучы, инанучы.

**Васита** *г.* 1. Арадаш, ике арада эш йөртүче. 2. Тоташтыру, бәйләү. 3. Берәр эшне булдыру яисә башкару өчен күрелә торган чара.

**Васләт** *г.* Элемтә, бәйләнеш, тоташу.

**Вассаф** *г.* Сурәтләп, күрсәтеп бирүче.

**Васфи** *г.* Төсмерле, сыйфатлы.

**Васыйль** *г.* 1. Килеп җитүче, килүче. 2. Тоташтыручы, элемтә тотучы. 3. Аерылмас дус.

**Васыятьнамә** *г. ф.* Васыять кәгазе.

**Васәка** *г.* Төяү, йөкләү.

**Ватане асыйль** *г.* Туган җир, асылдагы туган ил, төп туган ил.

**Ватанпәрвәр** *г. ф.* Ватанын-илен сөюче, яратучы кеше. (патриот).

**Вафа** *г.* 1. Башкару, үтәү, тугрылыклы булу, сүздә тору. 2. Муллык.

**Вафадар** *г. ф.* Сүзендә торучы, вәгъдәгә тугрылыклы булучы.

**Вафат** *г.* Үлем.

**Вахид** *г.* 1. Бердәнбер, берүзе, ялгыз. **Вә лә вахид** — беркем дә, һичкем, бернинди дә түгел.

**Важиб, Важип** *г.* Үтәлергә тиеш булган, фарыз эш, бурыч.

**Важид, вәҗид** *г.* 1. Бер дә икеләнмичә үтәлергә тиешле. 2. Вәҗибәл-вуҗүд — үзеннән-үзе бар булган, яратылган; Аллаһ тәгалә. 3. Еш тибүчән (йөрәк). 4. Һәр кешенең (Аллаһ каршындагы) үтәлергә тиешле бурычы.

**Ваhаб, Ваhап** *г.* Бар булган нәрсәне бирүче (Аллаhының эпитеты).

**Ваhиб** *г.* 1. Бүләк бирүче, бүләкләүче. **Ваhhаб** — Аллаh тәгаләнең эпитеты. **Ваhhабилар** — ислам динендәге мәзhәб, тармак.

**Видаг** *г.* Озату, хушлашу. **Әлвидагел ахыйр** — соңгы озату, соңгы саубуллашу.

**Викая** *г.* Булдырмый калу, кисәтү, саклау, профилактик эш уздыру, булдырмый калу өчен чарасын күреп кую.

**Вилдан** *г.* 1. Бала, сабый. 2. Ир бала. 3. Берәр эшнең нәтиҗәсе, җимеше.

**Вилаят** *г.* 1. Идарә, өлкә, штат. 2. **Әhлел-вилаят** — изгеләр. 3. Опекунлык (карамакка алу). 4. **Вәли** — якын, туган, үз кеше. **Вәлийүл-лаhи** — Аллаhының дусты. **Вәлийүл-әмр** — хакимият вәкиле. **Вәлийүл-гаhди** — тәхет варисы. **Валлаhү вәлийүт-тәүфыйк** — Аллаh үзе рәхмәт hәм игелек ирештерүчедер.

**Вирәсәт** *г.* 1. Малга хуҗа булып калу, нәселдәнлек. 2. **Варәсә** — варислар; үлгән кешенең малына ия булып калучылар. 3. **Вирса** — мирас итеп калдырылган мал. 4. Ген (биология термины).

**Висайә** *г.* Опекунлык, карамакка алу, опека.

**Висак** *г.* Килешү, тугрылык беркетмәсе, договор, пакт h. б.

**Висаль** *г.* Аралашу, кавышу, кушылу. 2. Җенси якынлык.

**Вифак** *г.* 1. Килешү, туры килүчәнлек, тынычлык килешмәсе. 2. **Муафыйк** — хуплаучы, ярашлы булу, туры килү.

**Виҗаh** *г.* 1. Берәр нәрсәнең каршында тору, йөзгә-йөз килү. 2. Капма-каршы якта булу. 3. **Вәҗаhәт** — зыялылык, дәрәҗә.

**Восуль** *г.* Килеп җитү, ирешү, барып җитү.

**Вәбал** *г.* 1. Авыр хәл, аңлашылмаучылык, кыен халәт.

2. Усаллык, кайгы-хәсрәт, яманлык. 3. Зыян, һәлакәт; ниндидер бер эш нәтиҗәсендә барлыкка килгән бәхетсезлек, зыян.
**Вә бәгъдә** *г.* Шуннан соң, соңында, һәм башка.
**Вә гайре зәлик** *г.* Һәм моннан башкалар.
**Вә гайриһи** *г.* Һәм башкалар.
**Вә галә әлин** *г.* Барысының да, барчаның да.
**Вәгыйдь** *г.* Янаулар, куркытулар. **Йәүмүл-вәгыйдь** — исәп-хисап; олут хөкем ителү көне (Аллаһ каршында).
**Вәдад, уидад** *г.* Ярату, дуслык, татулык, яхшы мөнәсәбәт.
**Вәзарәт** *г.* Министрлык.
**Вәзен** *г.* 1. Үлчәү, авырлык. 2. Шигъри үлчәм, музыка үлчәме.
**Вәйл, үәйл** *г.* Үкенеч, кайгы.
**Вәйран** *ф.* Ватык, җимерек, хәрабә хәленә килгән.
**Вәйселкарани** *г.* Коръән кушканны үтәүче, тәкъва зат.
**Вәкарь** *г.* Җитдилек, үз-үзен дәрәҗәле (вәкарьле) тоту.
**Вәкяләт** *г.* Вәкиллек. **Вәкяләтүл-әнбә әл-гарабийә** — гарәп информацион агентлыгы. **Вәкәлә билләһи** — Аллаһының иркенә тапшыру.
**Вәкяләтән** *г.* Вәкил буларак.
**Вәли** *г.* 1. Ия, хуҗа, яклаучы. Изге. 2. Ләкин (вәләкин сүзенең кыска шәкеле).
**Вәлид** *г.* 1. Бала, сабый. 2. Берәр эшнең нәтиҗәсе, җимеше.
**Вәлхасыйль** *г.* Җыеп, бер сүз белән әйткәндә, нәтиҗәдә.
**Вәләд** *г.* Бала, ир бала.
**Вә ләү** *г.* Әгәр дә, ичмасам, һич булмаса.
**Вә ма әшбәһе зәликә** *г.* Шуңа охшашлы, шуның шикелле, моның кебек, шундыйлардан.
**Вә мәга заликә** *г.* Һәм шуның белән бергә, шулай булса да, шулай да.

**Вәраә** *г.* Артта, артында, аркасында. **Вәраәән-нәһер** — елга аръягында, елга артында. **Мә вәраәән-нәһер** — елга аръягындагы җир.
**Вәрзеш** *ф.* Гимнастика, физик күнекмә, спорт, җиңел атлетика һ. б.
**Вәрзешкяр** *ф.* Спортчы, гимнаст, атлет.
**Вәрәкъ** *ф.* 1. Бер бит кәгазь. 2. Яфрак.
**Вәсамәт** *г.* Күркәмлек, матурлык, мөлаемлык.
**Вәсатый** *г.* Уртадагы, урталык.
**Вәсамәт** *г.* Гүзәллек, матурлык, чибәрлек, күркәмлек.
**Вәсвәс** *г.* Аздыручы (иблиснең эпитеты).
**Вәсвәсә** *г.* Начар уй-фикерләрне ирештерү, тарату, котырту, аздыру.
**Вәсем** *г.* Тамга, келәймә.
**Вәсигъ** *г.* Киң, иркен, күп сыйдырышлы.
**Вәсим** *г.* Матур, чибәр, мөлаем.
**Вәсилә** *г.* 1. Чара, ысул, юл, әмәл. 2. Берәр чараны башкару коралы.
**Вәссәлам** *г.* Шуның белән тәмам булды, бетте.
**Вәсәх** *г.* Пычраклык, керлелек, пакьсезлек; пычрак, шакшы.
**Вәтәд** *г.* 1. Палатканы торгызып куя торган казык. 2. Багана.
**Вәфрәт** *г.* Муллык, күплек.
**Вәфык** *г.* Ярашлы булу, муафыйклык, уңай килү.
**Вә халән** *г.* Әле хәзер дә, бу, шушы вакытта да.
**Вәхдани** *г.* 1. Берләнбер, уникаль. **Ибне вәхдани** — бердәнбер угыл. 2. Ялгызак.
**Вәхданиять** *г.* Бердәнберлек. Бер аллага гына ышану, гыйбадәт кылу.
**Вәхи** *г.* Аллаһ тарафыннан пәйгамбәргә ирештерелгән

фикерләр, күрсәтмәләр; пәйгамбәр күңеленә иңдерелгән боерыклар.
**Вәхийүн** *г.* Тиз, кәтмәгәндә. **Мәүтүн вәхийүн** — һич көтмәгәндә вафат булу. Көтелмәгән үлем.
**Вәхши** *г.* Кыргый, явыз, ерткыч, канечкеч, кансыз.
**Вәхшиянә** *г.* Кыргыйларча, вәхшиләрчә, ерткычларча.
**Вә әтүни би әһликүм әҗмәгыйн** *г.* Гаиләгез белән барыгыз бергә миңа килегез.
**Вәҗазәт** *г.* Кыска, ләкин төпле итеп аңлатып бирү.
**Вәҗаһәт** *г.* Дәрәҗәлелек, зыялылык, әһәмиятлелек, мөһимлек; дөреслек, нигезлелек.
**Вәҗига** *г.* Авыртыну, сызлану, сыкрану.
**Вәҗәһәссорур** *г.* Шат йөз, ачык чырай. Шатлыклы.
**Вәһем** *г.* 1. Күз алдына китерелгән уй, хыялый фикер, иллюзия. 2. Уй, фикер, идея. 3. Чамалау, шикләнү, курку. 4. Ялгышу, буталу.
**Вөзух** *г.* Ачыклык, билгелелек.
**Вөкуг** *г.* 1. Төшү, түбән тәгәрәү. 2. Бер эшнең башкарылуы; эшнең халәте.
**Вөкуд** *г.* Ягулык.
**Вөҗуб** *г.* Зарурлык, тиешлелек. Башкарылырга тиешле яки фарыз булган эш.
**Вөҗүд** *г.* Барлык, бар булу, катнашу. Гәүдә.

# Г

**Габавәт** *г.* Ахмаклык, аңгыралык, зиһенсезлек, аңсызлык, миңгерәүлек.
**Габбас** *г.* Караңгы чырайлы; кырыс кеше.
**Габделбәр** *г.* Яхшылык колы, тыңлаучан кеше; биргән

вәгъдәгә турылыклы; яхшылык эшләүче; пакь вә саф, диндар кеше.

**Габделвәли** *г.* Изге кол. Аллаһыга якын торучы зат.

**Габделгазиз** *г.* Олуглык; бөеклек колы, сирәк зат.

**Габделгани** *г.* Байлык, муллык колы.

**Габделгафур** *г.* Гафу итүче, кичерүче.

**Габделхак** *г.* Дөреслек, хаклык колы; гадел кеше.

**Габделхаликъ** *г.* Булдыручының, бар нәрсәне яратучының (Аллаһының) колы.

**Габделхәбир** *г.* Хәбәр ирештерүче, гыйлем иясе. Зур гыйлемгә ия кеше.

**Габделҗаббар** *г.* Зур көч, кодрәт колы; көч-куәткә ия булучы.

**Габделҗәмил** *г.* Күркәмлек, матурлык колы. Яхшы эш башкаручы.

**Габдерауф** *г.* Миһербанлы, кешенең хәленә керүчән, ярдәмчел кеше.

**Габдият** *г.* 1. Коллык. 2. Табынучанлык.

**Габдрахман** *г.* Шәфкатьле кеше.

**Габдулла** *г.* Аллаһының колы.

**Габи** *г.* Ахмак, акылсыз, миңгерәү.

**Габид** *г.* 1. Кол, буйсынучы. 2. Гыйбадәт кылучы.

**Габиданә** *г. ф.* Колларча, коллар кебек.

**Габәс** *г.* 1. Уен; мавыгу, кызык өчен генә башкару 2. Бозу, юкка рәнҗетү. 3. Бер файдасызга, бушка нәрсәдер эшләү.

**Гаваид** *г.* Файда, керем. Налогтан кергән файда.

**Гавам** *г.* Төркем, халык, масса.

**Гавас** *г.* Су астына энҗе эзләп төшүче. Водолаз.

**Гадавәт** *г.* Дошманлык, күралмаучылык.

**Гадаләт** *г.* Тугрылык, гаделлек.

**Гадаэ** *г.* Иртәнге аш.

**Гадид** *г.* Күпсанлы; сан, микъдар.

**Гадлия** *г.* Хокук эшләре, юстиция.

**Гаднан** *г.* Гарәбстанның Хиҗаз, Нәҗад тирәсендә яшәгән «төньяк» гарәпләренең нәсел башлыгы исеме.

**Гадр** *г.* Бәреп, җимереп керү; хыянәт, мәкер.

**Гадәм** *г.* Юк булу, югалу. **Әлхукмүл игъдәм** — үлем җәзасы.

**Гадәтән** *г.* Гадәттәгечә, гадәтенчә.

**Гадү** *г.* Дошман.

**Газаль** *г.* **1.** Кыр кәҗәсе, кәҗә бәтие. **2.** Мәхәббәт, матур хисләр турында язылган шигъри юллар, газәлләр. **3.** Төчетелләнү, яраткан булып кылану.

**Газвәт** *г.* Хәрби һөҗүм, ябырылу.

**Газем** *г.* 1. Тәвәккәллек, карар итү, ниятләү. 2. Көч, куәт.

**Гази** *ф.* 1. Ислам дине өчен көрәшүче, мөрид. 2. Сугышчан.

**Газиз** *г.* 1. Көчле, булдыклы. 2. Сирәк, бәһале, бик сирәк очрый торган. 3. Йомшагым, кадерлем.

**Газраил, Гыйзраил** *г.* 1. Үлем фәрештәсе. 2. Каты күңелле, шәфкатьсез.

**Газыб** *г.* Ачу, нәфрәт, кызулану, кызып китү.

**Газыйм** *г.* 1. Бөек, зур. 2. Зыялы. 3. Мөһим, җитди. 4. Искитмәле, бөек, менә дигән.

**Гаиб** *г.* Югалу, юк булу, гаиб булу.

**Гаибанә** *г.* Күренмичә, күрмичә, үзе юкта.

**Гаид** *г.* 1. Кайтып килүче. 2. Файда, керем.

**Гаикъ** *г.* 1. Киртә, тоткарлык, комачаулык, катлаулылык. 2. Ыспай гына киенеп, ясанып йөрүче.

**Гайб** *г.* 1. Юк булу, катнашмау; күз алдында булмау. 2.Яшертен, күзгә күренми торган, юкка чыккан, югалган. **Гайб ганәл вуҗүд** — аңсыз хәлдә яту.

**Гайбәт** *г.* Хурлау, яманлау, булмаган эшне эшләүдә гаепләү, яла ягу.
**Гайд** *г.* Бәйрәм; **Гайдел әдха** — Корбан бәйрәме. **Гайдел фитр әлмөбарәк** — ураза гаете. **Гайдел мәүлид ән-нәбауи** — Пәйгамбәрнең туган көне бәйрәме.
**Гайн** *г.* 1. Күз. 2. Чишмә, чыганак. 3. **Гайнүннәфсүһү** — нәкъ үзе.
**Гайнелякыйн** *г.* Ап-ачык, ачыктан-ачык.
**Гайнетдин** *г.* Дин күзәтчесе.
**Гайни** *г.* 1. Күз алдында, күренә торган. 2. **Йәгайни** — Йә, күз нурым! Гарәп теленең Гыйрак шивәсендә «әйе, тыңлыйм» мәгънәсен белдерә.
**Гайнуллаһ** *г.* Аллаһының күзәтчесе, күзәтеп торучысы.
**Гайре** *г.* 1. Башка, үзгә, бүтән. 2. Татар телендәге «-сыз, -сез» яки «түгел» мәгънәсенә туры килә.
**Гайре мәгъкуль** *г.* Ярашлы түгел, тиешсез, кирәксез.
**Гайре мөнтазам** *г.* Тәртипсез, системасыз рәвештә.
**Гайре рәсми** *г.* Рәсми булмаган, рәсми түгел.
**Гайре табигый** *г.* Табигый түгел, табигый булмаган.
**Гайрәт** *г.* 1. Көнчелек. 2. Көч-куәт; ашкынучанлык; тырышлык.
**Гайсә** *г.* Пәйгамбәр исеме.
**Гайш** *г.* 1. Тормыш, тереклек. 2. Икмәк, ризык.
**Гайяр** *г.* Гайрәтле, дәртле кеше.
**Гакакыйр** *г.* Агу; үләннән ясалган дару; дару үләне.
**Гакде никях** *г.* Никахлашуны теркәү, никах уку.
**Гакес** *г.* 1. Киресенчә, киресе, капма-каршы. 2. Кире як, тискәре як. 3. Яктылыкның кире кайтуы. Балкыш, чагылыш.
**Гаклыят** *г.* Бар нәрсәләр дә; акыл белән ирешелгән нәрсәләр; уйлар, фикерләр, төшенчәләр.
**Гаклән** *г.* Акыл белән, акыл буенча, рациональ.

**Гакрәб** *г.* 1. Чаян. 2. Сәгать угы. 3. Уйдырмалар; яла ягу, бәхетсезлекләр, бәлаләр.
**Гакыд** *г.* Тоташтыру, бәйләү, килешү, контракт.
**Гакыйбәт** *г.* Нәүбәт, чират белән.
**Гакыйд** *г.* 1. Тоташтырылган, бәйләнгән. 2. Оеган, катып калган, ныгыган. 3. Теләктәш, союзник. 4. Концентрат. 5. Җитәкче, даһи. 6. Полковник.
**Гали** *г.* 1. Бөек, олуг, өлкән. 2. Югары дәрәҗәле, мәртәбәле. 3. Кыйммәт, бик бәяле.
**Галиб** *г.* 1. Җиңүче. 2. Өстенлек итүче. 3. Күпчелек, күп өлеше, зур өлеше.
**Галибанә** *г.* Җиңүчәнлек белән, батырларча, каһарманнарча.
**Гализадә** *г. ф.* Олы зат, аксөяк, аристократ.
**Галиманә** *г. ф.* Галимнәрчә, укымышлыларча.
**Галимулла** *г.* Аллаһының галиме, укымышлысы.
**Гали мәкам** *г.* Олуг урын, зур дәрәҗә, зур урын.
**Галишан** *г. ф.* Зур мәртәбә, дәрәҗә, бөеклек, дан.
**Галиҗәнаб** *г.* Зур дәрәҗәле, мөхтәрәм зат.
**Галләм** *г.* Белемле, белем иясе.
**Галәйкә** *г.* Сиңа.
**Галәйна** *г.* Безгә.
**Галәм** *г.* Шактый күпне белгән; гыйлем иясе.
**Галтән** *г.* Хаталанучылар, ялгышучылар.
**Галямәт** *г.* 1. Билге, тамга. 2. Берәр сыйфатны яки дәрәҗәне белдерә (мәсәлән, укымышлы). **Галиму галәмә** — галимнәрнең дә иң укымышлысы, белемлесе, олысы. 3. Татар телендә *бигрәк тә, үтә дә, аеруча да* мәгънәсе белән гамәлгә кергән.
**Галәният** *г.* 1. Берәр нәрсәнең ничек ниятләнгән булса, шулай башкарылышы. Ничек карар кылынган, шулай эшләнү. 2. Ачыклык.

**Галəддəвам** (галə+дəвам) *г.* Дəвамлы рəвештə, бертоташтан, өзлексез.
**Галəйкем, галəйкүм** (галə+күм) *г.* Сезгə, сезнең өстегезгə.
**Галə кадəрит такать** *г.* Хəлендə, көчендə барынча.
**Галə көллит тəкъдир** *г.* Ничек кенə булса да, барлык очракта да.
**Галə көлли хəл** *г.* 1. Ничек кенə булса да, нинди генə халəттə дə. 2. Хəлең ничек дигəн сорауга җавап буларак та əйтелə (мəсəлəн, *халдə барынча.*).
**Галə əлиһи, вə əсхабиһи əҗмəгыйн** *г.* Барлык якыннарына һəм иярченнəренə дə.
**Галəме өнса** *г.* Хатын-кызлар, ханымнар дөньясы.
**Галəт тəгъйин** *г.* Билгелəнгəнчə, тəгаенлəнгəнчə.
**Гамамə** *г.* Чалма.
**Гами** *г.* 1. Халык, масса. **Лəһҗə гаммия** — **гади халык** сөйлəме. 2. **Гади, тупас, надан.**
**Гамикъ** *г.* Тирəн.
**Гамил** *г.* Эшче, эшлəүче.
**Гамир** *г.* 1. Халык урнашып яши торган, тормыш кайнап торган җир; эшкəртелгəн җир. 2. Эшкəртелгəн, чəчəк атып гөрлəп утыручы. 3. Бик яхшы, искиткеч.
**Гамир** *г.* 1. Ташып чыгу, мул. 2. Бушлык, эшкəртелмəгəн җир. 3. Су баскан, су астында калган; ком белəн капланган, ком астында калган.
**Гамькин** *г. ф.* Хəсрəтле, кайгылы, гамьле кеше.
**Гамəлият** *г.* Эшлəр, мəсьəлəлəр.
**Ганасыйр** *г.* 1. Элементлар. 2. Нəрсəнең дə булса бер өлеше. 3. Чыгышы, табигате, асылы. 4. Расачы. 5. Миллəтче.
**Ганасыйру əрбəга** *г.* Табигатьтəге дүрт элемент — җир, су, ут, һава.

**Ганбәр, гамбир** *г.* 1. Ислемай. 2. Амбар, сарай, саклау урыны. 3. Кашалот.

**Ганвә** *г.* Җәбер-золым, ирексезләү, мәҗбүр итү.

**Ганвән** *г.* Кемгә дә булса адреслау, адреслап яза башлау, мөрәҗәгать итү.

**Ганганә** *г.* 1. Хикәя кылу, берничә кешенең сүзенә таянып сөйләү. Сүзнең кешедән кешегә күчүе, тапшырылуы. 2. Үзеңнең чыгышың, нәсел-нәсәбең белән горурлану. 3. Төрле юк-барга ышану.

**Гандәлиб** *г.* Сандугач (күплек санда «ганәдилү»).

**Ганзә** *г.* Кәҗә.

**Гани** *г.* Бай, таза тормыш белән яшәүче, зур малга хуҗа булучы.

**Ганид** *г.* Үзсүзле, тискәре, тыңлаусыз, үҗәт, нык торучан.

**Ганимәт** *г.* Кулга төшерелгән мал, җиңел генә табылган мал. Трофей, табыш.

**Ганиф** *г.* Явыз, каты бәгырьле, ярсулы, курку белмәс, көчле.

**Ганка** *г.* Мифик кош исеме (грифон, феникс).

**Ганкәбут** *г.* Үрмәкүч.

**Гар** *г.* Тау куышы, мәгарә (күплек санда «әгъуар» яки «гийран»).

**Гараба** *г.* Арба, коляска, экипаж.

**Гараз** *г.* 1. Очраклы күренеш, очраклы рәвештә пәйда булу. 2. Тәкъдим. 3. Берәр нәрсәне күрсәтү, тәкъдим итү; күзәтү, аңлату.

**Гараз гаскәри** г. Хәрби парад.

**Гараис** *г.* Киленнәр (берлек санда «гарус»).

**Гарасат** *г.* 1. Каралты, йорт, ишегалды. 2. Мәйданчык.

**Гарб** *г.* 1. Көнбатыш. 2. Ерагаю, ераклык. 3. Кызулык, дәрт.

**Гареш** *г.* 1. Тәхет. Хитабел гарш — тәхеткә менү уңаеннан сөйләнә торган нотык, сүз. 3. Түбә, күк түбәсе.
**Гарэ** *г.* Киңлек. Хаттел гарэ — параллель; тулән вә гарзән — буйга һәм аркылыга.
**Гариб** *г.* 1. Ят, чит, таныш булмаган, билгесез. 2. Искиткеч; гаҗәеп кеше.
**Гарийбед дияр** *г.* Читтә яшәүче, ят илдә яшәүче.
**Гарийр** *г.* 1. Алданган. 2. Яшь, тәҗрибәсез.
**Гарийсә** *г.* Үсенте. Утыртырга әзерләнгән үсенте.
**Гарийә** *г.* Ялангач, ап-ачык, шәрә.
**Гарикъ** *г.* Чумган, баткан, батучы.
**Гарис** *г.* Кияү егете.
**Гарифә** *г.* 1. Белүче, хәбәрдар булган ханым. 2. Бүләк.
**Гарс** *г.* 1. Утырту, агач утырту. 2. Берәр гадәтне булдыру, бар итү.
**Гарше көрси** *г.* 1. Күк тәхете, тәңре тәгаләнең тәхете. 2. Гарше әгъляә — күкнең иң югары катламы. 3. Югарылык, биеклек, олуглык.
**Гарәкъ** *г.* 1. Тир, тирләү. 2. Исерткеч, аракы.
**Гарәфә** *г.* 1. Белү, тану. 2. Гарәфә көн — зөлхиҗҗә аеның тугызынчы көне. Бу көнне хаҗга килгән кешеләр Гарәфә исемле тауда уздыралар. (Гарәфә тавы Согуд Гарәбстанының Мәккә шәһәреннән ерак түгел урында).
**Гарәфетдин** *г.* Дингә кагылышлы мәсьәләләрне белүче, дин кануннарын аңлата белүче.
**Гаса** *г.* Таянып йөри торган таяк.
**Гасаб** *г.* Бәйләп тору, тоташтыру.
**Гасаби** *г.* Тиз кызып, кабынып китүчән, тәзгенсез.
**Гасыйб** *г.* Ата ягыннан булган туган.
**Гасыйб** *г.* (нокталы «гайн» белән языла). Талап алучы.
**Гасыйр** *г.* Җиләк-җимеш суы.

**Гасыйм** *г.* Яман эшләрдән саклаучы, туктатып торучы; туктатып торучанлык.
**Гасыйф** *г.* Көчле җил; давыллы, җилле һава.
**Гасәл** *г.* Бал.
**Гаталәт** *г.* 1. Эшсезлек. 2. Сүлпәнлек, инерция, үз агымында бару, хәрәкәт итү.
**Гаташ** *г.* Сусау, бик көчле эчәсе килү.
**Гатаэ** *г.* Берәр нәрсәне бирү, тапшыру, садака итеп бирү, бүләк итеп бирү.
**Гатикъ** *г.* 1. Азат итүче. 2. Җилкә. 3. Борынгы, иске. Әлбәйтүл гатикъ — Кәгъбә.
**Гаттар** *г.* Парфюмерия әйберләрен сатучы.
**Гатыйф** *г.* 1. Борылучан, үзгәрүчән. 2. Мәрхәмәтле, олы җанлы. 3. Тоташтырып, баглап торучы.
**Гатыйфәт** *г.* 1. Хис, тойгы. 2. Күңелгә ятышлы, хуш килү.
**Гатыр** *г.* Хуш исле май, бизәнү әйбере.
**Гаффар** *г.* Гафу итүче, кичерә алучы.
**Гауасат** *г.* Су асты көймәсе.
**Гаудәт** *г.* 1. Кире борылып кайту, яңарыш, яңадан торгызу. 2. Кабатлану, кабатланып тору.
**Гаун** *г.* (иганә) Ярдәм, булышлык. Би-гаунил лаһи тәгалә — олуг һәм бөек Аллаһының ярдәме белән.
**Гаурәт** *г.* 1. Түбәнге өлеш. 2. Йомшаклык, җитешсезлек. 3. Нәзберек, якланылмаган урын. 4. Җенес әгъзасы.
**Гафил** *г.* 1. Игътибарсыз, гамьсез. 2. Шапшак, сиземсез.
**Гафир** *г.* (Гаффар, Гафур, Гофран сүзләре дә шул ук мәгънәдә) Гафу итүче, ярлыкаучы, кичерүче, булган гөнаһларны ярлыкаучы.
**Гафиф** *г.* Саф, пакь, тыйнак, игелекле, абруйлы.

Гафият *г.* 1. Кунак булып килүче туташ, ханым. 2. Сәламәтлек, исәнлек, яхшы хис итү, куәтле булу.
Гафләт *г.* 1. Игътибарсызлык, ваемсызлык, саксызлык. 2. Искитмәү. 3. Аңсызлык.
Гашаэ *г.* Кичке аш.
Гашиканә *г.* Гашыйкларча, мәхәббәт утында янучылар дәрте белән.
Гашир *г.* 1. Унынчы тәртип саны. 2. Салым җыючы.
Гашия *г.* Кич, кичке вакыт.
Гашият *г.* 1. (Нокталы «гайн» белән языла). Япкыч, каплавыч. 2. Төркем, көтү. 3. Өянәк тоту. 4. Кайгы, хәсрәт. Әл-гашият — Мәетләрнең терелгән көне (Коръәннән алынган сүз).
Гашура *г.* Мөхәррәм аеның унынчы көне. Бу көнне Гали хәзрәтнең улы имам Хөсәеннең Кәрбәлә шәһәре янында шәһит китүе билгеләп үтелә.
Гаюр *г.* 1. Көнче, көнләшүче. 2. Тырыш, иҗтиһадлы, гайрәтле.
Гаят *г.* 1. Азак, кырый, чик, ахыр чик. 2. Максат, омтылыш, теләк. 3. Ният, уй-фикер.
Гаян *г.* Ап-ачык күренеп тора торган; билгеле.
Гаҗиз *г.* 1. Көчсез. хәлсез. 2. Хәлне, көчне югалту. 3. Сукыр.
Гаҗил *г.* Ашыгу. Хәзер үк, кичектергесез. Ин гаҗилән әү аҗилән — иртәме, соңмы.
Гаҗәба *г.* Ни гаҗәп; гаҗәп бит, әй; бик гаҗәп.
Гаҗәлә *г.* Ашыгычлык, тизлек.
Гаҗәләт *г.* Чүлмәк ясый торган тәгәрмәч.
Гаҗәләтүл-хәззаф *г.* Штурвал.
Гаҗәм *г.* Гарәп булмаган халыклар; фарсылар (иранлылар).
Гаҗүз *г.* Карт кеше.
Гаһед *г.* Вәгъдә, сүз бирү, өскә алу, килешү.

Гидай *ф.* Фәкыйрь, ярлы, хәерче, теләнче.
Гирьян *ф.* Елау. Үксеп елаучы.
Гобар *г.* Тузан.
Гобудият *г.* Коллык, бәйлелек.
Гобур *г.* Елга аркылы чыгу; кичү; урам аркылы узу.
Гозат *ф.* 1. Ислам дине өчен көрәшүче, мөрид. 2. Сугышчан рухлы.
Гозу *г.* Татар телендә бу сүзнең күплек сандагы «әгъза» шәкеле гамәлдә.
Голям *г.* Ир бала, малай.
Голяма *г.* Галимнәр.
Голәви *г.* Бөек; бөеклек, югары, күтәренке уйлар.
Гомдә *г.* 1. Нигез, терәк, таяныч. 2. Авыл старостасы. 3. Шәһәр шурасы әгъзасы.
Гоммаль *г.* Эшчеләр.
Гомран *г.* Эшкәртү, төзекләндерү. Мәдәният.
Гонуд *г.* Киреләнү, үҗәтләнү.
Гончә *ф.* Чәчәк бөресе, ачылмаган чәчәк.
Горуб *г.* Кояш бату.
Горуранә *г. ф.* Масайган хәлдә, тәкәбберләнеп, эреләнеп.
Горьян *г.* Ялангач, шәрә.
Госман *г.* 1. Гарәп хәлифе (644—655). 2. Төрек солтаннары династиясенә нигез салучы Госман (1299—1326). Бу династия Төркиядә 1925 нче елга кадәр хакимлек итте.
Госел *г.* Пакьләнү, юыну, коену.
Госер *г.* Кыенлык, авыр хәл, чарасызлык.
Гофунәт *г.* Черек исе. Черү, черек.
Грифтар *г.* 1. Тотылган, кулга төшерелгән. 2. Бик мәшгуль, эше күп булган кеше. 3. Әсирлеккә төшү, авыр, кыен хәлгә эләгү. 4. Берәр эш, уй-фикер белән янып йөрү. 5. Дучар ителү.
Гуаһ *ф.* Шаһит.

**Гукаб** *г.* 1. Бөркет йолдызлыгы. 2. Бөркет — Мөхәммәт пәйгамбәр байрагының исеме.
**Гыйбрани** *г.* Яһүд теле.
**Гыйддәт** *г.* 1. Күпмедер вакыт узу, сан. 2. Гыйддәтүлмәръә — ире үлгән яки иреннән аерылган хатынның никах яңартырга ярамаган вакыты.
**Гизаэ** *г.* Ризык, ашамлык, азык-төлек.
**Гыйзами** *г.* Бөек, затлы, олуг, зыялы, бик шәп.
**Гыйззәт** *г.* Дан, дәрәҗә, кадер-хөрмәт, горурлык.
**Гыйззәтү нәфс** *г.* 1. Үз-үзеңне ярату. 2. Сахибүл гыйзэзә — зыялылык. 2. Кыйммәтчелек.
**Гыйкаб** *г.* Җәза бирү, газаплау.
**Гыйлавә, гыйлауәт** *г.* Өстәмә, кушымта.
**Гыйлаҗ** *г.* 1. Дәвалау, төзәтү, чара, дару. 2. Реставрация.
**Гыйләт** *г.* Авыру, чир, сырхау.
**Гыйлҗ** *г.* 1. Ышанмаучы, динсез. 2. Тупас, кытыршы; әдәп кагыйдәләрен белмәүче.
**Гыйльме горуз, гаруз** *г.* Шигырь үлчәмен өйрәнә торган фән.
**Гыйльме кимия** *г.* Химия; химия фәне.
**Гыйльме нәбатәт** *г.* Үсемлекләрне өйрәнүче фән.
**Гыйльме нөҗүм** *г.* Йолдызларны өйрәнүче фән — астрономия.
**Гыйльметдин** *г.* Дин гыйлеме, дин турындагы фән.
**Гыйльмулла** *г.* Аллаһының гыйлеме.
**Гыймад** *г.* Таяныч, терәк, багана.
**Гыймарәт** *г.* 1. Үзләштерү, эшкәртү; эшкәртелгән җир. 2. Төзелеш. 3. Корылма, бина.
**Гыйнаять** *г.* Кайгыртучанлык, кайгырту, игътибарлы булу, ярдәм итү.
**Гыйндәннаси** *г.* Кешеләр янында (каршында).
**Гыйнәб** *г.* Йөзем.

**Гыйрафәт** *г.* Багучылык, күрәзәчелек, алдан белү.
**Гыйрфан** *г.* 1. Белем, аң. 2. Рәхмәтле булу, яхшылык өчен рәхмәт белдерү; мәмнүн булу.
**Гыйсави** *г.* Гайсә пәйгамбәргә ияручеләр, христианнар.
**Гыйсмәт** *г.* 1. Гөнаһсызлык, пакьлек, сафлык. Яхшылык эшләүче. 2. Муенса; мунчак.
**Гыйсъян** *г.* Баш күтәрү, чуалыш, буйсынмау, каршылык күрсәтү.
**Гыйтәб** *г.* Кисәтү, шелтәләү, әрләү, битәрләү, орышу.
**Гыйфрит** *г.* 1. Хәйләкәр (шайтан кебек). 2. Явыз, усал, мәкерле. 3. Дию パрие.
**Гыйффәт** *г.* 1. Яхшы, миһербанлы, саф, пакь, тыйнак. 2. Тыелып тору.
**Гыйш-гыйшрәт** *г.* Кәеф-сафа корып, гамьсез генә күңел ачып утыру, типтерү.
**Гыйшнуш** *г. ф.* Гамьсез гомер уздыру, типтереп яшәү, һәрвакыт эчеп, типтереп вакыт уздыру.
**Гыйшрәт** *г.* 1. Аралашу, дуслык, якынлык. 2. Кәеф-сафа кору.
**Гыядәт** *г.* 1. Авыруның хәлен белү, хәл белә бару. Яңадан бару, кабат-кабат бару. Кире борылып кайту. 2. Яңарыш. 3. Клиника.
**Гыял** *г.* Сабый, бала-чага.
**Гыяләт** *г.* Гаиләне карау, гаилә, өй җәмгате.
**Гяһ** *ф.* 1. Вакыт, мизгел, кайчакта. 2. Тәхет.
**Гяһ вә нәгяһ** *ф.* Вакытлы-вакытсыз.
**Гәзар** *ф.* Кишер.
**Гәзаф** *ф.* 1. Нигезсез, буш, мәгънәсез. 2. Зур, гадәттән тыш зур, чиксез.
**Гәзафе** *ф.* Ялган, арттырып сөйләү, нигезсез буш сүз.
**Гәп** *ф.* 1. Буш сүз сөйләү, лыгырдау. 2. Мактану. 3. Сүз, әңгәмә.

**Гәнҗ, гәнеҗ** *ф.* 1. Хәзинә, байлык. 2. Егет. 3. Җитлеккән, өлгереп җиткән.
**Гәүһәр** *ф.* Кыйммәтле таш, асылташ, ювелир әйберләре.
**Гөлзар** *ф.* Гөлләр, чәчкәләр үсә торган җир.
**Гөлчәһрә** *ф.* Алсу йөзле, гөлгә охшаш нәфис йөзле.
**Гөман** *ф.* 1. Фараз итү, дип уйлау, фикерләү. 2. Шикшөбһә.
**Гөнаһкяр** *ф.* Гөнаһ эшләүче, гаепле, җинаятьче.
**Гөраз** *ф.* 1. Кабан дуңгызы. 2. Батыр, кыю. 3. Сабанга охшаган җир сөрә торган эш коралы.
**Гөрг** *ф.* 1. Бүре. 2. Берәр эштә (яки уенда) башлап йөрүче. 3. Ут-суларны кичкән шома, хәйләкәр кеше.
**Гөруһ** *ф.* 1. Төркем, компания. 2. Халык массалары, өер.
**Гөстаһ** *ф.* 1. Тупас, дорфа, оялуны белмәүче. 2. Батыр, курыкмас.
**Гөфтагу** *ф.* 1. Кара-каршы сөйләшү (диалог). 2. Бәхәс, талаш, әйткәләшү.
**Гүаһ** *ф.* Шаһит.
**Гүгерд, гугәрд** *ф.* Күкерт.
**Гүл** *ф.* Ялган, афера.
**Гүлхор** *ф.* 1. Тиз ышанучан, гади, садә кеше. 2. Пешмәгән, җүләр, ахмак.
**Гүлзән** *ф.* Ялганлаучы, алдакчы, шома.
**Гүше** *ф.* 1. Почмак, тыныч урын. 2. Тел белән «чагып, чәнчеп» алу.
**Гүшә** *ф.* Колак.
**Гүя** *ф.* Нәкъ, әйтерсең, шикелле, имеш.
**Гүяндәги** *ф.* 1. Килешле, матур сөйләү. Оста теллелек. 2. Диктор.
**Гүяндә** *ф.* 1. Хикәя кылучы, сөйләүче. 2. Сирәк кенә «шагыйрь» мәгънәсендә кулланыла.

# Д (дәл)

**Даббәбәт** *г.* 1. Сөйрәлеп, шуышып йөрүче. 2. Танк, ташбака.

**Давхаһ** *ф.* 1. Үз теләге белән баручы. 2. Теләүче, кандидат.

**Давәр** *ф.* 1. Арбитр, хәким, судья. 2. Давәрә әгъзам яки давәрә асмон — барлык тереклек ияләрен хөкем итә алучы; тәңре.

**Дад** *ф.* 1. Тугрылык, гаделлек. 2. Ярдәм сорап ялвару. 3. Бүләк. 4. Кешенең яше.

**Даим** *г.* Һәрвакыт, бертуктаусыз, өзлексез.

**Даин** *г.* Әҗәткә биреп торучы. Кредитор.

**Даир** *г.* 1. Урап алу, ... тирәли әйләнеп йөрү. 2. Вакытывакыты белән.

**Даирә** *г.* 1. Түгәрәк сызык, түгәрәк әйләнәсе. 2. Түгәрәк божра, алка. 3. Өлкә, бүлек. 4. Әйләнә-тирә, мохит. 5. Оешма, идарә.

**Даирәи котбия** *г.* Котып түгәрәге.

**Дам** *ф.* Тозак; ау.

**Дамелля** *ф.* 1. Югары дәрәҗәле мөгаллим. Укытучыга олылап эндәшүнең бер төре. 2. Укымышлы, зыялы.

**Дана** *ф.* 1. Белүче, галим, укымышлы кеше. 2. Акыл иясе.

**Данешамуз** *ф.* Укучы, шәкерт, курсант.

**Данешгаһ** *ф.* Университет.

**Данешкадә** *ф.* Институт, югары уку йорты, факультет.

**Данешмәнд** *ф.* Белемле, гыйлемгә ия кеше.

**Данешъяр** *ф.* Югары уку йорты укытучысы.

**Данешҗу** *ф.* Югары уку йорты укучысы, студент.

**Данияр** *ф.* Белемне, гыйлемне яратучы. Акыл, зиһен белән эш итүне хуп күрүче.
**Данпәрәст** *ф.* Дан-шөһрәткә омтылучы, табынучы.
**Данә** *ф.* 1. Бөртек, орлык. 2. Данә (экземпляр).
**Дар** *г.* Йорт-җир; зур өй, торак урын; тору урыны; ил-йорт.
**Дар агачы** *г.* Асып үтерү җайланмасы (Җиргә утыртылган баганалар).
**Дарел бәка** *г.* Мәңгелек йорт; теге дөнья.
**Дарел гаҗизийн** *г.* Картайган кешеләр, зәгыйфьләр йорты.
**Дарел голүм** *г.* Фәннәр өйрәнелә торган йорт, югары уку йорты.
**Дарел фәна** *г.* Бетәчәк йорт, бетәчәк дөнья.
**Дарел фөнүн** *г.* Фәннәр академиясе.
**Дарчин** *г.* 1. Тәмләткеч уылма (корица). 2. Агач исеме.
**Дастан** *ф.* 1. Хикәят, тарих, роман, поэма, эпос. 2. Әкият.
**Дашад** *ф.* Бүләк, шатлык.
**Дахил** *г.* 1. Эчкә кереп баручы, катнашучы, тыкшынучы. 2. Эчке як, эчке өлеш.
**Дахилия назараты** *г.* Эчке эшләр министрлыгы.
**Даэ** *ф.* Авыру, чир.
**Дая** *ф.* Бала карачы, бала имезүче хатын.
**Даһи** *ф.* 1. Чиктән тыш булдыклы, талантлы; гений. Даһианә — даһиларча (гениаль). 2. Бик зиһенле, тапкыр.
**Дибаҗ** *ф.* Кыйммәтле ефәк тукыма, парча.
**Дибаҗә** *ф.* 1. Тышкы ягы, күренеше.
**Диван** *г.* 1. Шигырьләр тупламы, җыентыгы. 2. Дәүләт шурасы. 3. Диван. 4. Канцелярия.
**Дивана** *ф.* 1. Җүләр, акылсыз. 2. Гарәп телендә «таможня» мәгънәсен дә белдерә.
**Дивар** *ф.* Койма, дувал; читән белән урап алу.
**Дигәр** *ф.* 1. Башка, икенче берәү. 2. Тагын, яңадан.

**Дидар** *ф.* 1. Визит, килү. 2. Очрашу, күрешү. 3. Йөз, кыяфәт; өсте-башы, күренеше.
**Дидә** *ф.* 1. Күз. Күз алмасы, күз нуры. 2. Күрү, күз күргән.
**Дикъкать** *г.* 1. Төгәллек. 2. Игътибарлылык, зәвык, пөхтәлек. 3. Нечкәләп, тирәнтен уйлаучылык.
**Дил** *ф.* 1. Йөрәк, җан, күңел, акыл, бәгырь. Күңел түре, эчке дөнья. Диле вә җегәре белән — йөрәге һәм бавыры белән. Дәр һәр кяр дил лязым әст — һәр эшкә кыюлык һәм батырлык кирәк.
**Дилавәр** *ф.* 1. Батыр йөрәкле, курку белмәс, кыю. 2. Баһадир, батыр.
**Дилазар** *ф.* 1. Йөрәкне, бәгырьне телгәләүче, күңелне төшерүче, кәефне бозучы. 2. Рәнҗетүче, җәберләүче.
**Дилара** *ф.* 1. Җанны, күңелне сөендерүче, матур. 2. Яраткан, сөекле туташ, ханым.
**Дилбәр** *ф.* 1. Сөекле, яраткан хатын-кыз. 2. Бик матур, ягымлы, үзенә тартучан, нәзакәтле, җәзибәле, шаян.
**Дилдар** *ф.* 1. Сөекле, сөелгән. 2. Батыр, курку белмәс.
**Дилнәваз** *ф.* Ягымлы, сөйкемле, хәлгә керүчән, нәфис, йөрәкне тынычландыручы.
**Дилфикяр** *ф.* Сызланулы, әрнүле йөрәк; күңел сызлавы.
**Дилфруз** *ф.* 1. Күңелне күтәрүче, шатландыручы, җанга җылылык бирүче. 2. Гашыйк итүче.
**Дилхуш** *ф.* Шат күңелле, күтәренке күңел белән.
**Дилшад** *ф.* Шат күңелле, канәгать кеше.
**Динар** *г. ф.* Борынгы Юнандагы алтын акча исеме. Хәзерге вакытта Юнан, Гыйрак, Әлҗәзаир һәм кайбер башка дәүләтләрдә акча берәмлеге булып әйләнештә йөри.
**Диндар** *ф.* 1. Бурычы бар кеше. 2. Динле, дин юлында ихласлык белән тырышып хезмәт итүче.
**Динмөхәммәт** *г.* Мөхәммәт дине.

**Дираз** *ф.* Озын, озак, дәвамлы.
**Дираять** *г.* Белеп тору, белү, зирәклек, хәбәрдарлык.
**Диянәт** *г.* 1. Дин тоту. 2. Дин тәгълиматы. 3. Динлелек.
**Дияр** *г.* Ил-йорт... Диярыбызда — илебездә һ. б.
**Диһкан** *ф.* Игенче, авыл җирендә тереклек итүче, иген игүче һ. б.
**Дога** *г.* Өндәү, чакыру, теләү, ялвару, дога кылу.
**Дузәх** *ф.* Җәһәннәм, тәмуг.
**Дустанә** *ф.* Дусларча мөнәсәбәттә булу.
**Дәббаг** *г.* Тире иләүче.
**Дәва** *г.* Дару, савыктыру чарасы, им.
**Дәвер** *г.* 1. Әйләнү, бер тирәдә әйләнеп йөрү. 2. Вакыт, чор, заман. 3. Кабатланып тору. 4. Кат, катлам. 5. Роль.
**Дәгъва** *г.* 1. Чакыру. 2. Өндәү. 3. Үз хакыңны даулап хөкем оешмасына мөрәҗәгать итү.
**Дәгъвәтнамә** *г. ф.* Чакыру кәгазе.
**Дучар** *ф.* Бәлагә юлыгу, дучар булу.
**Дәкыйк** *г.* 1. Вак. 2. Төгәл, дөрес. 3. Тәфсилле, җентекләп, игътибар белән. 4. Четерекле, нәзберек. 5. Нәзек, нәфис, зәвыклы. 6. Тикшерүчән, вакчыл. 7. Он.
**Дәкыйка** *г.* 1. Минут. 2. Кисәк, өлеш. 3. Нечкәлек.
**Дәлил** *г.* Нигезләү, дәлилләү, фактлар белән күрсәтү.
**Дәляләт** *г.* 1. Күрсәтеп торучы билге: дәлил; раслану. 2. Күрсәтеп торучы сыйфат, билге, мәгънә.
**Дәм, дәммүн** *г.* Кан.
**Дәм** *ф.* Ял итеп алу, кыска вакытлы ял, дәм алу.
**Дәмгъ** *г.* (күплек санда дүмуг) Күз яше.
**Дәмин** *г.* Тәэмин итүче, гарантия бирүче.
**Дәний** *г.* 1. Якын, иң якын. 2. Түбән җанлы, кабахәт.
**Дәраһим** *г.* Дирһәмнәр (акча берәмлегенең күплек шәкеле).
**Дәрвазә** *ф.* Шәһәр капкасы.

Дәргяһ *ф.* 1. Капка төбе, бусага. 2. Тәрәзә төбе. 3. Керү урыны, сарай, торак җир.
Дәрига *ф.* Ни аяныч, ни үкенеч! Никадәр аяныч!
Дәрман *ф.* 1. Дәвалау. 2. Дару. 3. Әмәл, чара. 4. Көч-куәт.
Дәрхаль *ф. г.* Шунда ук, шул ук вакытта.
Дәрхакыйкать *ф. г.* Чынлыкта, дөресен әйткәндә.
Дәрья *ф.* 1. Диңгез. 2. Зур елга, су.
Дәрәхт *ф.* Агач, куак.
Дәссас *г.* 1. Интрига коручы, мәкерле. 2. Зәһәр елан.
Дәстемал *ф.* Тастымал, яулык, салфетка.
Дәстур, дустур *г.* Кануннар тупламы, кагыйдә, инструкция.
Дәстәрхан *ф.* Ашъяулык, эскәтер.
Дәфга *г.* Тапкыр, кабат.
Дәфен *г.* Җиргә иңдерү, күмү.
Дәхел (итү) *г.* Керү, кертү, керешү.
Дәшти *ф.* 1. Даланыкы, чүлнеке, кырныкы. 2. Кыргый. 3. Борынгы Иран классик музыкасының төре.
Дәүләт *г.* 1. Империя. 2. Дәүләтүн иттихадия — федератив дәүләт. 3. Татар телендә «мал», «байлык» мәгънәсендә дә кулланылышка кергән.
Дәҗҗал *г.* Ялганчы, аздыручы, шарлатан. Кешеләрне дөрес юлдан, диннәняздыручы.
Дәһр *г.* Дәвер, заман, бер гасырга карашлы.
Дәһри *г.* Алласыз, атеист.
Дәһшәт *ф.* Курку, өркү, шашып хәйран калу.
Дөбб *г.* Аю.
Дөкян, дүккән *г.* Кечкенә кибет.
Дөлдөл *г.* Мөхәммәт пәйгамбәрнең кияве Галигә бүләк иткән ат исеме.

**Дөньяви** *г.* Дөнья эшләренә караган, дөнья хәлләре белән бәйле.
**Дөньяпәрәст** *г. ф.* Дөньяны яратучы кеше.
**Дөррә** *г.* Энҗе.
**Дөрудгяр** *ф.* Балта остасы.
**Дөхтәр** *ф.* Кыз бала, кыз.
**Дөхән** *г.* Төтен, тәмәке.
**Дөхулия** *г.* Илнең чиген узган чакта яки берәр җиргә кергәндә түләнә, алына торган хак.
**Дүзәх** *ф.* Тәмуг, җәһәннәм.
**Дүн** *ф.* Түбән, юньсез, арзан, пәст.
**Дүшәмбе** *ф.* (дү+шәмбе) Шимбәдән соң икенче көн.

# З

Гарәп хәрефләренә нигезләнгән тарихи язуыбыз алфавитында дүрт шәкелдә языла торган «З» хәрефе бар. Алар сакау әйтелешле «зәл», «зә» һәм эмфатик хәрефләр гаиләсеннән булган «дад» яки «зад», «зый» хәрефләре. Бу хәрефләрнең һәрберсе үзенә генә хас сүзләр составында язылалар. Кирилл хәрефләренә нигезләнгән бүгенге көн татар алфавиты ярдәмендә бу гарәп хәрефләренең үзенчәлекләрен төгәл итеп белдерү мөмкин түгел. Татар телендә аларның дүртесе дә «з» хәрефе аркылы белдереләләр, ә язганда гарәп телендәгечә язылалар.

**Забит** *г.* 1. Буйсындыручы. 2. Кагыйдә, тәртип. 3. Офицер.

**Завия** *г.* Почмак.

**Задә** *г.* Бала; затлы, зыялы гаиләдә туган бала.

**Заегъ** *г.* 1. Югалган, бушка узган, әрәм булган. 2. Мескен, бәхетсез.

**Заид** *г.* 1. Ишәя, арта, күбәя бару, үсә бару. 2. Өстәмә. 3. Артык, чамадан тыш.

**Заир** *г.* Визит белән килүче, хәл белергә, күрешергә килүче.

**Зайк** *г.* Тарлык, тыгызлык, кысылган хәлдә, кризис.

**Закир** *г.* 1. Искә алучы, хәтергә төшерүче. 2. Дога укып Аллаһыны искә алучы.

**Залим** *г.* Рәнҗетүче, мәрхәмәтсез, шәфкатьсез, залим.

**Замир** *г.* 1. Вөҗдан, намус. 2. Акыл; эчтән фикер, серлелек. 3. Алмашлык (грамматик төшенчә). Замирүн ишарийүн — күрсәтү алмашлыгы.

**Замиру изафи** *г.* Исемнәрдә тартым кушымчасы.

**Заммә** *г.* 1. Үзеңә таба кысып китерү, кочаклау. 2. Җыелыш, берләшмә, бәйләм (гөл бәйләме). 3. Гарәп язуында (ярым) сузыкны, «у-ү» хәрәкәсен белдерүче хәреф өстенә куела торган тамга, билге.

**Зан итү** *г.* 1. Уйлау, ... дип исәпләү, шулайдыр дип уйлау, булуы ихтимал дип уйлау. 2. Шикләнеп карау, шөбһәләнү.

**Занийн** *г.* 1. Бик саран. 2. Бер тамчы гына, бик аз гына, җитәрлек түгел.

**Зарафәт** *г.* Үткен зиһенле, оста, җаен белеп эшләүче.

**Зарбел мәсәл** *г.* Берәр хикмәтле мәсәлгә, әйтемгә, мәкальгә нигезләп сүз әйтү, мисал китерү.

**Зарб** *г.* 1. Сугу, бәрү, кыйнау (мөһер сугу, акча басу). 2. Тапкырлау. 3. Төр, сорт.

**Зарбханә** *г. ф.* Акча баса торган йорт.

**Зари-зари** *ф.* 1. Аяныч, кызганыч, кызгандыра торган халәт. 2. Кычкырып, үксеп елау.

**Зар-интизар** *ф. г.* Еларга җитешеп көтеп тору; сабырсызлык, түземсезлек белән көтеп тору.

**Зариф** *г.* 1. Матур, көяз, чибәр, зәвыклы. 2. Үткен, фикерле, тапкыр сүзле. 3. Гаҗәпләндерә торган, кызыклы гына эшләр чыгаручы.

**Зарури** *г.* Кирәкле, мөһим булган нәрсә.

**Зарф** *г.* 1. Сыек матдә сала торган савыт. 2. Конверт. 3. Халәт, хәл, шарт.

**Зате галия** *г.* Югары дәрәҗәле, олы затлар, аксөякләр.

**Затән** *г.* Асылда, нигездә.

**Зауук** *г.* Терекөмеш.

**Зафәр** *г.* Җиңү, өстенлеккә ирешү, басып алу.

**Захик** *г.* Көлүче, көлеп торучы.

**Заһид** *г.* 1. Тыелып торучы, үзен бар нәрсәдән чикләүче. 2. Аскет.

**Заһир** *г.* 1. Ап-ачык күренеп тору. 2. Тышкы ягы.

**Заһирән** *г.* Тыштан, тышкы яктан.

**Зиба** *ф.* Матур, гүзәл, күркәм, зиннәтле.

**Зикер** *г.* 1. Искә алу. 2. Хәтердә, истә калганнар. 3. Дан. 4. Аллаһының исемен искә алу, дога уку.

**Зикрү бил-хәйри** *г.* Яхшылык белән искә алу.

**Зикрү җәмил** *г.* Яратып, җылы итеп искә төшерү, уңай яктан искә алу. Матур хатирәләр.

**Зилкагдә, зөлкагдә** *г.* Мөселман календареның унберенче ае (утыз көннән гыйбарәт).

**Зилзилә** *г.* Тетрәү, селкенү.

**Зилхиҗҗә, зөлхиҗҗә** *г.* Мөселман календареның уникенче ае.

**Зинакяр** *ф.* Бозык эш эшләүче, зиначы.
**Зиндан** *г.* Төрмә.
**Зиндийкъ** *г.* Динсез, еретик.
**Зиндәги** *ф.* Тормыш, тереклек.
**Зиннәт** *г.* Бизәк, матурлык, гүзәллек. Яхшылык.
**Зинҗи** *г.* Кара тәнле кеше.
**Зинҗир** *г.* Чылбыр, богау.
**Зирагать** *г.* 1. Җир эшкәртү, игенчелек. 2. Чәчү, утырту, үстерү. 3. Авыл хуҗалыгы.
**Зир-зәбәр** *ф.* Асты-өскә.
**Зифаф** *г.* Кияүнең кәләше янына керү киче.
**Зиәб** *г.* Бүре.
**Зиядә** *г.* Ишәю, арту, күбәю.
**Зиярәт** *г.* 1. Бару, зиярәт кылу (визит). 2. Хаҗ кылу. 3. Татар телендә *каберстан, зират* мәгънәсендә гамәлдә.
**Зиһен** *г.* Хәтер, аң, истә тоту.
**Зобани** *г.* 1. Җәһәннәмдәге гаскәриләр, шайтаннар, җеннәр. 2. Сатлыкҗаннар, ялчылар.
**Зогафа** *г.* 1. Хәлсезләр, көчсезләр, авырулар. 2. Зәгыйфүл кальб — түбән җанлы, куркак, авыру кеше.
**Золым, золем** *г.* 1. Гаделсезлек, изеп, җәберләп тору; тирания. 2. Гаделсез булу, рәнҗетү, кысу.
**Золмәт, золәм** *г.* Караңгылык.
**Золямият** *г.* Тиранлык.
**Зоһур** *г.* 1. Барлыкка килү, пәйда булу. 2. Арка як, арка өлеше, арткы якта. 3. Көн уртасы, төш вакыты. 4. Килеп чыгу, беленү, күренү.
**Зыйд** *г.* 1. Каршы булу, көндәш булу. 2. Капма-каршылык.
**Зыйл** *г.* 1. Күләгә, ышык. 2. Дәвамлылык. Күләгәдә калып килү.

**Зымна** *г.* 1. Эчендә, эчке өлешендә, эчтә. **Дәүләтүн зымна дәүләтин** — дәүләт эчендәге дәүләт. 2. Эчтәгесе, яшерелгәне, эчке якта булганы.
**Зыяфәт** *г.* Кунак итү, кунакчыллык, ачык күңеллелек.
**Зәбан** *ф.* Тел, сүз.
**Зәбане гавам** *ф. г.* Халык теле, гавам теле.
**Зәбани мадәри** *ф.* Ана теле.
**Зәбанавәр** *ф.* Матур, үткен, оста телле.
**Зәбанбаз** *ф.* 1. Ялганчы, күз буяучы, шарлатан. 2. Кызыктыру, ияртү. 3. Ялагай.
**Зәбур** *г.* Борынгы яһүд телендә язылган китап. Бу китап Дауд пәйгамбәргә Аллаһы тәгалә тарафыннан иңдерелгән дип риваятьләнә.
**Зәбиб** *г.* Киптерелгән тешсез йөзем.
**Зәҗаҗ** *г.* Пыяла, шешә, тәрәзә пыяласы.
**Зәгъфран** *г.* Хуш исле сары төстәге үсемлек, шафран.
**Зәгыйфь** *г.* Гарип, көчсез, хәлсез, дәрмансыз.
**Зәйнетдин** *г.* Диннең бизәге, матурлыгы.
**Зәйни** *г.* Матур, күркәм, бизәп торучы.
**Зәйнулла** *г.* Аллаһының яхшы кешесе.
**Зәет** *г.* Үсүчән, үсешкә йөз тотучы, арта бару.
**Зәйтүн** *г.* Агач. Бу агачның урман чикләвеге зурлыгындагы яшел яки шәмәхә карасу төстәге җимешеннән май сыгып алына.
**Зәки** *г.* Пакь, ару, гаепсез.
**Зәкий** *г.* 1. Үткен, зирәк. 2. Акыллы, булдыклы. 3. Татлы, тәмле.
**Зәкъкум** *г.* 1. Тәмуг агачы 2. Кыргый зәйтүн агачы.
**Зәкят** *г.* 1. Пакьлек, сафлык. 2. Фәкыйрьләр файдасына байларның керемённән түләнергә тиешле салым.
**Зәкәрия** *г.* Чын ир-егет.

**Зәмзәм** *г.* 1. Мул, тулы. 2. Мәккә шәһәрендә Кәгъбә янындагы изге коеның исеме.
**Зәмзәми** *г.* Мәккәдәге су ташучы.
**Зәмзәмия** *г.* 1. Су сала торган савыт. 2. Дөя карындыгыннан ясалган су тутырып ташый торган капчык.
**Зәмил** *г.* Юлдаш, иптәш, бергә эшләүче, кулдаш.
**Зәмин** *ф.* Җир, туфрак.
**Зәмстан** *ф.* Кыш.
**Зәмһәрир** *г.* Көчле салкын, җелеккә төшүче суык.
**Зән** *ф.* Хатын-кыз, хатын.
**Зәнәдика** *ф.* 1. Мани тәгълиматына иярүчеләр, манихейләр. 2. Динсез, алласызлар.
**Зәнб** *г.* 1. Гөнаһ. 2. Гаеп. 3. Җинаять.
**Зәнбур** *ф.* Шөпшә.
**Зәнҗи, зәнки** *г.* Кара тәнле кеше, негр.
**Зәнҗәбил** *ф.* Имбирь (яки шул үсемлек тамырыннан ясала торган он).
**Зәргәр** *ф.* Алтынчы, алтын-көмештән бизәнү әйберләре ясаучы, ювелир.
**Зәхмәт** *ф.* 1. Хезмәт, тырышлык, иҗтиһадлык. 2. Авырлык, кыенлык; тынычсызлык.
**Зәүәл** *г.* 1. Көн уртасы. 2. Кояш баткан чак, кич.
**Зәвык, зәүкъ** *г.* 1. Тоя, таный белү. 2. Аера белү, зәвык.
**Зәүра** *г.* Көймә, каек; катер.
**Зәүҗ** *г.* 1. Өйләнгән ир кеше. 2. Пар, җөп сан.
**Зәүҗә** *г.* Ирдәге хатын, хатын-кыз.
**Зәһәб** *г.* Алтын, алтыннан ясалган.
**Зөбәрҗәт** *г.* Яшел төстәге кыйммәтле асылташ.
**Зөкак** *г.* Урам, тыкрык.
**Зөкям** *г.* Салкын тию, томау төшү.

**Зөлкарнәйн** *г.* Ике мөгезле. Искәндәр патша (А. Македонскийның кушаматы).
**Зөлфикар** *г.* Мөхәммәт пәйгамбәрнең Бәдер янындагы сугышта кулга төшергән кылыч исеме. Соңыннан бу кылыч хәзрәти Галигә кала.
**Зөмрә** *г.* Төркем, өер, группа. Катлам, класс.
**Зөннун** *г.* Уйлар, фикерләр. Ялгызлык исеме.
**Зөфәр** *г.* Җиңүгә ирешүче, үз дигәнен эшли торган, теләгенә ирешүче.
**Зөһд** *г.* Тәкъвалык, суфилык, тыелып тору.
**Зөһрә** *г.* 1. Төс. 2. Гөл. 3. Иң яхшы вакыт, чәчәк аткан чор. 4. Зөһрә йолдызы.
**Зүф** *г.* Көч-хәл белән сөйрәлеп килү.

## И

**Ибгадь** 1. Ераклаштыру, читләштерү. 2. Аерып кую. 3. Сөрү, сөргенгә озату.
**Ибдаг** *г.* Бар итү, иҗат итү.
**Ибдаэ** *г.* Беренче булып башлау, башкару, иҗат итү.
**Ибдәл** *г.* Алмаштыру, үзгәртү, алмашу.
**Ибка** *г.* 1. Калдыру, саклау. 2. Шәфкатьлелек, миһербанлылык күрсәтү.
**Иблис** *г.* Шайтан, аздыручы.
**Ибляг** *г.* Җиткерү, ирештерү.
**Ибне әүи, ибне ави** *г.* Шакал, чүл бүресе.

**Ибнел вакыт** *г.* Замана баласы, үз чорының баласы.
**Ибнес сәбийли** *г.* Юлчы, юлдагы кеше.
**Ибрам** *г.* Килешү төзү, раслау, әйләндерү, урап кую, беркетеп кую (имзалау).
**Ибрикъ** *г.* Комган, чәйнек, су чүлмәге.
**Ибрә** *г.* Инә.
**Ибталь** *г.* Кире кагу, юкка чыгару, юк итү.
**Ибтида** *г.* Башлау, башлап җибәрү, керешү.
**Ибтидаи** *г.* Башлангыч (мәктәп).
**Ибтиляә** *г.* 1. Сынап карау, сынау. 2. Бәхетсезлек. 3. Җәза бирү, җәзалау.
**Ибтинаә** *г.* Төзү; яшь киленне өйгә төшерү.
**Ибтисам** *г.* Елмаю, көлемсерәү, елмайган булып кылану.
**Ибтисар** *г.* Тирәнтен аңлап эш итү; ерактан күрә, таный белү; белергә тырышу.
**Игадә** *г.* Кабатлау, кире кайтару; яңарту, яңабаштан эшләү.
**Иганә** *г.* Ярдәм итү, булышу, акчалата ярдәм итү.
**Игъва** *г.* 1. Котырту. 2. Кызыгу, нәфескә хуҗа булмыйча кызыгу, ияреп китү.
**Игъдад** *г.* Әзерлек, әзерләү.
**Игъдадия** *г.* Хәзерлек сыйныфы.
**Игъдам** *г.* Үлем җәзасы.
**Игъзаз** *г.* Ярату, хөрмәтләү, олылау.
**Игъзам** *г.* Олылау, зурлау, хөрмәт итү, мөһим дип санау.
**Игълякъ** *г.* 1. Ябу, бикләп кую. 2. Бутап сөйләү.
**Игъмаль** *г.* Эшләү, ясау, барлыкка китерү.
**Игърак** *г.* 1. Батыру, чумдыру; су басу. 2. Күпертү, арттырып сөйләү.
**Игъта** *г.* Бирү, өләшү, тәкъдим итү (бәя бирү).
**Игътидал** *г.* 1. Төз булу, туры булу. 2. Урталыкта булу; тигезлек. 3. Ике якның да бер үлчәмдә булуы.

**Игътизар** *г.* 1. Гафу үтенү. 2. Аклану. Язма рәвештә берәр эшнең, рәвешнең сәбәбен тәфсилләп аңлату, ачыклап күрсәтү.

**Игътикад** *г.* Ышану, инану.

**Игътикяф** *г.* 1. Өйдә генә утырып тору, беркая да чыкмау. 2. Берәр нәрсәгә яки кемгә дә булса тулысынча ышану. Мөкиббән китеп ышану.

**Игътимад** *г.* 1. Ышану, ышаныч. 2. Таяныч, нигез (ләнү). 3. Раслау, (имза салып) санкция бирү. 4. Нинди дә булса карарга, күрсәтмәгә һ. б. нигезләп, ышанып кредит ачу. Ассигнацияләү.

**Игътираб** *г.* Туган-үскән җирдән еракта яшәү. Туган илдән еракка китү.

**Игътираз** *г.* 1. Юлга аркылы төшү. 2. Нинди дә булса эшкә яки башлангычка аркылы төшү, каршылык күрсәтү, протест белдерү.

**Игътираф** *г.* 1. Тану. 2. Тәүбә итү, эшләгән эшне тану.

**Игътисаб** *г.* 1. Тартып алу, талау, җәберләп, көч белән берәр нәрсәгә хуҗа булу. 2. Көч кулланып өстенлеккә ирешү.

**Игътисал** *г.* Юыну, пакьләнү, госел коену, тәһарәт алу (пакьләнү, чистарыну).

**Игъфаль** *г.* 1. Гафиллек, игътибарсызлык, битарафлык. 2. Тиеш булганча эшләмәү, нәрсәгә дә булса салкын карау; булса ярый, булмаса да хуп дип санау; җаһиллек.

**Идамә** *г.* Дәвамлы итү, озайту, сузу.

**Идбар** *г.* Чигенү, артка таба китү, арка белән борылу («тәдбир» не кара).

**Иддигаэ** *г.* 1. Раслау, инандыру. 2. Дәгъва белдерү, даулау, таләп итү. 3. Хаксызга дулау, таләп итү. 4. Үз-үзеңне һавалы тоту, әллә кемгә кую.

**Идрак, идрәк** *г.* 1. Берәр нәрсәгәирешү. 2. Аңлау, күңел белән кабул итү. 3. Аң, уй, кабул итүчәнлек, кабул итә белү, төшенеп җитү. 4. Өлгереп җитү, балигъльгкка ирешү.
**Идхал, идхәл** *г.* Кертү, ирештерү, тоташтыру, уздыру, тыгу.
**Изафә** *г.* 1. Тоташтыру, өстәү, кушу, өстәмә кертү. 2. Иялек килешендәге исем белән белдерелгән аергычның аерылмышка мөнәсәбәте.
**Изафәтән иләйһи** *г.* Моңарга, шуңарга өстәп.
**Изах** *г.* Аңлату, төшендерү, ачыклау.
**Издиваҗ, издиваҗ** *г.* 1. Парлашу, берләшү. 2. Өйләнешү.
**Изен** *г.* 1. Рөхсәт бирү. **Бизниллаһи** — Аллаһының рөхсәте белән. 2. Ордер, лицензия.
**Изкяр** *г.* Искәртү, хәтерләтү.
**Израр** *г.* Зыян салу, зарар китерү, мәҗбүр итеп эшләтү.
**Изтыйраб** *г.* 1. Дулкынлану, борчылу. 2. Тәртип бозу, буталыш, бәрелеш китереп чыгару, тавыш куптару, стачка.
**Изһар** *г.* Ачып күрсәтү, ачыклау, аныклау.
**Иказ** *г.* 1. Күтәрелеш, уяну. 2. Искә төшерү, белдерү.
**Икамә** *г.* 1. Торгызу, күтәрү. 2. Билгеләү. 3. Башкару, булдыру, эшләү. 4. Бер урында яшәү.
**Икмаль** *г.* Тәгәлләү, башкарып чыгу, эшләп бетерү, камилләштерү.
**Икрам** *г.* Хөрмәт; мактау, олылау.
**Иксир** *г.* Шифалы тамчы, эликсир.
**Иктисаб** *г.* 1. Казану, табу, булдыру, табып алу. 2. Отыш.
**Иктифәә** *г.* Канәгатьләнү, җитеш булу.
**Икъбал** *г.* 1. Алга китү, алга чыгу, алга бару. 2. Кабул итү, очрашу. 3. Вакытның килеп җитүе, якынаюы. 4. Уңыш, бәхет; барысына да өлгерү, бик өлгер булу.

**Икъдәм** *г.* 1. Берәр эшне башкарырга керешү, эшли башлау, башлап җибәрү. 2. Батырлык, кыюлык.

**Икъдәр** *г.* Булдыра алу, көч җитү, кулдан килү.

**Икълим** *г.* 1. Климат. 2. Өлкә, район, территория.

**Икънаг** *г.* Канәгатьләндерү, ризалаштыру.

**Икърар** *г.* 1. Рөхсәт итү, урнаштыру. 2. Тынычландыру, раслау. **Әссүкүт минәл икърар** — дәшми тору, риза булуны аңлата.

**Икътисад** *г.* 1. Экономика, хуҗалык. 2. Тота белеп тоту, сакчыллык, бәрәкәтле итеп файдалана белү.

**Икътисам** *г.* Бүлү, бүлгәләү, бүлешү, өлешләү.

**Икътисар** *г.* 1. Кыскарту, чикләү. 2. Кыскача. **Биликътисар** — кыска гына итеп, кыскача.

**Илаһ** *г.* Аллаһ, тәңре.

**Илаһият** *г.* 1. Теология мәсьәләләре, проблемалары. 2. **Илаһият факультеты** — дини фәннәрне үзләштерү факультеты. Аллаһыга, дингә караган гыйлемнәр.

**Илзам** *г.* (Лазимә-лузүм) Вазифаны кушу, җаваплы итү, башкарылырга тиешлекне аңлату.

**Иллә** *г.* Әгәр дә юк икән..., ул чакта, ул вакытта башка («ин» теркәгече һәм юклыкны белдерүче «лә» кисәкчәсе берләшеп ясала).

**Илтизам** *г.* Үз өстенә алу, тиешле дип табу. Җаваплылык, бурыч.

**Илтика** *г.* 1. Очрау, каршы алу, юлыгу. 2. Очрашып тору, кушылу, берләшү, кавышу.

**Илтимас** *г.* Үтенеч; инәлеп сорау; булсын дип берәр эшнең артыннан йөрү.

**Илтифат** *г.* 1. Борылып карау, игътибарлы булу. 2. Кызыксыну, ягымлы булу. 3. Хөрмәт күрсәтү, олылау, илтифатлы булу.

**Илтихак** *г.* Тоташтыру, кушу, килеп кушылу.
**Илтиһаб** *г.* Шешү, ялкынсыну, җилсенү, пешегү.
**Илһам** *г.* Илһам килү, күңел күтәренкелеге. Илаһи көч белән күңелгә — дәрт, җанга, тәнгә — сихәт, күтәренкелек, хозурлык иңгән чак.
**Имам** *г.* 1. Җитәкче, баш кеше, даһи. 2. **Имамүл** әкбәр — Каһирәнең әл-Әзһәр мөселман университетындагы гыйльми дәрәҗә, шәех.
**Имамү кыйблатәйн** *г.* Ике кыйбланың да имамы (Мәккәнең һәм Әл-Кодеснең).
**Иман** *г.* Ышану, инану.
**Имин** *г.* Куркынычсызлык, тынычлык, ышанычлылык, саф күңеллелек.
**Имкян** *г.* Мөмкинчелек, булдыра алу.
**Имля** *г.* 1. Әйтеп яздыру, диктант. 2. Дөрес язу, орфография.
**Имраәт** *г.* Хатын-кыз.
**Имсәк** *г.* 1. Саранлык. 2. Тыелып тору, баш тарту. 3. Рамазан аенда уразага керү көне. 4. Медицинада «эч кату» мәгънәсендә кулланыла.
**Имтидад** *г.* Озынлык, билгеле бер урынга кадәр сузылган булу, дәвамлылык.
**Имтинан** *г.* 1. Җаваплылыкны тою. 2. Берәүнең кылган яхшылыгы өчен рәхмәт белдерү, мәмнүн булу. 3. Миннәтдар булу, рәхмәтле булу.
**Имтихан** *г.* Сынау, сынап карау.
**Имтияз** *г.* 1. Аерымлык, аерма. 2. Өстенлек.
**Инабәт** *г.* 1. Вәкаләтне бирү, вәкил итеп җибәрү. Берәүне үз урыныңа вәкил итеп, ышанып җибәрү. 2. Ярлыка дип ялвару.
**Ингам** *г.* 1. Бүләкләү, бүләк бирү, яхшылык белән кайтару. 2. Игътибарлылык, тырышлык.

**Ингыйкад** *г.* Утырыш, чакырылыш, килешү белән беркетү, договор.
**Ингыйтаф** *г.* 1. Читләшкән булу, борылыш, авышканлык. 2. Бөгелгән булу, бөгелү. Юлда барганда кайсыдыр тарафка борылу, борылыш ясап «сутылып» чыгу.
**Инзәл** *г.* 1. Индерү, төшерү. 2. Урнаштыру, китереп утырту (яшәү, тору өчен). 3. Түбәнәю, арзанаю. 4. Иңү, югарыдан иңү.
**Инзәр** *г.* Белдереп кую, кисәтеп кую, сакланырга кирәклекне алдан кисәтеп кую.
**Инкаль** *г.* 1. Күченү, күчү, хәрәкәткә килү, китеп бару. 2. Үлү, ахирәткә күчү.
**Инкисәр** *г.* 1. Сыну, ватылу. 2. Буйсынучанлык, йомшап калу, буйсыну.
**Инкыйлаб** *г.* 1. Әйләнү, үзгәрү, алмашыну. 2. Хөкүмәт алмашыну, революция.
**Инкыйраз** *г.* 1. Тукталу. 2. Үлеп юкка чыгу, сүнү, яшәүдән туктау, нәсел киселү, бетү.
**Инкяр, инкарь** *г.* Инкяр итү, юк дип раслау, кире кагу, танымау.
**Инсан** *г.* Кеше, адәм баласы.
**Инсаният** *г.* Кешелек дөньясы.
**Инсаф** *г.* Гаделлек, гадел хөкем.
**Интаҗ** *г.* 1. Эшләп чыгаручы оешма. 2. Эшләп чыгарылган әйбер, эшнең нәтиҗәсе.
**Интизам** *г.* Тәртип, дөреслек, рәтле булу, кагыйдә буенча эшләү.
**Интизар** *г.* Көтеп тору, зарыгып көтеп тору.
**Интисар** *г.* Җиңү, триумф.
**Интисәр** *г.* Чәчелү, сибелү, таркалу.
**Интишәр** *г.* 1. Таралу, таралучанлык. 2. Билгелелек.

**Интиһаэ** *г.* Азагы, соңы, тәмам булу, чик.
**Интыйбаг** *г.* 1. Тәэсир калу (уңай яки тискәре фикер калу). 2. Басылып чыгу, басылган булу.
**Инфирад** *г.* 1. Йомылып, ялгыз яшәү. 2. Ялгызлык.
**Инфисаль** *г.* 1. Аерылу, бүленеп чыгу. 2. Калдырып китү, әгъзалыктан чыгу (берәр фиркадән, партиядән).
**Инфиҗар** *г.* 1. Шартлау, чәчелеп шартлау. 2. Атылып чыгу (вулкан).
**Инхираф** *г.* Тайпылу, авышу, читкә тайпылу.
**Инша** *г.* 1. Барлыкка китерү, кору, төзү. 2. Төзү, язу (инша, диктант).
**Иншалла** *г.* Аллаһ кушса, боерса, теләсә.
**Инҗил** *г.* Евангелие китабы.
**Ирадә** *г.* 1. Теләү, омтылу. 2. Ихтыяр көче, ирадәлек.
**Ирсәл** *г.* 1. Җибәрү (хат, бүләк). 2. Радиотапшыру; нәрсәгә дә булса ирек кую.
**Иртибат** *г.* Бәйләнешлек, элемтә.
**Иртидад** *г.* 1. Чигенү, кайту. 2. Төшеп калу, тоткан юлны үзгәртү, алыштыру (динне).
**Иртифаг** *г.* 1. Күтәрү, күтәрелү, менү. 2. Биеклек, югарылык.
**Иртихал** *г.* 1. Күчеп китү, күчү. Иртихалә илә рәхмәти раббиһи — Раббысының карамагына күчте; үлде, дөньядан күчте мәгънәсендә.
**Ирфәгъ** *г.* Күтәр, менгер, алып мен (боерык фигыль шәкеле).
**Иршад** *г.* Юлга салу, күрсәтмә-инструкция, юл күрсәтү.
**Исгад** *I г.* Бәхетле итү, баету.
**Исгад** *II г.* Югары күтәрү, югарыга тарту, менгерү.
**Искат** *г.* 1. Санап киметү, ташлама ясау, төшерү. 2. Өстеннән алып ташлау. 3. Йөк төшерү (аборт)
**Искәндәр** *г.* Патша, Александр Македонский.

**Ислам** *г.* Үзеңне Аллаһыга тапшыру, буйсыну.
**Ислах** *г.* 1. Яхшырту, төзәтү. 2. Үзгәртеп кору, реформа.
**Исмаг** *г.* Тыңла, ишет (боеру).
**Исме аләт** *г.* Эш кораллары (исемнәре).
**Исме гадәд** *г.* Саннар.
**Исме гадәд тәртиби** *г.* Тәртип саннары.
**Иснад** *г.* 1. Таяныч, терәк. 2. Дәлил, раслаучы факт. 3. Чыганак.
**Исраг** *г.* Тизләтү, ашыктыру.
**Исрар** *г.* Үз дигәнендә нык торучанлык. Ныклык, катылык.
**Исрафил** *г.* Кыямәт көненең килүе турында хәбәр бирүче фәрештә.
**Истибгадь** *г.* 1. Ераклашу, ерагаю, ерак дип санау. 2. Мөмкин түгел дип санау. 3. Ераклаша бару, югалу.
**Истибдад** *г.* Канунга буйсынмыйча үз белдегең белән эш йөртү, башбаштаклык.
**Истива, истиуа** *г.* Тигез, бертигез хокукта, дәрәҗәдә булу.
**Истигарә** *г.* 1. Бурычка алып тору. 2. Метафора.
**Истигъдад** *г.* 1. Әзерлек, әзер булу. 2. Тумыштан булган сәләт, булдыклылык.
**Истигъмаль** *г.* Куллану, файдалану, гамәлдә булу.
**Истигънәэ** *г.* Игътибарлы булу, карап, ярдәм итеп, булышып тору.
**Истигънаэ** *г.* Бай булу, мохтаҗ булмау.
**Истигърак** *г.* 1. Чуму, бату, (йокыга) талу. 2. Чаманы, чикне белмәү.
**Истигъфар** *г.* Ялваруны, кичерүне, гафу итүне, ярлыкауны сорау.
**Истигъҗаль** *г.* Ашыгу, кабалану, ашыгып эшләү.
**Истикамәт** *г.* 1. Дөреслек, турылык, хаклылык, намуслылык. 2. Торып басу, тураю.

**Истикбәр** *г.* 1. Масаю, һавалы булу, үзеңне югары тоту, тәкәбберләнү. 2. Мөһим дип санау.

**Истикмәл** *г.* 1. Тулылык, мөкәммәллек. 2. Төгәлләү, тәмамлау, ахырына кадәр эшләү.

**Истикъбаль** *г.* Кабул итү, каршылау; киләчәк.

**Истикълял** *г.* Бәйсезлек, мөстәкыйльлек, үзидарә.

**Истикърар** *г.* 1. Хәрәкәтсезлек. 2. Тотрыклылык, нык-лылык, бер җирдә төпләнеп калу.

**Истиляэ** 1. Ия булу, басып алу. 2. Кулга алу (эш хакын). 3. Тартып, талап алу.

**Истимдәд** *г.* Ярдәмгә чакыру, ярдәм сорау.

**Истимляк** *г.* Кулга төшерү, ия булу, үзенеке итү, үзләштерү, хуҗа булу.

**Истимрар** *г.* Дәвамлылык, өзлексез, бертоташтан.

**Истимтар** *г.* 1. Яңгыр теләү, ялвару. 2. Чакыру, өндәү; миһербанлы, шәфкатьле булырга өндәү.

**Истинәд** *г.* Таяныч, терәк, ярдәмле булу. Таянып, нигезләп аңлату, дәлилләү.

**Истинсәх** *г.* 1. Күчереп яздырырга тырышу. 2. Нөсхә ал-дыру, ишәйтү, күбәйтү.

**Истинтәҗ** *г.* Нәтиҗә, йомгак ясау, йомгаклау.

**Истинҗа** *г.* Юыну, пакьләнү, нәҗестән арыну.

**Истирахәт** *г.* 1. Ял итү, хәл алу. 2. Тынычлану, тыныч-лык, рәхәтлек. 3. Бер эшне башкарганда кыска вакытка тук-талып тору, хәл җыеп алу, тәнәфес ясап алу, пауза. 4. Сәя-хәтчеләр өчен кунакханә, ял йорты, отель.

**Истифадә** *г.* Берәр эштән, кәсептән файда күрү.

**Истифсар, истифсәр** *г.* Сорап белү, сораттыру. Берәр кеше яисә эш хакында мәгълүмат туплау максаты белән мөрәҗәгать итү.

**Истифһәм** *г.* Сорап белү, аныклау, ачыклау, белешү.

**Истихбар** *г.* Сорашып мәгълүмат җыю, белешү.

**Истихдам** *г.* 1. Хезмәткә, эшкә кабул итү. 2. Файдалану, куллану. 3. Эш, хезмәт.

**Истихкар** *г.* Хурлау, түбәнсетү, кимсетү, хәкарәт итү.

**Истихкям** *г.* 1. Ныгыту, чыдамлы итү. 2. Хәрби ныгытма.

**Истихраҗ** *г.* 1. Суыртып чыгару, тартып чыгару. 2. Сыгып чыгару. 3. Нәтиҗә ясау, чыгару.

**Истихсаль** *г.* Тырышып мал табу, хасил итү, булдыру.

**Истихсан** *г.* 1. Хуплау, яхшы дип табу, мактап кую. 2. Кирәк дип санау, табу.

**Истихфаф** *г.* Җиңел дип санау, әһәмият бирмәү, җиңелчә генә карау, игътибарсыз булу. Салкын карашта булу. Көлеп, түбәнсетеп карау.

**Истишарә** *г.* Киңәш сорап мөрәҗәгать итү, киңәшләшү.

**Истишһәд** *г.* 1. Шаһит итеп файдалану, китерү, нигезләп әйтү, таянып әйтү (цитата). 2. Үлү, корбан булу (дин өчен, дөреслек өчен, берәр төрле идея өчен һ. б.). Зур газаплар чигеп үлү, шәһит булу.

**Истиҗабә** *г.* 1. Башкару, эшләү, үтенечне канәгатьләндерү. 2. Туры килү, ярашлы булу, уңай җавап бирү.

**Истиҗазә** *г.* Рөхсәт алу.

**Истиһзау** *г.* Көлү, мыскыл итү, хурлау.

**Истиһляк** *г.* 1. Куллану, сарыф итү, тоту. 2. Файдаланган өчен күпмедер өлешен тотып калу (амортизация). Тотылып бетү, тузу, яраксыз хәлгә килү.

**Истыйлах** *г.* 1. Шартлылык, гомуми килешү, шартлы рәвеш-гамәлгә кертү, файдалану. 2. Махсус атама, термин (мосталахәт — терминнар).

**Итагать** *г.* Тыңлау, буйсыну.

**Италә** *г.* 1. Озайту, озынайту, сузу. 2. Озынлык, сузылганлык.

**Иттам** *г.* Тукландыру, ашату.
**Итлак** *г.* 1. Бушату, ату, ут ачу, җибәрү (ракетаны). 2. Аеру, тулы ирекле итү, бушату, азат итү.
**Итмам** *г.* Тәмамлау, тәгәлләү, эшләп бетерү.
**Иттибаг** *г.* 1. Иярү. 2. Уздыру (берәр фикерне). 3. Эзеннән, артыннан җибәрү.
**Иттилягъ** *г.* Төшенеп җитү, аңлау, хәбәрдар булу. Карап, күзәтеп тору.
**Иттисал** *г.* 1. Тоташу, багланып китү, контакт. 2. Берәр урынга килеп җитү. 3. Туганлык җепләре белән бәйләнгән булу.
**Иттисаф** *г.* Мөһим, әһәмиятле булган аерымлык, үзгәлек.
**Иттифак** *г.* 1. Килешү, бердәм булу. 2. Ярашлы булу, муафыйк булу.
**Иттихәд** *г.* 1. Берләшмә, бердәмлек. 2. Фикерләрнең туры килеше, бер фикердә булу, килешеп эшләү.
**Иттихәз** *г.* 1. Алу, кабул итү, кабул итеп алу. 2. Тиешле чараны күрү.
**Ифадә** *г.* 1. Белдерү, хәбәр итү, ирештерү. 2. Шаһитнең күрсәтмәсе. 3. Файда.
**Ифляс** *г.* Бөлгенлеккә төшү, акчасыз калу, банкрот.
**Ифрад, ифрәд** *г.* Ялгызлык, берәнбер, ялгызак.
**Ифрат** *г.* 1. Артык, чамадан тыш, чиктән тыш, кирәгеннән артык. 2. Усаллык максатында файдалану, бирелгән вәкаләттән узып китү, артыграк кылану, узыну.
**Ифтар** *г.* Рамазан аенда авыз ачу. Ифтар мәҗлесе — уразада авыз ачтыру мәҗлесе.
**Ифтикар** *г.* 1. Ярлылану, фәкыйрьлектә иза чигү, интегү. 2. Ярлылык.
**Ифтикяр** *г.* Уйлау, фикерләү, искә төшерү, хәтергә алу; уй-фикергә чуму.

**Ифтира** *г.* Яла ягу, гаепли торган уйдырмалар.

**Ифтирак** *г.* 1. Аерылып тору (мәсәлән, фикерләр); төрле тарафка аерылып китү (юлларның). 2. Берәр үзенчәлек белән аерылып тору.

**Ифтитах** *г.* (фәтәхә) Ачып җибәрү. Ачу уңаеннан оештырылган тантана.

**Ифтихар** *г.* Горурлык. Мактану, масаю.

**Ифһам** *г.* Аңлату, белдерү.

**Ихавәт, ихауәт** *г.* Кыз туганнар, апалар.

**Ихата** *г.* 1. Әйләндереп, уратып алынган булу. Колачлау. 2. Койма белән тотып алу. Эченә алу. 3. Әһәмият, мәгънә.

**Ихбар** *г.* Хәбәр бирү, белдерү, мәгълүмат ирештерү.

**Ихван, ихуан** *г.* 1. Туганнар, ир туганнар. 2. Дуслар, фикердәшләр.

**Ихдә** *г.* Бер, япа-ялгыз.

**Ихзар** *г.* 1. Чакыру (хөкем йортына, судка). 2. Хәзерләү. Әзерләп китереп җиткерү.

**Ихлас** *г.* Пакь күңеллелек, керсезлек, ачык күңеллелек, ихласлык.

**Ихмирар** *г.* Кызару, кызыл төскә керү, кызыллык.

**Ихрам** *г.* Хаҗга баручылар бөркәнә торган ак кием. Ул ике кисәк тегелмәгән, ягъни инә тимәгән тукымадан гыйбарәт булып, берсе белән муен һәм җилкә өлешенә аркылыга салындырылып тән каплана, ә икенчесе белән тәнгә ябылган тукыма урап куела.

**Ихсан** *г.* Яхшылык, шәфкатьлелек эшләү, изге гамәл кылу.

**Ихтилял** *г.* Басып алу, оккупация.

**Ихтиләл** *г.* 1. Бозылган булу, җимереклек. 2. Тәртипсезлек, тузган булу. Бозыклык.

**Ихтиляф** *г.* 1. Төрлелек, фикер аерымлыгы. 2. Үзгәлек, үзгәреп торучанлык, риза түгеллек. Ызгыш-талаш.

**Ихтираз** *г.* Үз-үзеңне саклау, саклану, сак кына эш итү.

**Ихтирак** (нокталы «хә» белән) *г.* 1. Үтемлелек, үтеп керүчәнлек. 2. Бәреп керү, үтәли чыгу (атылган ядрәнең үтәли чыгуы).

**Ихтирак** *г.* Яну, янып бетү, яндыру.

**Ихтисаб** *г.* 1. Санау, хисаплау, санашу, исәпкә алу. 2. Каршылыксыз булу, ризалашу.

**Ихтисар** *г.* 1. Кыскарту. 2. Кыскача әйткәндә, кыскасы.

**Ихтисас** г. 1. Башкарылырга тиешле бурычлар, эшләр, йөкләнелгән эшләр. Компетентлылык. Кемнеңдер карамагында булу (юрисдикция) 2. Үзенчәлек, белгечлек. Нинди дә булса эшнең яхшы белгече булу.

**Ихтифәл** *г.* 1. Тулып, ташып чыгу. 2. Тантана; бәйрәм итү.

**Ихтияр, ихтыяр** *г.* Сайлап алу, ирекле булу.

**Ихтият** *г.* 1. Саклык белән эш итү, саклану, куркынычсызлык чаралары. 2. Кирәккә калдырылган әйбер, резерв.

**Ихтияҗ, ихтыяҗ** *г.* Мохтаҗлык, кирәклек.

**Ихтиҗаб** *г.* Пәрдә белән каплану, яшерену (пәрәнҗә каплау).

**Ишарә** *г.* 1. Ымлап күрсәтү. 2. Күрсәткеч тамга, билге.

**Ишгаль** *г.* 1. Биләп, басып алу. 2. Эшкә керешү. Берәр эш белән шөгыльләнү.

**Ишкял** *г.* Кыенлык, катлаулылык.

**Ишрак** *г.* 1. Яктыру, нурлану. 2. Нур, балкыш.

**Ишрәк** *г.* Мәҗүсилек, күп аллаларга ышану.

**囉Иштибаһ** *г.* Шикләнү, шөбһәләнү. Охшаш булу, охшашлык.

**Иштидәд** *г.* 1. Көчәю, ныгу. 2. Начарлану.

**Иштирәк** *г.* 1. Берләшү. 2. Гомумилек. 3. Катнашу, бергәлектә башкарып чыгу.

**Иҗабе кабул** *г.* 1. Тәкъдимне уңай кабул итү, җайлап кую. 2. Кыз белән егетне никахтан әүвәл ярәштерү.
**Иҗаби** *г.* Уңайлы, уңышлы, ярашлы, җайлы.
**Иҗат** *г.* Иҗат итү; ачу, уйлап табу.
**Иҗазәт** *г.* 1. Рөхсәт, мөмкинлек бирү. 2. Рөхсәт кәгазе, лицензия, аттестат, диплом.
**Иҗазәтнамә** *г. ф.* Рөхсәт кәгазе.
**Иҗарә** *г.* 1. Вакытлыча файдалану өчен арендага түләп алу. 2. Аренда, прокат өчен түләү.
**Иҗбар** *г.* 1. Мәҗбүр итү, башкарырга кушу. 2. Теләмәсә дә кушу, эшләтү.
**Иҗлял** *г.* Олылау, хөрмәтләү.
**Иҗмаг** *г.* Бертавыштан кабул ителгән карар; туплау, җыю. Берсүзле булу.
**Иҗмали** *г.* Кушып, гомумиләштереп санаганда, кыскача гына, кыскартылган булу.
**Иҗтизаә** *г.* 1. Өлеш алу, бүлеп бирү. 2. Өлешчә кабул итү. 3. Канәгатьләнү.
**Иҗтимаг** *г.* 1. Җыелыш, җыен, митинг. 2. Очрашу, кушылу.
**Иҗтимаг зыйддәен** *г.* Ике каршылыкның бергә кушылуы.
**Иҗтинаб** *г.* Сакланырга мөмкин булу. Читләшергә мөмкин булу.
**Иҗтисар** *г.* 1. Узу, аркылы чыгу (чүлне), кисеп чыгу. 2. Батырлану, гайрәтләнү.
**Иҗтиһад** *г.* 1. Тырышу, күңел биреп эшләү. 2. Мөстәкыйль рәвештә иҗат итү, ирекле рәвештә эзләнү, тикшеренү.
**Иһдә** *г.* Бүләк итеп бирү. Китапны багышлау.
**Иһляк** *г.* Һәлак итү, юк итү, харап итү.

**Иhтизәз** *г.* Тетрәү, калтырау, тибрәнү, селкенү.
**Иhтимам** *г.* 1. Кайгырту, карау, кайгыртучанлык күрсәтү. 2. Кызыксыну. 3. Игътибарлы булу.

# Й — Я

Иске татар язуының «ى» хәрефе хәзерге татар алфавитының «й», «я», «ю» хәрефләренә туры килә. Шуңа күрә мондый хәрефләр белән башланган алынмалар бергә туплап бирелделәр.

**Йабандә** *ф.* Табучы, тапкан. **Йабандә-җуйәнде** әст эзләгән табар.
**Йад** *ф.* Искә алу, хәтерләү, сагынып искә алу.
**Йазид** *г.* Өммәвиләр династиясендә (680 — 683 елларда) хакимлек иткән хәлифләрнең берсе.
**Йакатт** *г.* Яка, күлмәк якасы h. б.
**Йакыйза** *г.* Уяу булу, йокламау, сизгер булу. Сизгерлек, уяулык. Күтәрелеш.
**Йар** *ф.* 1. Дус, иптәш, сөйгән кыз, егет, сөекле кеше. 2. Ярдәмче.
**Йарабби** *г.* Йа раббым, йа Аллам, йа хуҗам.
**Йасин, ясин** *г.* Коръәннең утыз алтынчы сүрәсе.
**Йасуг** *г.* Гайса пәйгамбәр (гарәпчә «Йасугүл-Мәсих» дип тә әйтелә).
**Йаум** *г.* Көн.
**Йауми** *г.* Көндәлек, hәр көнне.
**Йахуд** *ф.* Яки.

**Йаъис, мәйъүс** *г.* 1. Аптырашта, чарасызлыкта калу, кыен ҳәлдә булу. 2. Бар нәрсәдән дә гайрәте чиккән кеше.
**Йаһу** *г.* «Йа» (әй, йә) + «һуа» = *Йа Аллаһ, әй Аллаһ* мәгънәсендә.
**Йосыф** *г.* 1. Ялгызлык исем. 2. Мандарин.
**Йәд** *г.* Кул.
**Йәдәүи** *г.* Кулдан эшләнгән, кулныкы.
**Йәмийн** *г.* Уң як, уң тараф.
**Йәмин** *г.* Ант итү.
**Йәмән** *г.* Йәмән.
**Йәрҗу** *г.* Сорый, ялвара, үтенә.
**Йәһүд, яһүд** *г.* Еврей.
**Йөсрә** *г.* Сул як, сул тараф.
**Йунан** *г.* Греция.
**Ядкяр** *ф.* Истәлек.
**Якдил** *ф.* Бердәмлек, бер уйда булу, ихласлык.
**Якут** *г.* Кыйммәтле таш, якут, корунд.
**Яран** *ф.* Иптәш, дус, якын кеше, булышчы.
**Ясир** *г.* 1. Аз, әһәмияте булмаган. Җиңел генә.
**Ятим** *г.* Атасыз-анасыз. Ятим бала.

## К

**Кабаза** *г.* 1. Кулга төшерү, алу; ия булу; кулдан кысып тоту. 2. Эләктереп алу, хәбес итү, тоткын итү.
**Кабил** *г.* 1. Кабул итүче, каршы алучы. 2. Булачак, киләчәк. 3. Яраклы булу.

**Кабилият** *г.* Сәләтлелек, булдыклылык.

**Кабих** *г.* 1. Әшәке, чирканыч, гайрәтне чигерә торган, җүләр. 2. Тупас, әдәпсез.

**Каблә** *г.* Әүвәл, элек.

**Каблəл мийляд** *г.* Безнең эрага кадәр (Гайсә пәйгамбәр туганга кадәр).

**Кавем** *г.* 1. Халык, ыруг, нәсел, милләт. 2. Кешеләр, кабилә.

**Кави** *г.* Көчле, куәтле.

**Кагъдә** *г.* 1. Утырыш, утыру, утырып тору. 2. Утыру кыяфәте.

**Кадер** *г.* 1. Сан, бәя, күләм, үлчәм, дәрәҗә. Игътибар, хөрмәт. 2. Сүрәтүл-кадәр — Коръәннең 97 нче сүрәсе.

**Кадим** *г.* Атлаучы, йөрүче.

**Кадийм** *г.* 1. Иске, борынгы. 2. Искергән, тузган.

**Кадир** *г.* 1. Көчле, бөек көчкә ия булучы. 2. Булдыра алучы.

**Кадәм** *г.* 1. Аяк, аяк табаны. 2. Адым.

**Кадәре хәл** *г.* Көчендә, куәтендә барынча, көче җиткәнчә.

**Кадәх** *г.* 1. Стакан. 2. Бокал, рюмка.

**Каза** *г.* 1. Административ бүленеш (Гыйрак), өяз. 2. Юриспруденция, хокук. 3. Үтәү, башкару, уздыру, эшләү. 4. Язмыш, хөкем карары (Аллаһ тарафыннан).

**Казый** *г.* 1. Хөкем чыгаручы, хөкем итүче. 2. Хәл кылучы, карар чыгарганда соңгы йомгаклау сүзен әйтүче. Соңгы эшне башкаручы, карар кабул итүче, тәгәлләүче, тәмамлаучы.

**Казыя** *г.* 1. Мәсьәлә; хәл ителергә тиешле мәсьәлә, проблема. **Кадыя хәят әү мәүт** — яшәү яки үлем мәсь-

әләсе. 2. Эш, очрак. 3. Дәгъва белдерү, процесс. 4. Математика теоремасы. 5. Тезис.

**Каид** *г.* 1. Җитәкче, баш кеше, юлбашчы. 2. Әйдәп баручы (машинаны, паровозны һ. б.). Йөртүче пилот.

**Каил** *г.* Әйтүче, сөйләүче, тапшыручы, диюче.

**Каим** г. 1. Аяк өстендә басып торучы, аягүрә торучы, 2. Бар булучы, яшәүче. 3. Вакытлыча вазифаны башкаручы, берәр эшне вакытлыча гына эшләп торучы.

**Каимә** *г.* 1. Терәк, багана, таяныч. 2. Аяк (урындык аягы, хайван аягы...). 3. Исемлек, җәдвәл, таблица.

**Кайсар** *г.* Патша, император, кайзер.

**Калийль** *г.* 1. Аз, күп түгел, аз санлы. 2. Җитешмәүчелек.

**Кальб** *г.* Йөрәк, күңел, җан.

**Кальга** *г.* Ныгытма, курган. **Кальгатүс-силми үә тәкаддүми** — тынычлыкның һәм үсешнең (прогрессның) нигезе, таянычы.

**Каләндәр** *ф.* Сәяхәт итүче, ил гизүче дәрвиш.

**Каләнсовә** *ф.* Очлы, конуска охшаган баш киеме.

**Камәр** *г.* Ай.

**Камус** *г.* 1. Океан. 2. Сүзлек.

**Камусе голүм** *г.* Төрле фәннәр буенча сүзлек, энциклопедия.

**Камәри тәкъвим** *г.* Ай календаре.

**Камәретдин** *г.* Диннең ае.

**Камәт** *г.* 1. Буй; буй озынлыгы. 2. Буй-сын. 3. Озынлык үлчәме (1 метр 88 сантиметрга тиң). 4. Аягүрә басып дога уку.

**Канд** *ф.* 1. Авыл, торак пункт. 2. Ныгытма, ныгытылган урын.

**Канд** *ф.* Шикәр, шакмак шикәр, йомры, укмашкан шикәр.

**Кандил** *г.* Лампа, люстра, фонарь.

**Канун** *г.* Закон, канун; хокуклар, кагыйдәләр тупламы.

**Кануне әсасий** *г.* Төп канун, төп закон.
**Канунщинас** *г. ф.* Кануннар белгече, юрист.
**Каранфөл** *г.* Канәфер гөле, чәчәге.
**Карарнамә** *г. ф.* Кабул ителгән карар, резолюция.
**Кариб** *г.* Якын, туган кеше. Якын ара, ерак түгел.
**Кариә** *г.* 1. Укып торучы. Коръәнне яттан укый белүче. 2. Китап укучы.
**Кариэл бәхт** *г.* Багучылык белән шөгыльләнүче, күрәзәче.
**Карун** *г.* Мифик шәхеснең исеме. Татар телендә *саран* мәгънәсен дә аңлата.
**Карыз** *г.* Бурыч, әҗәткә алган нәрсә.
**Карья** *г.* Авыл.
**Касд** *г.* 1. Максат, омтылыш, ният, уй-фикер. 2. Мәгънә, әһәмият.
**Касим** *г.* 1. Бүлүче, бүлгәләүче. 2. Ант итү (ант итүче).
**Каср** *г.* Зур, матур сарай.
**Касыйр** *г.* Кыска, кыска вакытлы.
**Касыйдә** *г.* Поэма, мактап язылган шигырь.
**Каттъ** г. 1. Кисү, кисеп төшерү. 2. Өзү, сүндерү (утны). 3. Кичү, аркылы кисеп чыгу.
**Каттый** *г.* Кискен итеп, өздереп, кистереп.
**Кател** *г.* Үтерү, һәлак итү, юк итү.
**Катрә** *г.* Әйтү, сөйләү, хикәяләү.
**Кафилә** *г.* Кәрван, колонна, конвой.
**Кафия** *г.* 1. Рифма, бер үк төсле яңгыраш. 2. Сүз уйнату, каламбур, шаяру. 3. Икетөрлелек.
**Кафль** *г.* Бик; бикләп кую, ябып кую. Йозак белән бикләү.
**Кафр** *г.* 1. Бушлык, буш, кешеләрсез. 2. Чүл, сусыз урын.
**Би-аби кафр** *ф. г.* Сусыз чүл.
**Кафәс** *г.* 1. Читлек. 2. Кәрзин, үрелеп ясалган әйбер. 3. Кафәс әссадр — күкрәк читлеге.

**Кахбə** *г.* Уйнашчы хатын, фахишəлек белəн шөгыльлəнүче хатын.
**Каюм** *г.* Мəңгелеккə яратылган (Аллаһының эпитеты).
**Каһвə** *г.* Кофе.
**Каһир** *г.* 1. Җəбер-золым күрсəтүче, каһəрлəүче. 2. Җиңүче, беркайчан да җиңелмəүче. 3. Кушучы, буйсындыручы.
**Каһкаһə** *г.* Кычкырып көлү, кеткелдəп көлү.
**Каһһар** *г.* Бөек көч иясе (Аллаһының эпитеты).
**Кибар** *г.* 1. Олылар, зурлар, бөеклəр. 2. Мөһим, бөек, җитди. 3. Күптəнге, иске.
**Кибрит** *г.* Күкерт, шырпы.
**Кибрия** *г.* Горурлык, тəкəбберлек.
**Кизб** *г.* Ялган.
**Кимияви** *г.* Химияле, химия белəн бəйлəнешле.
**Киная** *ф.* 1. Читлəтеп кенə сиздерү, аңлату. 2. Бик тыйнак кына, саклык белəн генə əйтү, хəбəр итү. Аллегорик рəвештə белдерү.
**Кинə** *ф.* 1. Усаллык, явызлык, дошманлык, искедəн калган дошманлык. 2. Үч алу, ачу саклау. Кан үчен алу. Күңелдə, бик тирəндə сакланган дошманлык хисе..
**Кирам** *г.* 1. Юмартлар, олы җанлылар, затлылар, ачык күңеллелəр, ихтирамлылар. 2. Кыйммəтле, затлы. 3. Шактый зур, мул.
**Китаби** *г.* Язма рəвештə, язулы, язу.
**Китман** *ф.* 1. Яшерү, яшереп тоту, саклау (серне). 2. Матур əдəбиятта *тыйнак булу, үз-үзеңне тыя белү* мəгънəсендə кулланыла.
**Кифая** г. 1. Җитəрлек дəрəҗəдə булу, кирəк кадəр булу. 2. Өлеш, кисəк. 3. Сəлəт, булдыклылык, тумыштан ук булдыклы булып туу.

**Коббә** *г.* Түбәсе түгәрәкләп тоташтырылган булу, гөмбәз. **Куббәтүл ислами** — исламның гөмбәзе, түбәсе (Басра шәһәренең эпитеты).
**Коддус, Котдус** *г.* Изге, иң изге.
**Кодес** *г.* 1. Изгелек, гөнаһсызлык. 2. Әл-Кодес (Иерусалим шәһәренең гарәпчә исеме). Борынгы гыйбри телендә — Уршалайм.
**Кодүм** *г.* 1. Килеп җитү. 2. Батырчылык итү.
**Колүб** *г.* Йөрәкләр. **Рәунакүл колүб** — йөрәкләрнең бөеклеге, чаткысы, нуры.
**Комар** *г.* Отыш уены, акчага уйнау.
**Комаш** *г.* Тукыма.
**Корбан** *г.* Берәр мөнәсәбәт белән, атап хайван чалу, корбан итү.
**Корбәт** *г.* Туганлык, кардәшлек; якын кеше.
**Коруне ахирә** *г.* Соңгы гасырлар.
**Коруне уста** *г.* Урта гасырлар.
**Кур** *ф.* Сукыр, күрми торган.
**Кыйбла** *г.* Намаз вакытында мөселманнар йөзләрен юнәлтә торган тараф.
**Кыйблатани** *г.* 1. Ике кыйбла: беренчесе Әл-Кодес (Иерусалим), икенчесе Мәккә. 2. Көньяк. 3. Тартып торучы мәркәз, үзәк (сурәтләү чарасы булып гамәлгә кергән).
**Кыйрат** *г.* Кыйммәтле ташлар өчен үлчәү берәмлеге.
**Кыйрд** *г.* Маймыл, койрыксыз маймыл.
**Кыйсса** *г.* Тарих, хикәя, новелла.
**Кыйссадан хисса** *г.* Укыган хикәядән алына торган гыйбрәт.
**Кыямәт** *г.* 1. Үлгәннәр тереләчәк көн. **Йәүмүл-кыямәт** — олуг һәм куркыныч булган зур хөкем итү көне.

2. Опекунлык. 3. Тавыш-гауга, шау-шу (сурәтләү чарасы буларак гамәлгә кергән).

**Кязым** *г.* 1. Тыйнак, тыныч, тавышсыз-тынсыз, үз-үзен тота белүчән, чыдам. 2. Шигыйларның сигезенче имамы — Мусаның эпитеты. Ул Багдад шәһәренең Кязымия районында алтын гөмбәзле, дүрт манаралы төрбә эчендә күмелгән. Шигый мәзһәбендәге мөселманнарның изге урыны булып санала.

**Кяинат** *г.* Бөтен, яратылыш, дөнья, галәм.

**Кямил** *г.* 1. Тулы, бөтен. 2. Җитешкән, кимчелексез.

**Кямран** *ф.* Бәхетле, үз-үзеннән канәгать, теләгәненә ирешкән, тормыштан тәм табып яшәүче.

**Кяргәр** *ф.* Эшче, хезмәткәр.

**Кярханә** *ф.* 1. Фабрика, завод. 2. Төрек телендә бу сүз «фәхешханә» мәгънәсендә гамәлдә йөри.

**Кяфер, кяфир** *г.* 1. Яхшылыкның кадерен белмәүче. 2. Ышанмаучы, намуссыз, тугрылыксыз. 3. Алласыз.

**Кяфур** *г.* Камфара агачы.

**Кәбаб** *г.* Куырма, кәбаб (иттән әзерләнгән).

**Кәбирә** *г.* 1. Олы, зур, дәү, бөек. 2. Мөһим.

**Кәбисә** *г.* Февраль ае; 29 көннән гыйбарәт булган ай.

**Кәбүтәр** *ф.* Күгәрчен.

**Кәгъбәтуллаһ** *г.* Мәккә шәһәрендәге гыйбадәтханә. Аллаһ йорты.

**Кәеф-сафа** *г.* Кәефле, яхшы итеп вакыт уздыру, ял итү.

**Кәззаб** *г.* Ялганчы, алдакчы.

**Кәлимә** *г.* Сүз.

**Кәлисә** *ф.* Гарәп телендә кәнисә. Христиан гыйбадәтханәсе, чиркәү.

**Кәллә** *ф.* Баш.

**Кәләпүш, кәлләпүш** *ф.* Баш каплый торган, баш киеме.

**Кәлямулла** *г.* Аллаһының сүзе. Коръән китабы.
**Кәмә йәнбәгый** *г.* Ничек булырга тиеш булса, шулай, тиешенчә, тиешле рәвештә.
**Кәмәнҗә** *г.* Кыллы уен коралы, скрипка.
**Кәмәһә** *г.* Сукырлык.
**Кәр, кяр** *ф.* Эш, хезмәт.
**Кәмәр** *ф.* 1. Бил-сын. 2. Пута, билбау. 3. Урта өлеш.
**Кәнизәк** *ф.* Кол хатын, җария.
**Кәрамәт** *г.* 1. Олылау, хөрмәтләү, дәрәҗә, мәртәбә. 2. Юмартлык, затлылык, зыялылык. 3. Могҗиза. Сахибе кәрамәт — могҗиза тудыручы.
**Кәррат вә мәррат** *г.* Күп тапкырлар, кабат-кабат.
**Кәсеп** *г.* 1. Табу, кулга төшерү, ия булу, кәсеп итеп табу. 2. Файда табу, отыш. Кәсептән алынган файда.
**Кәсәл** *г.* 1. Ялкаулык, иренчәклек, сүлпәнлек. 2. Эшсезлектән интегү. 3. Авыру (эчәк авыруы).
**Кәшиф** *г.* 1. Берәр ачыш ясаучы, эзләп табучы. 2. Район башлыгы.
**Кәшиф әл-гоммәт** *г.* Кайгы-хәсрәттән коткаручы.
**Кәшшаф** *г.* 1. Ачып күрсәтүче, ачучы, эзләп тикшереп табучы. 2. Чик аркылы уздыручы, таможня кешесе.
**Кәүакиб** *г.* Йолдызлар.
**Кәүнәйни** *г.* Ике дөнья.
**Кәүсәр** *г.* 1. Мул, тулы. 2. Оҗмахтагы елга исеме.
**Кәһраба** *г.* Электр уты.
**Кәһрубә** *г.* Гәрәбә (янтарь).
**Кәһф, кәһәф** *г.* Мәгарә, тау куышы.
**Көллия** *г.* 1. Тулылык, бербөтенлек. Факультет, колледж. 2. Хәрбиләр өчен югары уку йорты.
**Көрраса** *г.* 1. Дәфтәр, брошюра; китапның бер өлешен нәшер итү. 2. Памфлет.

**Кәсуф** *г.* 1. Оят. 2. Караңгылану. **Кәсуф әшшәмс** — кояш тотылу.
**Кәхел** *г.* Күз сөрмәсе.
**Куфи** *г.* 1. Куфә шәһәренеке. 2. Гарәп язуының төре. (Куфи язуы белән мәчет гөмбәзләренә, төрбәләргә, кабер ташларына языла. Көндәлек тормышта сирәк кулланыла. Гыйракның бу борынгы шәһәре Гали хәзрәт заманында хәлифат башкаласы булган).
**Куфтә** *ф.* 1. Ватылган булу. 2. Арыганлык. 3. Туралган иттән һәм дөгедән пешерелгән ашамлык.

# Л

**Лаек** *г.* Тиешле, ярашлы, лаек, күркәм.
**Латыйф** *г.* 1. Ачык күңелле, яхшы, мөлаем. 2. Чибәр, матур, бик күркәм.
**Либас** *г.* Кием (күплек санда «әлбисә»).
**Лива** *г.* 1. Байрак, әләм. 2. Хәрби бригада. 3. Командующий, бригада генералы.
**Лизәликә** *г.* Менә шуның өчен..., шуңа күрә (ли бәйлеге һәм зәликә күрсәтү алмашлыгыннан ясалган).
**Ликаә** *г.* Очрашу, күрешү.
**Лиллаһ** *г.* Аллаһ өчен; Аллаһ хакына.
**Лисан** *г.* Тел. **Лисанүл гарәбийү** — гарәп теле, **лисанүл инсани** — кешенең теле.

**Лифафә** *г.* 1. Төргәк, уралган әйбер. 2. Урый торган кәгазь яки чүпрәк.
**Лихаф** *г.* Юрган, одеял, урын-җир өстенә яба торган япма, покрывало.
**Лихья** *г.* Сакал.
**Локмә** *г.* 1. Кечкенә кисәк, бер кабым ашамлык. 2. Ризыкның соңгы кисәге, иң тәмлесе.
**Лосук** *г.* 1. Ябышкан. 2. Ябыштыргыч.
**Лосус** *г.* Караклар, пиратлар.
**Лотфулла** *г.* Аллаһының йомшак, яхшы, ачык күңелле бәндәсе.
**Лотфән** *г.* Ярдәм йөзеннән, яхшылык итеп, хуш күреп. (*Ля* — гарәп телендә юклыкны белдерә).
**Лябуддә, ләбуддә** *г.* Һичшиксез, котылгысыз, әлбәттә. («лә»+»буддә»=ләбуддә).
**Ля бәәс** *г.* Зыянлы түгел, ярар, ярый ла, зарар юк.
**Лятыйб** *г.* Уйнаучы, уенчы, спортчы.
**Ләб** *ф.* 1. Ирен, иреннәр. 2. Кырый, яр чите (өстәл чите, икмәк чите).
**Ләббәйкә** *г.* Хаҗ мәрасимен үтәгән вакытта «менә мин бөтен барлыгым белән синең алдыңда торам» дип әйтү.
**Ләбиб** *г.* Акыллы, үткен зиһенле, тапкыр.
**Ләвазим, ләүазим** *г.* Тиешле, кирәкле нәрсәләр, эшләр.
**Ләгаллә** *г.* Шаять, бәлки.
**Ләгънәт** *г.* Каргыш, каргау. **Ләгънәтүллаһи галәйһи** — Аллаһының каһәре төшсен аңарга.
**Ләгыйнь** *г.* Каргалган, бәддога укылган, юньсез.
**Ләззәт** *г.* Татлылык; ләззәтләнү, рәхәтләнү; тәмен тату.
**Ләзиз** *г.* 1. Тәмле, татлы, искиткеч. 2. Нәфис, зәвыклы.
**Ләйләт** *г.* Бер төн. **Әлләйләтү** — бүген төнлә. **Ләйләтүл мигъраҗ** — Мөхәммәт пәйгамбәрнең күккә ашып

Әл-Кодескә сәяхәт иткән киче (Рәҗәб аеның 27 нче кичәнә туры килә).

Ләйлән *г.* Төнлә яки кичен. Төнлә белән.

Ләйсә *г.* Юклыкны белдерүче «юк», «түгел» кисәкчәләре.

Ләйтә *г.* Теләкне белдерүче сүз: «Әй булса иде!» мәгънәсендә.

Ләкаб *г.* 1. Кушамат. 2. Гыйльми дәрәҗә, титул.

Ләмигъ *г.* Ялтырап, балкып, нурланып тору. Нур чәчү.

Ләмисә *г.* Тотып капшап карау, тоеп белү.

Ләм ялид *г.* Тумады.

Ләнгәр *ф.* Якорь.

Ләт, әлләт *г.* Исламга кадәр булган (җаһилия дип аталган) чорда борынгы гарәпләрнең табынган алиһәләре (аллалары).

Ләтаиф («ләтыйфә»нең күплек саны) Үткен сүзләр, мәзәкләр, хикәяләр.

Ләтафәт *г.* Күркәмлек, матурлык, нәфислек, ямьлелек.

Ләфзы көфер *г.* Ярамас, начар сүз сөйләү, Аллаһыга инанмауны белдергән сүз.

Ләхед *г.* Гүр, ләхет.

Ләхза *г.* Бик кыска вакыт, күз йомганчы.

Лә хәүлә *г.* Лә хәүлә үә лә куәт иллә билләһил газыйми — Аллаһының көченнән башка бернинди дә көч-куәт юк!

Лә хәүфә галәйһим *г.* Алар курыкмыйлар, куркуны белмиләр.

Ләшкәр *г.* Гаскәр, армия.

Лә шәй *г.* Һични түгел, берни түгел, бернәрсә дә түгел, яки зыян юк мәгънәсендә.

Лә шәккү, лә шәккә *г.* Һичшиксез, шөбһәсез, икеләнүсез.

**Ләүз** *г.* Миндаль чикләвеге, бадәм.

**Ләүхел мәхфуз** *г.* Адәм баласының дөньяда эшләгән барлык эшләре дә теркәлә (һәм саклана) торган такта.

**Ләүхә** *г.* 1. Такта, белдерүләр тактасы. Ишеккә язып асыла торган такта. 2. Сәнгать әсәре (шамаил).

**Ләһҗә** *г.* 1. Диалект (тел фәнендә); урындагы сөйләм. 2. Акцент.

**Лөгави** *г.* 1. Телгә караган, лингвистик. 2. Филолог, тел галиме.

**Лөгать** *г.* 1. Тел. 2. Сүзлек.

**Лөгате гарабия** *г.* Гарәп теле.

**Лөзум** *г.* Кирәклелек, кирәк булу.

**Лөәлөә, луәлү** *г.* Энҗе бөртеге.

**Лүли** *ф.* 1. Чегән. 2. Урамда җырлап-биеп йөрүче хатын.

# М

**Ма бәгъд** *г.* Соңгы, соңгысы, соңыннан булганы...

**Ма бәйнә** *г.* Ике аралыктагы. Ма бәйнәннәһр — ике елга арасындагы җир. Месопотамия.

**Ма вараэннәһер** *г.* 1. Елга аръягындагы җир. 2. Трансокеания.

**Ма дамә** *г.* Дәвам иткән, булып торган, әле һаман да.

**Мадди** *г.* Материалистик.

**Мадәр** *ф.* Ана, әни.

**Мазһар** *г.* (заһара) Күренеш, аспект, тышкы кыяфәт.

**Маил** *г.* 1. Авышучан, үзгәрүчән. 2. Авыш булу (таудан өстән аска таба төшкән кебек). 3. Тартым,... сыман.
**Макир** *г.* Мәкерле, хәйләкәр.
**Максуд** *г.* Эзләп табылган; теләгән теләк; алдан уйланылган теләк.
**Мал** *г.* 1. Байлык. 2. Мал-туар, каралты-кура. 3. Акча, капитал.
**Малик** *г.* 1. Малга ия булучы, хуҗа. 2. Җитәкче, башлык, хәким. **Малику йәүмиддин** — хөкем көненең хуҗасы.
**Малпәрәст** *ф.* Малга табынучы, мал яратучы.
**Маниғъ** *ф.* 1. Каршы торучы, каршылык күрсәтүче. 2. Көч җитәрлек түгел (бәяләр). 3. Кыенлык; аяк чалу.
**Мансур** *г.* Җиңүче, җиңүен бәйрәм итүче.
**Мантыйк** *г.* 1. Нотык, чыгыш ясау. 2. **Гыйльмүл мантыйк** — логика. 3. Тәртип, җай белән сөйләү, уйлау.
**Масдар** *г.* 1. Чыганак. 2. Килеп чыгышы, чишмә башы. 3. Исем фигыль.
**Матбага** *г.* Китап басу белән шөгыльләнүче оешма, нәшрият.
**Матбуг** *г.* 1. Басылып чыккан, нәшер ителгән. 2. Табигыйлек. 3. Тумыштан бирелгән сәләт.
**Маттам** *г.* Ашханә, ашый-эчә торган урын, ресторан.
**Матлаб** *г.* 1. Таләп ителгән, эзләнелә торган, кирәкле нәрсә, әйбер. 2. Ихтыяҗ булган, сорала торган.
**Матруд** *г.* Куылган, куып җибәрелгән.
**Матрух** *г.* 1. Ташланылган, ыргытылган. 2. Киметелгән (сан).
**Матәм** *г.* Кайгылы булу, матәм тоту, хәсрәтле булу.
**Ма фатә** *г.* Булып узган. **Ма фатә мәт** — үткән, беткән.
**Ма фиһһа** *г.* Эчендә, эчтә булган нәрсә.

**Ма фәука, ма фәвык** *г.* Югарыда булган, өстә булган, искәртеп узылган, югарыда әйтелгән.
**Махикъ** *г.* Ватучы, җимерүче. Җимергеч һөҗүм.
**Машалла** *г.* (Ма+шаә+Аллаһ=Машаллаһ) Бик яхшы, бик күркәм, нинди шәп... *Аллаһ кушканча булган* ич! Гаҗәпсенү, хуплау, хозурлануны белдергәндә кулланыла.
**Машиян, машиән** *г.* Җәяү бару.
**Маә, маъ** *г.* Су.
**Маи зәмзәм** г. Зәмзәм суы. *Кара:* зәмзәм.
**Маугыйдь** *г.* (үәгадә) 1. Вәгъдә. 2. Вәгъдәләшкән вакыт.
**Ма әшбәһе** *г.* Шуның шикелле, охшашлы булу, шундый.
**Маҗара** *г.* (ма+җәраә = маҗара) Вакыйга, гадәти булмаган хәл.
**Маҗид, Мәҗид** *г.* 1. Данлы, бик яхшы. 2. Мәшһүр, билгеле, танылган, дан казанган, яхшы исемгә лаек булган. 3. Олы җанлы, миһербанлы, киң күңелле.
**Маһ** *ф.* 1. Ай, күктәге ай. 2. Матур, чибәр, гүзәл.
**Ма һазә, ма һәзә** *г.* (*ма* сорау, *haза* күрсәтү алмашлыгы) Бу нәрсә?
**Маһанә** *ф.* 1. Һәр айда, һәр айлык. 2. Айлап. 3. Айлык эш хакы, стипендия.
**Маһе бәмаһ** *ф.* Ай саен.
**Маһитаб** *ф.* Ай яктысы, ай нуры.
**Маһибәдәр** *ф.* Тулган ай.
**Маһир** *г.* 1. Оста куллы, тәртибен белеп эшләүче. 2. Белүче, квалификацияле.
**Маһиранә** *г. ф.* Чын осталарча, осталарга хас сыйфат белән.
**Маһруй** *ф.* Ай йөзле, матур.
**Мескен** *г.* Мескен, ярлы, кызганыч, бәхетсез.
**Мивә** *ф.* Җиләк-җимеш.

**Мивәфрүш** *ф.* Җиләк-җимеш сатучы.
**Мигадь** («үәгадә» сүзеннән ясала) *г.* Билгеле бер вакыт; очрашу, вәгъдәләшү.
**Мигадә** *г.* Ашказаны.
**Мигъмар** *г.* Төзүче, архитектор.
**Мигъраҗ** *г.* 1. Күккә ашу. 2. Баскыч. *Кара:* ләйлә.
**Мизан** *г.* 1. Үлчәү, үлчәм. 2. Баланс. 3. Гаделлек.
**Микъяс** *г.* 1. Үлчәм, критерий. 2. Үлчи торган җиһаз, прибор.
**Микъдар** *г.* Үлчәм, сан, өлеш, чама.
**Миллият** *г.* 1. Халыкныкы, милләтнеке. 2. Динлелек. 3. Миллилек.
**Милләтпәрвәр** *г. ф.* Милләтен яратучы, патриот.
**Миляд'** *г.* 1. Туу, туган көн. 2. Раштуа көн, раштуа бәйрәме — гыйдүл миляд.
**Миләл** *г.* Халыклар, милләтләр.
**Минбәр** *г.* Менбәр, кафедра. Мәчет эчендә нотык сөйләүченең (хатыйбның) басып сөйли торган (баскычлы итеп ясалган) урыны.
**Миннәтдар** *г.* Берәүдән күргән яхшылык өчен рәхмәтле булу. Күргән яхшылыкны зур, олы бер миннәт дип белү.
**Минтака** *г.* 1. Билбау, кушак, пута. 2. Климат поясы, район, зона.
**Мин хәйсү лә яхтәсиб** *г.* Көтмәгән яктан нәрсәнең дә булса ирешүе.
**Мин шәррикә** *г.* (мин бәйлеге һәм шәррүн сүзенә кә кушма алмашлыгы кушылып ясалган) Синең явызлыгыңнан яки явызлыгың аркасында.
**Минһаҗ** *г.* 1. Юл. 2. Ачыклап, аңлатып бирү. 3. Программа, план.
**Минһүм, минһем** *г.* (мин+һүм) Алардан, аларның.

Мир *ф. Асылында гарәп сүзе.* («Әмир»нең кыскартылган шәкеле) Сәед, задә, әфәнде мәгънәсен белдерә.
Мирарән *г.* Берничә тапкыр, күп тапкыр.
Мирас *г.* 1. Үлгән кешедән калган әйбер, мал. 2. Ата-бабаларыбыздан калган мирас (тарихи, мәдәни).
Миргазиз *ф. г.* Көч-куәткә ия булучы зат, зыялы кеше.
Мирза *ф.* («Әмирзадә»нең кыскартылган шәкеле). Укымышлы, зыялы кешеләрнең исемнәренә кушылып әйтелгән. 2. Иранда тәхет варисларының исемнәре алдына куеп әйтелә торган олылау сүзе.
Мисакъ *г.* 1. Килешү, пакт. 2. Устав, хартия. Мисакуссәлам — тынычлык турында килешү, пакт.
Мисбах *г.* Яктырткыч-шәмдәл, лампа, фонарь.
Мискаль, мыскал *г.* 1. Үлчәү берәмлеге (бер мыскал 4,68 грамм яки 24 кыйратка тиң).
Мисл, мисләә *г.* Кебек, шикелле, охшашлы, нәкъ, әйтерсең лә, диярсең.
Мифтах *г.* 1. Ачкыч, кабызгыч (электр).
Мифтахетдин *г.* Дин ачкычы.
Михнәт *г.* Сынау, кайгы, кыенлык.
Михраб *г.* 1. Мәчет түрендә стенада эчкә таба уелып кыйбла тарафын күрсәтеп тору өчен ясалган урын.
Миһер *ф.* 1. Мәхәббәт, дуслык. 2. Яхшы ниятта булу, гашыйк булу. 3. Иран календареның җиденче ае (23 сентябрь — 22 октябрь).
Миһербан *ф.* 1. Ягымлы, шәфкатьле, яхшы күңелле. 2. Сөйкемле, йомшак күңелле, ачык йөзле, кеше хәлен аңлый белүче.
Миһләт, мүһләт *г.* Кичектереп, туктатып тору, әкренлек.
Миһман *ф.* Кунак.

**Миһманханә** *ф.* Кунакханә, отель.
**Могаббир** *г.* Аңлатучы, юрап бирүче.
**Могаванәт** *г.* Ярдәм, булышлык, ярдәмләшү.
**Могадил** *г.* Тигезлек, бәрабәр булу, шикелле.
**Могаззәм** *г.* 1. Олы, хөрмәтле, бөек саналган. 2. Сөекле.
**Могакадә** («гакадә» сүзеннән) *г.* Килешү, беркетеп кую.
**Могалләкать** *г.* Борынгы гарәпләрнең әдәби әсәрләре тупланган җыентык исеме (җиде әдәби әсәрне эченә алган).
**Могариз** *г.* 1. Каршылык күрсәтүче, каршы килүче. 2. Оппозиция. 3. Оппонент.
**Могасыйр** *г.* 1. Хәзерге. 2. Замандаш.
**Могаҗҗәлән** *г.* Ашыгыч рәвештә, тиз генә, ашыгычлык.
**Могаһәдә** *г.* Килешү, договор.
**Могътәбәр** *г.* 1. Хөрмәтле. 2. Күзгә алынырлык.
**Могътәзили(ләр)** *г.* Аерылып чыгу, китү, йомылып яшәү. (Ислам динендәге мәзһәбнең (юнәлешнең) тәгълиматы.)
**Могыйн** *г.* Яхшы ярдәмләшүче, ярдәм итүче.
**Могҗизә** *г.* Искитәрлек, акыл җитми торган дәрәҗәдә кызыклы, гаҗәеп.
**Мозаригъ, модаригъ** *г.* Киләчәк заман.
**Мозаффар** *г.* Җиңүче, өстенлеккә, теләгенә ирешүче.
**Мозлим** *г.* Караңгы, шыксыз, билгесез.
**Мокабәлә** *г.* 1. Капма-каршы, чагыштырып карау. 2. Каршылау. 3. Алмаштыручы, эквивалент. Нәрсәнеңдер, кемнеңдер урынына (өчен).
**Мокабил** *г.* 1. Каршы алучы, каршы якта торучы. 2. Берәр нәрсәнең алмашы. Эквивалент. Алмаштыру өчен фикер, әйбер тәкъдим итү.
**Мокавәлә, мокауәлә** *г.* 1. Бәхәс. 2. Килешү, контракт.
**Мокариб** *г.* Нәрсәгә яки кемгә дә булса якынаючы, якын торучы.

**Мокаранә** *г.* Берләшү, тоташу, чагыштырып карау. Бәйләнешкә керү.
**Мокатәлә** *г.* Сугышу, көрәшү, сугыш, көрәш.
**Моктәдир** *г.* Көчле, көче җитүче.
**Моназара** *г.* 1. Сүз көрәштерү, бәхәс. 2. Тикшерү, карау (мәсәлән, медицинада).
**Монафикъ** *г.* Икейөзле, кыланчык.
**Морад** *г.* 1. Теләгән нәрсә. 2. Теләк, ният, максат, башкарырга дип уйланган эш.
**Мораттиб** г. Әзерләнгән, тәртипкә китерелгән.
**Мосаддар** *г.* 1. Чыгарылган, җибәрелгән, читкә чыгарылган. 2. Кемне дә булса башлык, җитәкче итеп кую, үзәккә утырту.
**Мосаддыйк** *г.* 1. Дөрес дип табучы, раслаучы. 2. Берәр документны имзалау, дөреслеген имза белән ныгыту.
**Мосаләхә** *г.* Үзара тыныч яшәү, тынычлык турында килешү төзү, ризалашу.
**Мосанниф** *г.* Китапны төзүче, автор.
**Мосахабә** *г.* 1. Озатып кую, юлдаш булу, булсын дип теләк теләп калу, юллама бирү. 2. Утырышу, бергә утыру, гәп корып утыру. 3. Дуслык.
**Мосаххих** *г.* 1. Төзәтүче, дөресләүче. 2. Кул куючы. 3. Корректор.
**Мосауир, мосавир** *г.* 1. Рәсем ясаучы, рәссам. 2. Сурәт алучы, фотога төшерүче.
**Мостафа** *г.* Сайлап алынган, иң яхшы.
**Мосхаф** *г.* 1. Төргәк. 2. Китап. Әл-мусхафүш-шәриф яки Әлмусхафү — Коръәннең кульязмасы. Коръән.
**Мотабикъ** *г.* Туры килә торган, ярашлы булу.
**Моталәга** *г.* Уку, өйрәнү.
**Мотаһһар** *г.* Пакьләнгән, тазартылган, сафланган.

**Мотлакъ** *г.* Һич тә, бөтенләй, тәмам, һичничек тә, һичнәрсә белән шарт ителмәгән. Бернинди шартсыз, чикләнүсез.

**Мотмәин** *г.* 1. Тыныч, үз-үзенә ышанган. 2. Ышанган. 3. Түбәнлекле урын.

**Мотыйг** *г.* Буйсынучы, тыңлаучы.

**Мохабәрә** *г.* 1. Язышу, хәбәрләшү. 2. Сөйләшүләр (телефоннан). 3. Белеп, тикшереп, яшертен күзәтеп тору.

**Мохбир, мөхбир** *г.* 1. Хәбәрче, хәбәр итеп торучы, репортер. 2. Тикшереп, тыкшынып, белешеп йөрүче, хәбәр итеп торучы.

**Мохлис** *г.* Ачык, ихлас күңелле, ышанычлы, чын, тугрылыклы дус.

**Мохсинә, мохсанә** *г.* Игелекле, намуслы, киң күңелле, шәфкатьле, тәртипле, инсафлы ханым.

**Мохтар** *г.* 1. Сайланган, сайлап алынган. 2. Сайларга иреклe булган, ирекле. 3. Авыл старостасы.

**Мохтаҗ** *г.* Интеккән, тинтерәгән, ихтыяҗы булган, фәкыйрь.

**Мохтәлиф** *г.* Төрлелек, аерымлык, каршылык.

**Мохтәсар** *г.* 1. Кыскартылган, кыскалык, кыска. 2. Конспектив рәвештә, бик кыска итеп белдерү.

**Муафикъ** *г.* 1. Хуплаучы, килешүче. 2. Ярашлы, туры килә торган, уңайлы, җайлы.

**Муаффәкыять** *г.* Уңышлар, бәхетләр, уңайлыклар.

**Муаҗәһә** *г.* 1. Каршы тору, каршы булу, кара-каршы килү. 2. Очрашу, күрешү (рәсми очрашу яки күрешү).

**Мумәҗҗәд** *г.* Иң олы, иң бөек зат; мәңгелек данга лаек зат.

**Мусави** *г.* Муса каваме, яһүдләр.

**Мужҗиб** *г.* Сәбәп итү, кирәкле итү. Кирәклелек, ихтыяҗ.

**Муәәҗәз** *г.* 1. Кыска, үтемле, аңлаешлы. 2. Кыскача йомгак ясау, йомгаклау. Кыскача гына эчтәлеген аңлату.
**Муәйәд** *г.* Ярдәм итүче, хәлне аңлаучы.
**Мәбани** *г.* Биналар, корылмалар.
**Мәбахис** *г.* 1. Эзләнүләр, тикшеренүләр. 2. Өйрәнү, тикшерү өчен темалар.
**Мәбгус** *г.* 1. Җибәрелгән. 2. Илче, депутат. 3. Әлмәбгас — Мөхәммәт пәйгамбәр миссиясе.
**Мәбдәәл кыйраәт** *г.* Башлангыч уку, дәреслек. Уку нигезе.
**Мәбләгъ** *г.* Акча; акча саны, сумма.
**Мәга зәлик** *г.* Шуның белән бергә, шуңа күрә, шулай итеп.
**Мәгаш** *г.* 1. Тормыш, тереклек. 2. Айлык эш хакы, пенсия. 3. Яшәү, тереклек өчен кирәк булган акча.
**Мәгъбәд** *г.* Гыйбадәтханә, гыйбадәт кылу урыны.
**Мәгъбәр** *г.* Аркылы чыгу, узу, кичү урыны.
**Мәгъбүд** *г.* Сын, табыну поты. Җаһилләрнең табына торган сыннары.
**Мәгъдән** *г.* 1. Җир асты казылма байлыгы. 2. Шахта, рудник.
**Мәгъзуб** *г.* Ачуы килгән, ачуландырылган, ачуны чыгара торган зат.
**Мәгъкуль** *г.* Акылга сыя, аңлашыла торган, ярашлы булу. Мантыйклы.
**Мәгълүб** *г.* Җиңелгән, туздырып ташланган. Көрәштә үз мөстәкыйльлеген югалткан.
**Мәгълүм** *г.* Билгеле нәрсә. Кайвакытта «әлбәттә», «нәкъ шулай» мәгънәсендә дә кулланыла.
**Мәгъмүл** *г.* Эшләнгән, ясалган, башкарылган.
**Мәгъмүр** *г.* Эшкәртелгән, төзекләндерелгән.

**Мәгънәви** *г.* 1. Мәгънәгә караган. 2. Күзгә күренми торган, уйда гына булган.

**Мәгънәвиять** *г.* Рухилык, рухи күтәренкелек. Аңлылык, идеялелек һ. б.

**Мәгъриб** *г.* 1. Кояш бату урыны. 2. Көнбатыш. 3. Кичке вакыт, кич.

**Мәгърифәт** *г.* 1. Белем, аң. 2. Танышлык, танышлар, дуслар.

**Мәгърүз** *г.* 1. Күрсәтергә куелган, күргәзмәгә куелган. 2. Бирәр тәкъдим ясау, петиция.

**Мәгърур, мәгърурәнә** *г.* 1. Башкаларны күрмәс, танымас хәлгә килгән, борынын чөйгән, һавалы. 2. Тәкәббер, эреләнгән.

**Мәгъруф** *г.* 1. Билгеле, һәркемгә мәгълүм. 2. Хупланылган. 3. Яхшылык белән, яхшылык эшләү.

**Мәгърәкә** *г.* 1. Сугыш, көрәш. 2. Кампания.

**Мәгъсум** *г.* 1. Саклана торган, кагылмый торган. 2. Гөнаһсыз, гаепсез.

**Мәгъсүл** *г.* Юынган, коенган, пакьләнгән, госел коенган.

**Мәгъсәлә** *г.* Юыну урыны (раковина, умывальник).

**Мәгъфирәт** *г.* Ярлыкау, кичерү, гөнаһларны ярлыкау, кичерү.

**Мәгъшук** *г.* 1. Яратылган, сөелгән. 2. Сөйгән кеше.

**Мәгъшәр** *г.* Җыен, җыелыш, төркем, җәмәгать.

**Мәгъяб** *г.* Җитешсезлеге булган, гаепле.

**Мәгъҗүн** *г.* 1. Измә, паста (теш пастасы, томат измәсе). 2. Дару, үлән төнәтмәсе (әфьюн).

**Мәгыйшәт** *г.* 1. Тормыш, тереклек. Тереклек өчен кирәк ризык.

**Мәгәр** *ф.* Тик, ләкин, бәлки әле, ...- дан башка.

**Мәдар** *г.* 1. Кучәр. 2. Өлкә, сфера. 3. Бер әйбернең әйләнү юлы, орбита.

**Мәдех** *г.* Мактау, дан җырлау.

**Мәдинә** *г.* Согуд Гарәбстанындагы шәһәр. Мәдәният учагы, шәһәр.

**Мәдрәсә** *г.* 1. Мәктәп, дәрес бирү урыны, училище. 2. Фәндәге юнәлеш.

**Мәдфүн** *г.* Күмелгән, дәфен ителгән.

**Мәдхия** *г.* Мактау, дан җырлау, ода.

**Мәдәд** *г.* 1. Ярдәм, булышлык. 2. Хәрби ярдәм.

**Мәдәни** *г.* Культуралы, затлы, әдәпле, мәдәниятле.

**Мәдһуш** *г.* Гаҗәпләнгән, исе киткән, хәйран калган, аптырашта калган.

**Мәел** *г. кара*: маил.

**Мәзкүр** *г.* Искә алынган, атап узылган.

**Мәзлум** *г.* Гаделсезлекләр күрүче, рәнҗетелгән, кимсетелгән, кыерсытылган.

**Мәзмун** *г.* 1. Тәэмин ителүче, тәэмин ителгән, гарантияле. 2. Әһәмияте булган. 3. Эчтәлек, мәгънә.

**Мәзә** *г.* 1. Тәм, ләззәт. 2. Эчемлек, шәраб янына куела торган ризык.

**Мәзһәб** *г.* 1. Тоткан юл; тәртип; диндәге юнәлеш. 2. Теория, идеология.

**Мәймүн** *г.* 1. Бәхетле, уңышлы, шат. 2. Маймыл.

**Мәйфоруш** *ф.* 1. Шәраб сатучы. 2. Исерткеч эчемлекләр кибете хуҗасы.

**Мәйгосар** *ф.* Шәраб эчүче, шәраб эчәргә яратучы, сәрхүш, исерек.

**Мәкаль** г. Әйтем, әйтелгән сүз яки басылып чыккан мәкалә.

**Мәкам** *г.* 1. Халәт, урын, позиция. 2. Урын; бар нәрсәдән әүвәл, элек. 3. Дәрәҗә, әһәмият, тоткан урын. 4. Изге кеше кабере, төрбә, мавзолей. 5. Музыка сәнгатендә кулланыла (мәкам, көй, тон).

Мәкамә *г.* Әдәби әсәрнең бер төре. Мондый әсәр сузынкырак итеп, көйләбрәк башкарыла.
Мәкер *г.* 1. Астыртын, яшертен эш йөртү, хәйлә. 2. Алдау, төрле бозыклыклар эшләү, ялганлау.
Мәккяр *г.* 1. Астыртын гына бозыклык эшләүче, әчкерле. 2. Алдакчы, мәкерле.
Мәкруһ *г.* 1. Начар, ямьсез, сөйкемсез. 2. Дин кануннары тарафыннан кире кагылган, инкяр ителгән. 3. Рәнҗетү, көч куллану, җәбер.
Мәксүр *г.* 1. Сындырылган, ватылган, җимерелгән. 2. Җиңелгән. 3. Кайгылы, хәсрәтле, сызланулы, әрнүле.
Мәктүб *г.* 1. Кем тарафыннандыр язылган. Мәктүб галәйһи — язмыш кушканча. 2. Хат, мәктүб.
Мәкшүф *г.* 1. Ачылган (исәп-хисап). 2. Ап-ачык, капланмаган, шәрә, ялангач. 3. Яклау, саклау чарасы күрелмәгән, яклаусыз.
Мәкъбәрә *г.* Каберстан, зират.
Мәкъбүл *г.* 1. Кабул ителгән, хупланган. 2. Ярашлы дип табылган, күңелгә ятышлы.
Мәкъсуд *г.* 1. Теләгән теләк, ният. 2. Алдан ук уйлап эшләнгән, ниятләнгән. 3. Максат, мәгънә, омтылыш, теләк.
Мәкъсур *г.* 1. Чикләнелгән. 2. Кыскартылган, кыска.
Мәкъсүм *г.* Бүлгәләнгән, өлешләнгән, аерылган.
Мәкътуг *г.* 1. Киселгән, өзелгән. 2. Мәктугъ әләмәл — өмете өзелгән, өмете киселгән.
Мәктүл *г.* 1. Үтерелгән. 2. Корбан ителгән.
Мәкәтибе ибтидаия *г.* Башлангыч мәктәпләр.
Мәкәтибе рөщдия *г.* Урта мәктәпләр.
Мәлгунь *г.* 1. Ләгънәт укылган, куылган, сөрелгән. 2. Әлмәлгунь — шайтан.
Мәллях *г.* 1. Диңгезче, матрос. 2. Диңгез гизүче.
Мәлфуз *г.* Әйтелгән, сөйләнелгән, ләфыз ителгән.

Мәлямәт *г.* Шелтә.
Мәләкә *г.* 1. Ия булу, үзеңне тоту. 2. Идарә итү
Мәләкәт *г.* Осталык, сәләт, үзләштерелгән сыйфат.
Мәләкүт *г.* Патшалык. Мәләкүт әссәмауәт — күктәге патшалык; фәрештәләр патшалыгы, рухлар дөньясы.
Мәмалик *г.* Патшалыклар, дәүләтләр, империяләр.
Мәмәлике хариҗия *г.* Чит патшалыклар, дәүләтләр, чит илләр.
Мәмдүх *г.* Макталган, дан җырланган (шигырьләрдә, касыйдәләрдә һ. б.).
Мәмләкәт *г.* Дәүләт, патшалык, империя, корольлек.
Мәмнүгъ *г.* Тыелган, рөхсәт ителмәгән.
Мәмнүниять *г.* 1. Разый булу, канәгать булу. 2. Разыйлык, канәгатьлек.
Мәнар *г.* Яктылык чыганагы, маяк.
Мәнаҗис *г.* Пычраклыклар, әшәке нәрсәләр.
Мәнбәгъ *г.* Чишмә башы, чыганак. Елга башланган урын.
Мәндил *г.* Кулъяулык.
Мәнзара *г.* Күренеш, панорама, рәсем, пейзаж. Табигать күренешләре төшерелгән рәсем, сурәт.
Мәнзил *г.* Торак йорт, квартира, өй.
Мәнзум *г.* 1. Тезелгән, оештырылган. 2. Шигырь тезмәсе.
Мәни *г.* Нәсел орлыгы.
Мәнкуль *г.* 1. Тапшырыла торган. 2. Күчерелә торган. 3. Берәр телдән алынган, кабул ителгән сүз (алынма сүз).
Мәннан *г.* Шәфкатьле, нигъмәт бирүче. Әлмәннану — бөек шәфкать иясе булган Аллаһының эпитеты.
Мәнси *г.* Онытылган.
Мәнсуб *г.* 1. Куелган, бер урынга беркетелгән, билгеләнгән. 2. Грамматика фәнендә «төшем килешендә» мәгънәсен белдерә.

**Мәнсур** *г.* 1. Җиңүче, тантана итүче. 2. Җиңгән кеше.
**Мәнсүб** *г.* 1. Берәр нәрсәгә карашлы. 2. Үзенең чыгышы (нәсел шәҗәрәсе) белән билгеле булган. 3. Бик шәп, бик яхшы.
**Мәнсүҗ** *г.* Тукылган, тукып эшләнгән, сугылган.
**Мәнфәгать** *г.* 1. Файда, кызыксыну, табыш. 2. Яхшылык, игелек.
**Мәрасим** *г.* Йола, тантана. Церемония.
**Мәрви** *г.* Риваять ителгән, сөйләнелгән, хикәя кылынган.
**Мәргызар** *ф.* Болын, алан, болынлык.
**Мәрд** *ф.* Ир кеше, ир-егет.
**Мәрдан** *ф.* 1. Батыр, ир-егет. 2. Зыялы кеше.
**Мәрди** *ф.* Батырлык, зыялылык.
**Мәрзыя** *г.* Күркәм, канәгатьләнерлек, һәр кеше тарафыннан кабул ителгән.
**Мәриз, мәрыйз** *г.* 1. Авыручы, авыру. 2. Пациент.
**Мәркәз** *г.* Үзәк, мәркәз.
**Мәррә** *г.* Бер тапкыр.
**Мәррәт** *г.* Күп тапкырлар, күп мәртәбәләр.
**Мәрсия** *г.* Вафат булган кешенең уңай, яхшы сыйфатларын сурәтләп язылган шигырь, сүз (элегия).
**Мәртәбә** *г.* 1. Дәрәҗә, баскыч. 2. Өстенлек, биләп торган урын.
**Мәрфугъ** *г.* 1. Күтәрелгән. 2. Грамматикада сүзнең баш килештә куелышын белдерә.
**Мәрхаба** *г.* Хуш киләсез, рәхим итегез.
**Мәрхәмәт** *г.* Шәфкатьлелек, миһербанлык, яхшылык; кызгана белү, аяу, кешенең хәленә керә белү.
**Мәрхүм** *г.* 1. Шәфкатьлелек күрсәтелгән (ир кеше). 2. Үлгән кеше («мәрхүм» дип, ислам динендә булып, дөньядан ахирәткә күчкән кешегә генә әйтелә).

**Мәрҗигъ** *г.* 1. Мөрәҗәгать итә торган урын. Белешмә, чыганак. 2. Кире әйләнеп кайту урыны, кайтачак җир.
**Мәрҗ** *г.* 1. Болын, көтүлек. 2. Тәртипсезлек, буталчыклык.
**Мәрҗүгъ** *г.* Кире борып кайтарылган.
**Мәсгадь, мисгадь** *г.* Югары күтәрү җайланмасы, лифт. Өстәге урын.
**Мәсгуд, мәсгут** *г.* Бәхетле ителгән, бәхетле.
**Мәсгудиять** *г.* Бәхетлеләр, бәхетле ителгәннәр.
**Мәскат рәәси** *г.* Туган урын, туган җир.
**Мәскән** *г.* Яши торган җир, торак йорт, өй.
**Мәслихәт** *г.* Киңәш, файдалы киңәш, файдалы булачагын әйтү.
**Мәсләк** *г.* 1. Юл, бару юлы, маршрут. 2. Дөньяга караш, тоткан юл, принцип.
**Мәсмугъ** *г.* Ишетелгән, ишетелә торган, аңлаешлы.
**Мәснугъ** *г.* (Санага) Эшләп чыгарылган, ясалган.
**Мәснугать** *г.* Хезмәтнең нәтиҗәсе. Фабрикада, заводта эшләп чыгарылган әйберләр. Ясалган әйберләр.
**Мәснәви** *г.* 1. Ике катлы, икеләтелгән, икешәр. 2. Икеюллыклардан торган рифмалы шигырь.
**Мәсрук** *г.* Кем тарафыннандыр урланган.
**Мәсрүр** *г.* Шатланган, шатлыклы, сөенгән, шат.
**Мәсхәрә** *г.* Көлкегә калу, хурлык.
**Мәсъүл** *г.* 1. Җавап бирүче, җавап тотучы кеше. 2. Соралган.
**Мәсраф** *г.* Тотылган акча, чыгым.
**Мәсруф** *г.* Сарыф ителгән, тотылган (күплек санында «мәсруфат»).
**Мәсҗүн** *г.* Төрмәгә утыртылган, тоткын.
**Мәтанәт** *г.* 1. Ныклык, түземлелек, катылык. 2. Мәһабәтлелек.

**Мәтен** *г.* 1. Арка. 2. Текст. 3. Нык, таза.
**Мәтийн** *г.* Нык, чыдам, каты.
**Мәтлуб** *г.* 1. Таләп ителгән, эзләнгән, кирәк булган. 2. Теләк, таләп.
**Мәтрүк** *г.* Калдырылган, ташлап ителгән.
**Мәфгуль** *г.* 1. Эшләнелгән, башкарылган. 2. Ачуланган.
**Мәфкудь** *г.* 1. Югалтылган, хәбәрсез югалган. 2. Юклык.
**Мәфруз** *г.* 1. Фараз ителгән,... дип уйланылган,... булса кирәк дип уйланылган,... булырга тиеш булган. 2. Кушылган, үтәлүе мәҗбүри булган.
**Мәфтух** *г.* 1. Ачык, ачылган булу. 2. Турыдан-туры, туптуры. 3. Басып алынган, сугышып алынган (ил, җир).
**Мәфтүн** *г.* Үз-үзен онытып сокланучы, башы-күзе әйләнгән. Гашыйк булган.
**Мәфһүм** *г.* 1. Аңлый торган, аңлашылган, аңлаешлы. 2. Күздә тотылган, аңларга мөмкин булган. 3. Төшенчә, концепция.
**Мәхбүб** *г.* Сөекле, яраткан, сөелгән (ир-егет).
**Мәхбүбә** *г.* Сөекле, яраткан, сөелгән (хатын-кыз).
**Мәхбүс** *г.* 1. Төрмәгә утыртылган; тоткын кеше. 2. Кулга алынган кеше.
**Мәхдүд** *г.* 1. Чикләнгән. 2. Билгеле бер кысада булу. 3. Соңгы (нокта, чик).
**Мәхдүм** *г.* Әфәнде, бай әфәнде, хуҗа, эш бирүче, эшкә яллаучы.
**Мәхзүн** *г.* Кайгылы, хәсрәтле, көенечле, моңлы.
**Мәхкәмә** *г.* Хөкем итә торган урын; суд.
**Мәхкүм** *г.* Хөкемгә тартылган, хөкем ителгән.
**Мәхлук** *г.* Җан иясе, яратылган җан иясе.
**Мәхмүд** *г.* Мактала торган, мактаулы.
**Мәхмүр** *г.* Исерек, исерткеч эчеп изрәгән булу.

**Мәхрук** *г.* 1. Яндырыла торган, яндырылган. 2. Җәзаланган.
**Мәхрәм** *г.* 1. Тыелган нәрсә. 2. Өйнең тыелган өлешенә (хатын-кызлар ягына) керергә рөхсәте булган кеше. 3. Якын туганнар белән никахлашуның ярамаслыгын аңлатучы сүз.
**Мәхрәме әсрар** *г.* Ышанычлы дус, серне саклый белә торган якын дус.
**Мәхрәҗ** *г.* 1. Чыгу урыны. 2. Артикуляция. 3. Зур тәрәт юлы.
**Мәхрүм** *г.* 1. Өлешсез калдырылган, читләштерелгән. 2. Бәхетсез, мескен. 3. Һәрвакыт уңышсызлыкка юлыгучы.
**Мәхрүс** *г.* 1. Саклана торган, коткарыла торган. 2. Ир бала, угыл бала, сабый.
**Мәхсуль** *г.* 1. Уңыш җыю, урып-җыю. Үстерелгән уңышны җыеп алу. 2. Эшләп чыгарылган. Берәр эш нәтиҗәсендә барлыкка килгән әйбер. 3. Нәтиҗә, уңыш.
**Мәхсулате зирагыйә** *г.* Авыл хуҗалыгында җитештерелгән, үстерелгән азык-төлек.
**Мәхсулате сынагыйә** *г.* Эшләп, ясап чыгарылган әйберләр (промышленность товарлары).
**Мәхсус** *г.* Аерым, үзенә генә хас булган үзенчәлек.
**Мәхфуз** *г.* 1. Сакланган, саклана торган. 2. Яттан өйрәнелгән.
**Мәхшәр** *г.* 1. Кыямәт көнендә барлык кешеләр бер урынга җыелырга тиеш булган мәйдан. 2. Халык төркеме, җыелыш.
**Мәхәллә** *г.* Шәһәрнең бер кварталы.
**Мәхҗүб** *г.* 1. Пәрдә белән ябылган, капланган, пәрдә корылган, пәрәнҗәле. 2. Сукыр.
**Мәхҗүз** *г.* 1. Тотып калынган, тоткарланган. 2. Берәр

нәрсәне алдан атап кую (билгеле бер максат өчен, эш өчен).

Мәшаих *г.* 1. Олылар, өлкәннәр, картлар. 2. Дин өлкәсендә эшләүче галимнәр. Шәйхүлислам — ислам дине кануннарын аңлатучы зур, өлкән галимнәр. 3. Галимнәр. 4. Укытучылар, өйрәтүчеләр.

Мәшаһир *г.* Билгеле булганнар, данлыклылар, танылган, мәшһүр кешеләр.

Мәшгуль *г.* Буш түгел, берәр эш белән шөгыльләнүче.

Мәшкүк *г.* (Шәккә). Шикле, шөбһәле.

Мәшкүр *г.* Рәхмәткә лаеклы, мактаулы.

Мәшмүл *г.* Эченә алган, кемнеңдер яклавы астында булган, кемнеңдер карамагында булу.

Мәшрикъ *г.* Кояш чыгу, көнчыгыш, шәрык.

Мәшруб *г.* 1. Эчелгән, эчертелгән. 2. Эчемлек.

Мәшрух *г.* Ачыкланган, аңлатылган. Шәрәхә Аллаһу садриһи — Аллаһ аның күкрәген, күңелен чын хаклыкны кабул итү өчен киң кылды; Мөхәммәт пәйгамбәр турында әйтелгән.

Мәшәккать *г.* Кыенлык, авырлык, уңайсызлык.

Мәшһәд *г.* 1. Җыелыш, бер урынга тупланган булу. 2. Җеназа. 3. Шәһид булган, изге урын. 4. Истәлекле урын.

Мәшһүр *г.* 1. Билгеле, данлыклы, танылган. 2. Дан казанган, танылган.

Мәәзүн (изнүн, үзнүн) *г.* 1. Казый тарафыннан никах укырга һәм талакны расларга рөхсәт бирелгән вәкил. 2. Рөхсәт ителгән.

Мәәмүн *г.* 1. Ышаныч казанган, ышанычлы. 2. Куркынычсыз, хәвефсез-хәтәрсез, имин. 3. Ышанычлы.

Мәәюс *г.* Ышанычын, өметен югалткан.

**Мәүкуф** *г.* 1. Туктатылган, тоткарланган. 2. Туктап тору шәкеле (пауза). 3. Берәр сәбәп белән, берәр нәрсәдән бәйле булу.

**Мәүкыйф** *г.* 1. Туктаган урын. 2. Халәт, мөнәсәбәт, ниндидер фикердә булу (позиция). 3. Тукталыш (автобуснык**ы**).

**Мәүла, мәүляна** *г.* 1. Галиҗәнаб, әфәнде. 2. Галиҗәнаб падишаһыбыз, патшабыз.

**Мәүлид, мәүлет** *г.* 1. Туган урын. 2. Бер изгенең туган көне. 3. Туган көн бәйрәме.

**Мәүләви** *г.* 1. Дәрвиш мәүләви (фарсы шагыйре нигез салган суфыйлар ордены, оешмасы әгъзасы).

**Мәүсим** *г.* Сезон, вакыт (урак вакыты, урып-җыю вакыты). **Мәүсимүл хаҗ** — хаҗга бару вакыты.

**Мәүсук** *г.* Ышанырлык, таянырлык, ышана торган, хак, чын.

**Мәүте мүфәҗҗат** *г.* Кинәт, көтелмәгәндә вафат булу.

**Мәүҗүд** *г.* 1. Табылган, бар булган. 2. Тормышта бар булган, чынбарлыкта булган, реаль.

**Мәҗаль** *г.* 1. Урын. 2. Киңлек (мохит). 3. Кыр, арена, өлкә, (гыйлем, фән өлкәсе). 4. Әйләнә-тирә, мохит. 5. Көч, җегәр, мөмкинчелек.

**Мәҗбүр** *г.* Ирексезләнгән, мәҗбүр ителгән.

**Мәҗзүб** *г.* 1. Сиземләүнең иң югары ноктасында булу (экстазда булу). 2. Нормаль халәттә булмаган, мәҗнүн. 3. Бертөрле уй, хыял, ният белән тулысынча урап алынган, мөкиббән китеп мавыккан. 4. Суфыйларга бирелә торган дәрәҗә (өченче дәрәҗәле, экстаздагы суфый).

**Мәҗийд** *г.* 1. Данлы. **Әлкитабул мәҗийд** — Коръән. 2. Затлы, дәрәҗәле кеше.

**Мәҗлүб** *г.* Җәлеп ителгән, тартылган, табылган.

**Мәҗмугъ** *г.* 1. Тупланган, җыйналган. 2. Барысы бергә, бергәлектә. Нәтиҗә. 3. Коллектив.
**Мәҗмуга** *г.* Туплам, җыентык, коллекция.
**Мәҗнүн** *г.* Котырган, тилергән, акылсыз.
**Мәҗрух** *г.* Яраланган, җәрәхәтләнгән.
**Мәҗәллә** *г.* Журнал, вакытлы матбугат, кодекс.
**Мәҗүси** *г.* Утка яки төрле сыннарга табынучы.
**Мәҗҗанән** *г.* Бушлай, түләүсез.
**Мәҗһүл** *г.* Билгесез, хәбәре булмаган.
**Мәһабәт** *г.* 1. Курку, өркү. 2. Хөрмәтләү, ихтирам итү. 3. Бөеклек, күңелгә курку салырдай бөеклек.
**Мәһәр** *г.* Бирнә, калым.
**Мөбарәк** *г.* Кадерле, бәхетле, уңайлы, уңышлы, хөрмәтле.
**Мөбасыйр** *г.* Күзәтеп торучы, күзәтүче.
**Мөбахис** *г.* 1. Сөйләшүче, бәхәс коручы, сүз көрәштерүче 2. Тикшерүче, галим кеше.
**Мөбашир** *г.* 1. Башкаручы, үтәүче, үткәрүче. 2. Туры, турыдан-туры. 3. Мөдир, тәртип саклап торучы.
**Мөбашәрәт** *г.* 1. Башкару, уздыру, үткәрү (берәр эшне, сәясәтне), башкарып чыгу. 2. Эш, шөгыль.
**Мөбаянәт** *г.* 1. Аерымлык, контраст. 2. Каршылык, туры килмәү, охшамау.
**Мөбаһи** *г.* Мактанучы, мактанчык.
**Мөбин** *г.* 1. Ап-ачык, күренеп тору. 2. Дөреслек белән ялганны аера белүче.
**Мөбтәдә** *г.* 1. Башы, башлангыч, башлау. 2. Исем җөмләнең иясе.
**Мөбтәля** *г.* Авыручы, берәр авырудан интегүче. Нинди дә булса бәхетсезлеккә дучар ителү.
**Мөбәддәл** *г.* Үзгәргән, алмаштырылган.
**Мөбәррид** *г.* Суыткыч, салкынлык ясаучы (кондиционер).

**Мөбәшир** *г.* (бәшәрә) 1. Башкаручы, уздыручы, алып баручы. 2. Турыдан-туры.
**Мөбәшшир** *г.* Миссионер, дингә өндәүче, дин таратучы. Инҗил тарафдары.
**Мөгаййән** *г.* Билгеләнгән, тәгаенләнгән, ачыкланган. Анык.
**Мөгаллим** *г.* 1. Өйрәтүче, укытучы. Мәдрәсәтүл мөгаллимийнә — укытучылар семинариясе. 2. Оста, мастер, хуҗа кеше.
**Мөгаләҗә** *г.* 1. Дәвалау. 2. Төзәтү. 3. Әзерлек (эш алдыннан). Игътибар белән тикшереп чыгу, хәл итү, эшкәртү.
**Мөгаммәр** *г.* 1. Озак яшәүче, озын гомерле, бик өлкән кеше. 2. Торгызылган, яңартылган, төзәтелгән.
**Мөгамәлә** *г.* 1. Эш йөртү, аралашу. 2. Мөнәсәбәттә булу. 3. Эш, сәүдә.
**Мөдәфәга** *г.* Яклау, каршы тору.
**Мөдахәлә** *г.* Тыкшыну, катышу, арага керү.
**Мөдаһәнә** *г.* Икейөзлелек, ялагайлык.
**Мөддәгый** *г.* 1. Дәгъва белдерүче, таләп итүче, даулап йөрүче. 2. Гаепләүче.
**Мөддәт** *г.* Вакыт, ара, күпмедер вакыт узу.
**Мөдир** *г.* 1. Идарә итүче, баш кеше, җитәкче. 2. Югары уку йорты башлыгы (ректор). 3. Гарәп илләрендә *провинция башлыгы, хәким* мәгънәсендә гамәлгә кергән.
**Мөдәррис** *г.* Дәрес бирүче, укытучы, педагог.
**Мөдәүәр** *г.* Түгәрәк, йомры, туп сыман.
**Мөдһиш** *г.* Искитмәле, гаҗәпләнерлек, күз явын алырлык, бик гүзәл.
**Мөзәййән** *г.* Матурланган, бизәлгән, зиннәтләнгән, җыештырылган, яхшыланган.
**Мөзәккәр** *г.* Ир-җенес.
**Мөкаддәм** *г.* 1. Алда куелган. 2. Алдан ук түләп

куюь. 3. Җитәкче, башлык, мөдир. 4. Гаскәри дәрәҗә. 5. Элек, әүвәл.
Мөкаддәр г. 1. Билгеләнгән, бәяләнгән, бәя куелган. 2. Күздә тотылган. Алдан ук хәл ителгән, алдан ук билгеләп куелган. Алдан ук билгеләнгән (язылган язмыш).
Мөкаддәс г. 1. Изге, кагылырга ярамый торган. 2. Изге йорт — Әлбәйтүл мөкаддәс (Иерусалим). Изге җирләр — Әларадыйль мөкаддәсә (Фәләстыйн, Мәккә һәм Мәдинә шәһәрләре).
Мөкарриб г. Якынайтучы, якынлаштыручы, якын итүче.
Мөкаррар г. 1. Хәл ителгән, карар кылынган, билгеләнгән, билгеләп куелган. 2. Салым (налог).
Мөкауи г. Көч-куәт бирә торган, ныгытучы.
Мөкауият г. Ярдәм итә, көч бирә, хәлне яхшырта торган дарулар һәм башка дәвалау чаралары.
Мөкиббән г. Авышу, егылып китәрдәй булып мавыгу. Берәр нәрсә белән чаманы белмичә мавыгып китү, табыну.
Мөкяфәт г. 1. Берәр эшне башкарган өчен бирелә торган бүләк. 2. Компенсация.
Мөкәләмә г. Гәпләшү, сөйләшү.
Мөкәррәм г. Хөрмәт ителә торган, хөрмәтле.
Мөкәррәр г. Кабатлап эшләнелгән, башкарылган.
Мөмарәсә г. 1. Уздыру, башкару, эшләү, үтәү, практика. 2. Тәҗрибәлелек.
Мөмтаз г. 1. Аерылып торган, кайсыдыр сыйфат белән дан казанучы, танылган, менә дигән, шәп. 2. Өстен булган, өстен торган. 3. Махсус.
Мөнакашә г. Тикшерү, сөйләшеп алу, фикер алышу.
Мөнасиб г. 1. Яраклы, туры килә торган, ярашлы булу. 2. Бәрабәр килә торган, бер-берсенә ярашлы.
Мөнаҗат, мөнәҗәт г. 1. Котылу, арыну, ирекле булу

(яман уйдан, нияттән, эштән). 2. Пакьләнү (күңелдәге авыр уйлардан, кайгылардан яклау эзләп ялвару (Аллаһыга). Фарсы телендә Аллаһ белән яшертен генә «аралашу», ялгыз гына гыйбадәт кылу, төнлә белән дини эчтәлекле шигырьләрне көйләп башкаруны аңлата.

Мөндәриҗә *г.* 1. Кертелгән, теркәлгән. 2. Эчтәлек.

Мөнзир *г.* 1. Алдан хәбәр бирүче, хәвеф-хәтәр турында алдан ук кисәтеп куючы. 2. Хәбәр итә торган, сигнал бирә торган җиһаз.

Мөнийб г. Дөрес, туры юлга әйләнеп кайтучы, дөрес юлга күнүче, эшләгән ялгышларын аңлап, дөрес, яхшы юлга кайтучы, дөрес итеп яши башлаучы. Мөнийбү иләллаһи — үзенең гөнаһларын ярлыкауны сорап Аллаһыга ялваручы кеше.

Мөнир *г.* Яктылык бирүче, яктыртучы, нур өләшүче. Әлмәдинәтүл мөнәүара — нур сибүче, яктыртып торучы, нурлыларның иң нурлысы булган шәһәр (Мәдинә шәһәренең эпитеты).

Мөнәббиһ *г.* 1. Уятучы. 2. Ярсытучы, дәртне арттыручы. 3. Кисәтүче.

Мөнәззаф *г.* (нәзафа). Тазаланган, аруланган, әрчелгән.

Мөнкарыз *г.* 1. Өзелгән, тукталган, яшәүдән туктаган, үлгән, сүнгән, югалган.

Мөнкир *г.* 1. Кире кагучы, бар дип танымаучы, кабул итмәүче. 2. Мөнкир һәм Нәкир — кабердә мәетләрдән сорау (сөаль) алучы фәрештәләр.

Мөнтәкыйдь *г.* Тәнкыйтьләүче, тәнкыйтьче.

Мөнши *г.* 1. Нигез салучы, иҗат итүче, ясаучы, оештыручы. 2. Төзүче. 3. Автор. 4. Редактор, стилист.

Мөнәббиһ *г.* 1. Уятучы. 2. Кисәтүче. Сәгатү мөнәббиһ— чылтырап уятучы сәгать.

**Мөнәввир, мөнәүир** *г.* 1. Нур сибүче, яктыртучы. 2. Мәгърифәтле.

**Мөнәҗҗим** *г.* Йолдызлар санаучы, астролог, астроном.

**Мөнҗи** *г.* Коткаручы.

**Мөнҗәмид** *г.* Туңган, бозга әйләнгән, каткан.

**Мөрасәлә** *г.* Корреспонденция, хат алышу.

**Мөрафикъ** *г.* 1. Озатып баручы, юлдаш. 2. Дус яшәү, дус мөнәсәбәттә булу.

**Мөрдар** *ф.* 1. Үләксә. 2. Пакь булмаган, әшәке.

**Мөрид** *г.* 1. Берәүнең тәгълиматына иярүче, шәкерт. 2. Шәкерт суфый (суфыйларга бирелә торган беренче дәрәҗә).

**Мөрсәлийн** *г.* 1. Җибәрелгәннәр, илчеләр. 2. Миссионерлар.

**Мөртәд** *г.* 1. Диненнән язган, мөртәт. 2. Ренегат.

**Мөршид** *г.* Җитәкләүче, дөрес юлга күндерүче.

**Мөраббә** *г.* Кайнатма яки кайнатылган (варенье).

**Мөраббин** *г.* Тәрбияләүче, җитәкләп баручы, өйрәтүче.

**Мөрәккәб** *г.* 1. Катлаулы, тезмә, тезелгән, бергә җыелган. 2. Катлаулы, кушма, кушып әзерләнгән (дару составы).

**Мөрәүәт, мөрәвәт** *г.* 1. Олы җанлылык, киң күңелле булу. 2. Кешелеклелек, миһербанлылык, егетлек, намуслылык, гафу итә белү, игелеклелек, кеше хәленә керә, аңлый белүчәнлек сыйфаты.

**Мөрәҗәгать** *г.* 1. Карап, тикшереп чыгу. 2. Чагыштыру, янәшә куеп карау, күздән кичереп чыгу, туры килүкилмәвен тикшерү. 3. Кемгә дә булса эндәшү, сүз кушу. Берәр йомыш белән мөрәҗәгать итү, берәр оешмага, даирәгә рәсми рәвештә хат юллау, мөрәҗәгать итү.

**Мөсабәка** *г.* Узышу, ярышу, конкурс.

**Мөсагад** *г.* 1. Ярдәм итү, булышу, таяныч булу, ярдәм кулын сузу. 2. Үзара ярдәмләшү.

**Мөсафир** *г.* 1. Сәяхәтче. 2. Юлаучы, юлда баручы, узгынчы, 3. Кунак.
**Мөстәкъбил** *г.* Каршы алучы.
**Мөстәкъбәл** *г.* Киләчәк, киләчәк заман.
**Мөстәкыйль** *г.* Бәйсез, үз-үзенә хуҗа, буйсынмаучы.
**Мөстәфад** *г.* Файдаланылган, башка чыганаклардан алынган.
**Мөсәгыйд, мөсәгыйт** *г.* Ярдәм итүче, ярдәмчел, булышучан.
**Мөтәвәлли** *г.* Мөдир, идарә итүче, мәчет эшләре белән идарә итүче.
**Мөтәәссир** *г.* 1. Тирән тәэсирләнү астында булган кеше. 2. Кайгыдан яки берәр бәхетсезлектән иза чигүче, интегүче.
**Мөтәәссиф** *г.* Кайгыру, кызгану, үкенүне белдерү.
**Мөфти** *г.* 1. Дин кануннарына таянып тиешле карарны чыгаручы, фәтва бирүче. 2. Руханилар башлыгы.
**Мөфәккир** *г.* 1. Уйлаучы, фикерләүче. 2. Акыл хезмәте белән шөгыльләнүче. 3. Акыл иясе, зыялы кеше.
**Мөфәррих** *г.* Шатландыручы, шатлыклы, күңелле.
**Мөфәссир** *г.* Аңлатучы, җентекләп аңлатучы, комментарий бирүче.
**Мөхакәм** *г.* Судта тикшерү, процесс.
**Мөхаләфә** *г.* Килешү төзү.
**Мөхиббанә** *г.* Яратып, сөеп, дусларча.
**Мөхибулла** *г.* Аллаһының сөеклесе.
**Мөхәммәт** *г.* Мактаулы, макталган.
**Мөхтәрәм** *г.* Хөрмәтле, хөрмәт ителгән.
**Мөхтәсиб** *г.* Тикшереп торучы, инспектор.
**Мөхәррир** *г.* 1. Азат итүче, коткаручы. 2. Язучы, журналист. 3. Редактор.
**Мөхәррәм** *г.* 1. Тыелган. 2. Тыюлы. 3. Мөхәррәм ае — Ай календареның беренче ае (утыз көннән гыйбарәт).

**Мөшарәкәт** *г.* 1. Бергәлек, гомумилек. 2. Катнашу. 3. Хезмәттәшлек итү.
**Мөшкил, мөшкел** *г.* 1. Кыен, ачык булмаган, буталчык. 2. Кыенлык.
**Мөшрик** *г.* Мәҗүси, потларга табынучы.
**Мөштәри** *г.* 1. Сатып алучы. 2. **Әлмөштәри** — Юпитер.
**Мөшфикъ** *г.* Шәфкатьле, шәфкать күрсәтүче.
**Мөшфиканә** *г.* Шәфкатьлелек белән, киң күңеллелек күрсәтеп.
**Мөшәддәд** *г.* 1. Ныгытылган, көчәйтелгән, ассызыклап әйтелгән. 2. Тәшдидле булу (гарәп язуында хәрефне икеләтеп, көчәйтеп укуны күрсәтүче билге).
**Мөшәррәф** *г.* Хөрмәтле, хөрмәткә лаеклы, мөхтәрәм.
**Мөэмин** *г.* Ышанучы, хак диндәге кеше.
**Мөяссәр, мияссәр** *г.* 1. Җиңеләйтелгән булу. 2. Уңышлы, уңайлы, җайлы, җиңел. 3. Үтемле, җиңел кабул ителә торган тел белән язылган булу. 4. Бай, хәлле кеше.
**Мөәддиб** *г.* Укытучы, тәрбияче.
**Мөәззин** *г.* 1. Гыйбадәткә чакырып азан әйтүче. 2. Азанчы, азан әйтүче.
**Мөәллиф** *г.* 1. Автор, китап авторы, китапны төзүче. 2. Композитор.
**Мөәррих** *г.* Тарихчы, тарих турында язучы.
**Мөәссәсә** *г.* Оешма, институт.
**Мөҗиб** *г.* Җавап бирүче.
**Мөҗәррәб** *г.* 1. Тәҗрибәле. 2. Сыналган, тикшерелгән.
**Мөҗәүһәрат** (җәүһәр) *г.* Кыйммәтле бизәнү әйберләре, асылташлар, алтын алкалар, йөзекләр һ. б.
**Мөҗәһһиз** (җәһәзә) *г.* Җиһазлаучы, әзерләүче. Әзер булу.

**Мөҗәһид, мөҗәһит** *г.* Хаклык өчен көрәшүче. Көрәшче, сугышчы.

**Мөһаҗир** *г.* 1. Күчүче, чит җиргә күчеп китүче (эммигрант). 2. Әлмөһаҗир — Мөхәммәт пәйгамбәр белән бергә Мәккә шәһәреннән Мәдинә шәһәренә күчеп китүче.

**Мөһим** *г.* Җитди, кирәкле, мөһим.

**Мөһер** *г.* Штамп, мөһер.

**Мөһәндис** *г.* Инженер, механик.

# Н

**Нагяһ** *г.* 1. Көтмәгәндә, кинәттән, кинәт кенә. 2. Очраклы гына, уйламаганда. 3. Урынсыз, вакытсыз.

**Надан** *ф.* Белемсез, белеме юк кеше.

**Надим** *г.* Үкенүче, тәүбә итүче.

**Надир** *г.* Сирәк очрый торган, гадәти булмаган.

**Назыйм** *г.* 1. Оештыручы. 2. Шигырь язучы.

**Назил** *г.* Төшкән, кем тарафыннандыр иңгән булу, төшерелү.

**Наил** *г.* 1. Алучы, кабул итеп алучы. 2. Бүләк 3. Файда.

**Налаекъ** *ф. г.* Лаек булмаган, лаек түгел.

**Нам** *ф.* Исем, шөһрәт, дан.

**Намаз** *ф.* Гыйбадәт.

**Намдар** ф. Билгеле булган, танылган, шөһрәтле.

**Намзәд** *ф.* 1. Кияү егете; кәләш; ярәшкән булу. 2. Кандидат.

**Намәгъкуль** *ф. г.* 1. Акылга сыймый торган, кирәксез, мантыйксыз. 2. Яраксыз, ярашлы булмаган, әдәпсез, әхлаксызлык.

**Намәгълүм** *ф. г.* Билгесезлек, хәбәрсезлек.

**Намәхрәм** *ф.* 1. Чит, ят; сереңне ышанып сөйләргә ярамый торган чит кеше. 2. Якын булмаган туган кеше (шәригать кануннары буенча мондый туган белән никахлашырга рөхсәт ителә).

**Наразый** *ф. г.* Ризалашмау, канәгать булмау.

**Насыйх** *г.* Чын күңелдән яхшы киңәш бирүче.

**Насыйханә** *г. ф.* Үгетләү буларак, яхшы киңәш итеп, үгетнәсыйхәт итеп.

**Натавон** *ф.* 1. Көче булмаган, ярлы-ябагай, фәкыйрь кеше. 2. Ярлы, зәгыйфь..

**Нахак** *ф. г.* Дөрес булмаган, дөрес түгел.

**Нахия** (нәуәхә) *г.* Урын, квартал, район, йорт-җир.

**Нахуш** *ф.* Яхшы түгел, начар.

**Начар** *ф.* (*на* + *чарә*) Чарасыздан, ирексездән. Начар, яман.

**Нашир** *г.* Таратучы, бастыручы, бастырып таратучы.

**Нигъмәт** *г.* 1. Муллык, мул тормыш, бәхетле тормыш. 2. Бүләк, шәфкатьлелек, муллык.

**Нигъмәтулла** *г.* Аллаһының рәхим-шәфкате белән иңдерелгән яхшылык, муллык, бәхет.

**Низагъ** *г.* 1. Бәхәс, ызгыш-талаш, гауга. 2. Көрәш, бәрелеш.

**Низам** *г.* 1. Тәртип, система, кагыйдә. 2. Устав, берәр оешманың эчке тәртип кагыйдәләре (институтның, заводның һ. б.).

**Никях, никах** *г.* Өйләнү, өйләнешү.

**Нилүфәр** *ф.* Төнбоек.

**Нисбәт** *г.* 1. Бәйләнешле, мөнәсәбәтле булу. Туганлык элемтәсе булу. 2. Тиңләштерү, чагыштыру. 3. Үлчәм (размер), сан.
**Нишан** *ф.* 1. Билге, тамга, эз. 2. Аерымлык билгесе, орден.
**Нохсан** *г.* 1. Азаю, киму. 2. Җитешсезлек, дефект.
**Нохтаи назар** *г.* Караш; берәр нәрсәгә, эшкә карата булган фикер, караш.
**Нургали** *г.* Бөеклекнең нуры.
**Нуре гаршеллаһ** *г.* Аллаһының күктәге тәхете нуры.
**Нурзаһид** *г.* Пакьлек, сафлык нуры. Динле кеше.
**Нурҗиһан** *г.* ф. Дөньяның нуры, дөнья күрке.
**Нурҗәлал** *г.* Бөеклек, зыялылык нуры. Мөхтәрәм кеше.
**Нурҗәмал** *г.* Матурлык, гүзәллек чагылышы, нуры.
**Нәбавәт** *г.* Илчелек, пәйгамбәрлек.
**Нәби** *г.* Пәйгамбәр.
**Нәбиулла** *г.* Аллаһының пәйгамбәре.
**Нәгузе биллаһи** *г.* Аллаһыга сыенабыз;Аллаһ безне якласын, сакласын.
**Нәзакәт** *ф.* 1. Мөлаемлык, әдәплелек, матурлык. 2. Үзүзеңне тәртипле тоту; мөгамәләдә әдәплелек.
**Нәзар** *г.* Карау, күзәтү, күрү, күреп тору, күз-колак булу.
**Нәзари** *г.* 1. Күз белән күргән хәлдә. 2. Теоретик.
**Нәзер** *г.* Тантаналы рәвештә ант итү. Берәр эш уңаеннан Аллаһыга ант итү, нәзер әйтү.
**Нәзыйф** *г.* Пакь, саф. Нәзыйфүл-әхлак — саф йөрәкле, бик әхлаклы кеше.
**Нәккаш** *г.* Төрле бизәкләр төшерүче, рәсемче, гравер.
**Нәкыш** *г.* Бизәк, рәсем, чокып ясалган рәсем, язу.
**Нәкышбәнди** *г. ф.* 1. Рәсем, сурәт ясаучылык, бизәк ясаучылык, төшерүчелек. 2. Баһаведдин Нәкышбәнди тәгълиматына иярүчеләр.

Нәмунә *ф.* Үрнәк, мисал, өлге.
Нәргис *ф.* 1. Нәргис гөле (сары төстәге гөл). 2. Гүзәл кызның күзләре.
Нәсер *г.* 1. Чәчү, сибү, тарату. 2. Чәчмә әсәр, проза.
Нәсәб *г.* 1. Нәсел, ыруг, ата-бабалар. 2. Элемтә, мөнәсәбәт.
Нәтиҗә *г.* Йомгаклау, нәтиҗә ясау.
Нәфасәт *г.* Кыйммәтлелек, гүзәллек, матурлык, күркәмлек.
Нәфес *г.* 1. Рух, җан, кеше, зат. 2. Эчке тойгы, кичереш. 3. Үз, үзе, үзем, үзең. (Күплек санында «нөфүс»).
Нәфис *г.* 1. Кыйммәтле, бәһале, бик бәһале. 2. Матур, нечкә.
Нәфрәт *г.* Бизү, яратмау, җирәнеп карау, күралмау.
Нәфәс *г.* 1. Сулыш, сулау. 2. Ысул, стиль.
Нәхәуи, нәхәви *г.* Грамматикага бәйләнешле булган.
Нәхү *г.* Синтаксис.
Нәшрият *г.* Басмаханә. Китап бастырып таратучы идарә.
Нәүбәт *г.* 1. Чират, вахта. 2. Авырган чорда иң югары ноктага җиткән вакыт (кризис, приступ).
Нәүмиз *ф.* Өметсез, ышанычы калмаган.
Нәүрүз *ф.* Яңа көн; Иран календареның яңа ел башы. Елның беренче көне (21 нче мартка туры килә).
Нәҗасәт *г.* 1. Пычраклык, пакьсезлек, шакшылык. 2. Пычрату, мыскыллау, мәсхәрәләү.
Нәҗем *г.* Йолдыз.
Нәҗиб *г.* 1 Затлы, зыялы нәселдән чыгучы. 2. Булдыклы, акыллы, талантлы.
Нәҗми *г.* Йолдызлы, яктылыклы, нурлы.
Нәзһәт *г.* Күңел ачу, сәяхәт итү.

Нөмаиш *ф.* 1. Күрсәтү, күрсәтү өчен кую, күргәзмә, экспозиция. 2. Тамаша күрсәтү, тантана уздыру.
Нөсхә *г.* Данә, нөсхә, экземпляр.
Нөхас *г.* Бакыр (казылма байлык). Бакыр акча.

# О

Остаз, остад *г.* Өйрәтүче, укытучы.
Осуле кадим *г.* Иске метод (белән), иске тәртип.
Осуле җәдид *г.* Яңа метод, яңа кагыйдә (ләр).
Осуль *г.* 1. Нигезләр, принциплар, кагыйдәләр, төп кануннар. 2. Метод, алым.
Офык *г.* Горизонт. Күкнең җир яки су өсте яссылыгы белән тоташкан сыман булып күренгән сызыгы.
Охра, ухра *г.* Башка, бүтән, икенче.

# П

Пабис *ф.* Тоткын.
Паборжо *ф.* Бер урында торучы.
Падишаһ *ф.* Патша.
Пай *ф.* Аяк.
Пайман *ф.* Килешү, вәгъдәләшү.
Падәри бозорг *ф.* Дәү әти, бабай.

Пайтәхет *ф.* Башкала.
Пакдоман *ф.* Намуслы, саф, пакь.
Пакизә *ф.* Саф, керсез, пакь (хатын-кыз).
Парча *ф.* Тукыма, өлеш, кисәк.
Парә *ф.* Өлеш, кисәк.
Пасдар *ф.* Каравылчы, сакчы, сакта торучы.
Пирая *ф.* Бизәк, матурлык.
Пишрав *ф.* Юл салучы, башлап йөрүче.
Пишә *ф.* Эш, һөнәр.
Потпәрәст *ф.* Потка табынучы.
Пәйда *ф.* Барлыкка килү.
Пәнҗ *ф.* Биш.
Пәнҗ пайә *ф.* Биш аяк.
Пәнҗәрә *ф.* Тәрәзә.
Пәрвасыз *ф.* Игътибарсыз, саксыз.
Пәрваз *ф.* Очу, һавага очу.
Пәрванә *ф.* 1. Күбәләк. 2. Хәбәр китерүче.
Пәри *ф.* 1. Җеннәр арасындагы гүзәл. 2. Матур, гүзәл кыз.
Пәришан *ф.* Таркалган, таркау. Кайгылы, борчулы.
Пәрәст *ф.* Берәр нәрсәгә табынучы.
Пәһлеван *ф.* Зур көчкә ия булучы, батыр.

## Р

Раббани *г.* Аллаһыныкы, илаһилык.
Раббе *г.* 1. Аллаһ. 2. Хуҗа, ия булучы.
Раббелгаләмийн *г.* Дөньялар хуҗасы.

**Раббәна** *г.* Аллаһыбыз.
**Рабигыйль ахыр** *г.* Һиҗри календареның дүртенче ае.
**Рабигыйль әүвәл** *г.* Һиҗри календареның өченче ае.
**Рабит** *г.* Бәйләп, тоташтырып торучы, элемтәче.
**Ракыйб** *г.* Күзәтеп, карап, тикшереп торучы.
**Раст** *ф.* Чын, хак, дөрес.
**Рауза** *г.* Болын, бакча, гөлбакча.
**Рахман** *г.* Миһербан, шәфкать иясе (Аллаһының эпитеты).
**Рашад, Рашат** *г.* 1. Аң, аңлылык. 2. Дөрес, аек фикердә булу. 3. Акылның өстенлек итүе.
**Риваять** *г.* Хикәя; сөйләү; роман.
**Ригая** *г.* Кайгырту, карау, игътибарлы булу.
**Ризван** *г.* 1. Канәгать булсын. **Ридвану Аллаһу галәйһи** — Аллаһ аңардан канәгать булсын. 2. Оҗмах капкасын саклаучы фәрештә.
**Ризык** *г.* Яшәү, тереклек өчен кирәкле ашамлык, азык-төлек.
**Рисалә, рисаләт** *г.* 1. Миссия, пәйгамбәрлек миссиясе. 2. Хат, трактат, дипломатик нота.
**Рисвай** *ф.* Оят, хурлык. Намуссызлык.
**Рифгать (рәфәга)** *г.* Күтәрелү, югарыга менү.
**Рихләт** *г.* Сәяхәт, күчеп китү, миссия.
**Ришвәт** *г.* Үз файдасына берәр эшне эшләтү өчен бирелә торган акча, бүләк.
**Рия** *г.* Икейөзлелек, күз буяучылык.
**Рияз, риязый** *г.* 1. Болын, бакча. 2. Математика фәне белән мавыгучы.
**Робагый** *г.* 1. Дүртьюллык (шигырь), дүртле. 2. Квартет.
**Рузнаме** *ф.* 1. Газета. 2. Календарь.
**Рузә** *ф.* Ураза.
**Румия(ле)** *г.* Византияле, Грецияле.

**Рухани** *г.* 1. Дин башлыгы, җитәкчесе. 2. Рухи яктан, рухилык.
**Рәвеш** *ф.* Төс, ысул, рәвеш.
**Рәйхан** *г.* 1. Хуш исле гөл. 2. Гарәп каллиграфиясендә үзенчәлекле язу төре (рәйхани язуы).
**Рәкәгать** *г.* Гыйбадәт вакытында тезләнү, сәҗдә кылу.
**Рәһбәр** *ф.* 1. Юл күрсәтүче. 2. Җитәкче, юлбашчы.
**Рөшди** *г.* Урта мәктәп (элеккеге татар мәдрәсәләрендә балигъ-лыкка ирешкән балалар укый торган уку сыйныфы).

# С

**Сабах** *г.* 1. Иртәнге сафлык. 2. Яктыру.
**Сабир** *г.* Сабырлыклы, чыдам, түземле.
**Сабит** *г.* Нык, какшамас, курку белмәс, батыр.
**Сада** *ф.* Аваз, тавыш. Садои шәрык — шәрык тавышы, көнчыгыш авазы.
**Садака** *г.* Савап, әҗер өчен бирелә торган ярдәм. Хәер.
**Садыйк** *г.* Дус, эчкерсез дус.
**Саил** *г.* 1. Сораучы, сорашучы. 2. Сораныйп, теләнеп йөрүче.
**Саим** *г.* Ураза тотучы.
**Салават** *г.* 1. Догалар. 2. Ялварулар, намазлар.
**Салих** *г.* Яхшы, дөрес, тугрылыклы. Саф күңелле.
**Самигъ** *г.* Тыңлаучы, тыңлап торучы. Ишетүче.
**Самими** *г.* Чын күңелдән, саф.

**Самәд** *г.* 1. Үзгәрми торган, мәңге бетмәс. 2. Нык, чыдам.
**Санагать** *г.* 1. Эш, хезмәт, сәнгать. 2. Һөнәр, эш.
**Санаигы нәфисә** *г.* Матур сәнгать.
**Саниг** *г.* 1. Эшләп чыгаручы, ясаучы. 2. Хезмәткәр.
**Санубәр** *г.* Нарат.
**Санәм** *г.* Сын, сурәт, пот (мәҗүсиләрнең табына торган потлары).
**Санҗар** *ф.* 1. Ау бөркете. 2. Ялгызлык исеме. Сәлҗуклар династиясендәге солтан исеме.
**Сарыф** *г.* 1. Алмаштыру, ваклау (акчаны). 2. Сарыф итү, тоту, чыгым тоту. 3. Гыйльмүс сарф — морфология.
**Саттар** *г.* 1. Яклаучы, гафу итүче (Аллаһының эпитеты). 2. Ир җенесе ят кешенең бусагасыннан атлап кергәнче «йә саттарүн» дип әйтә. Бу хатын-кызлар яшеренеп өлгерсеннәр өчен эшләнә.
**Сафа** *г.* Пакьлек, сафлык.
**Сафар** *г.* (Татар телендә «сәфәр»булып әйтелә). Ай исәбенә нигезләнгән һиҗри календареның икенче ае (29 көннән гыйбарәт).
**Сафия** *г.* Саф, пакь, ачык күңелле хатын-кыз.
**Сафсата** *г.* 1. Суфыйчылык. 2. Буш сүз.
**Сахиб** *г.* 1. Юлдаш, юлчы иптәш. 2. Дус, иптәш. 3. Хуҗа, ия.
**Сахра** *г.* Дала, кыр, чүл.
**Саяд** *г.* Аучы, тотучы.
**Саҗидә** *г.* Сәҗдә кылучы, башы белән җиргә кадәр бөгелеп гыйбадәт кылучы, кемнедер олылаучы хатын-кыз.
**Саһир** *г.* Уяу торучы, йокламаучы.
**Сибгать** *г.* (сабага) Төс, буяу, төсмер, бизәк. Холык, фикер.
**Силах** *г.* Кораллар, сугыш кораллары.

**Симия** *г.* 1. Магиягә, багучылыкка кагылышлы. 2. Билге, тамга.
**Сираҗ** *г.* Яктырткыч, яктылык бирүче, лампа.
**Сихри** *г.* Тылсымлы, магияле.
**Солых** *г.* Тынычлык, килешү.
**Сохбәт** *г.* Берәү белән сөйләшеп утыру, аралашу, дуслык.
**Сур** *г.* Быргы.
**Сурәт** *г.* 1. Сурәт, рәсем. 2. Күренеш, кыяфәт. 3. Сын, портрет.
**Суфый** *г.* Динле, изге булып күренергә тырышучы.
**Сыйга** *г.* Шәкел, форма.
**Сыйддикъ** *г.* Һәрвакыт дөресен генә сөйләүче, тугры кеше. **Әбү Бәкер сыйддикъ** — турылыклы, туры сүзле Әбу Бәкер.
**Сыйныф** *г.* Бүлем, бүлек. Төр, сорт. Класс.
**Сыйххәт** *г.* 1. Сәламәтлек, гигиена, саулык, исәнлек. 2. Дөреслек, чынлык, турылык.
**Сәбзә** *ф.* Яшел, яшел төстә. Яшеллек, яшелчә.
**Сәбил** *г.* Юл, олы юл.
**Сәваб** *г.* Савап, әҗер, бүләк, яхшы эш.
**Сәгадәт** *г.* Бәхет, уңыш, рәхәтлек.
**Сәгыйть** *г.* Бәхетле, уңышлы, рәхәтле.
**Сәд, сад** *ф.* Йөз саны.
**Сәд** *г.* Аркылыга салынган киртә, койма. Буа, плотина. **Сәддү Әсуан әл-гали** — Асуанның биек буасы яки плотинасы.
**Сәдакать** *г.* Тугрылык, дуслык.
**Сәйр** *г.* 1. Йөрү, хәрәкәт, марш. 2. Тәртип (үз-үзеңне тотыш).
**Сәйар** *г.* Һәрвакыт хәрәкәттә булучы, бик хәрәкәтчән.
**Сәйф** *г.* Кылыч.

**Сәйеат** *г.* Начар эшләр, бозык гамәлләр, гөнаһлар.
**Сәях** *г.* Сәяхәт итүче, турист.
**Сәкинә** *г.* Тынлык, тынычлык.
**Сәкран** *г.* Эчкече, исерек.
**Сәлби** *г.* Кире, тискәре, кире кагылган. Пассив.
**Сәлимә** *г.* 1. Сәламәт, нормаль, тулы. 2. Чын, ясалма түгел, ирекле, ихлас.
**Сәлсәбил** *г.* 1. Җәннәттәге чишмә. 2. Күчерелмә мәгънәдә *җәннәт эчемлеге* яки *бик тәмле* булып кулланыла.
**Сәмаә** *г.* Күк йөзе.
**Сәмән** *г.* Акча, бәя.
**Сәнә** *г.* Ел.
**Сәнәви** *г.* Еллык, бер еллык, һәр елны, ел саен.
**Сәраб** *ф.* 1. Рәшә. 2. Буш вәгъдәләр. 3. Чыганак; чишмә башланган урын, чишмә башы.
**Сәр анҗам** *ф.* Соңы, азагы, төгәлләү, тәмамлау, башкарып чыгу.
**Сәрвәр** *ф.* 1. Башлык, җитәкче. 2. Хуҗа, ия булучы.
**Сәрвәт, сәрәүәт** *г.* Байлык, хәзинә. **Сәрәүәтү әттабигыйә** — табигый байлыклар, казылма байлыклар.
**Сәргаскәр** *ф. г.* Гаскәр башлыгы. Хәрби җитәкче.
**Сәрдар** *ф.* Гаскәр башлыгы, башкомандующий.
**Сәригъ, сәриган** *г.* Ашыгычлык, ашыгу, бик тиз генә.
**Сәригыльфәһми** *г.* Тиз аңлаучан, үткен, зирәк кеше. Тиз отып алучы.
**Сәркәтиб** *ф. г.* (сәр + кәтәбә) Секретарь.
**Сәрләүхә** *ф. г.* (сәр + ләүхә) Китапның титул бите. Мәкалә исеме. Эпиграф.
**Сәрмая** *ф.* Капитал, акча, байлык, сәбәп.
**Сәрмәди** *ф.* Мәңгелек, үлемсезлек, иксез-чиксез.
**Сәрхуш** *ф.* 1. Эчкән, эчеп алган. 2. Күңелле, кәефле.

**Сәфир** *г.* Сәяхәт итүче, сәфәр китүче.
**Сәфийр** *г.* Илче, арадашчы. Бөек илчелек башлыгы.
**Сәфәр** *г.* Юлга чыгу, юл, сәфәр.
**Сәхабә** *г.* Мөхәммәт пәйгамбәрнең көрәштәшләре, фикердәшләре. (Сәхабә — иярү, иярүче...).
**Сәхи** *г.* Юмарт кеше.
**Сәхифә** *г.* 1. Бит (китап бите). 2. Газета, бюллетень.
**Сәхнә** *г.* 1. Савыт-саба, тәлинкә. 2. Сәхнә; йорт эче.
**Сәхтиян** *г.* Сафьян, нәфис күн.
**Сәхәр** *г.* 1. Таң ату, таң беленү. 2. Сәхәр вакыты.
**Сәясәт** *г.* 1. Идарә. 2. Политика. 3. Дипломатия.
**Сәүдәгәр** *ф.* Сәүдә, сату-алу белән шөгыльләнүче.
**Сәҗдә** *г.* Тезләнгән хәлдә башны идәнгә (намазлыкка) тидерү, сәҗдә кылу.
**Сөаль** *г.* 1. Сорау. 2. Үтенеч.
**Сөбханалла** *г.* Аллаһыга дан һәм мактау.
**Сөлес** *г.* 1. Өчтән бер. 2. Гарәп каллиграфиясенең язу төре.
**Сөләм** *г.* Баскыч. Күчерелмә мәгънәдә *берәр максатка ирешү чарасын* белдерә.
**Сөнбел** *г.* 1. Башак. 2. Чәчәк, лалә чәчәге.
**Сөннә** *г.* 1. Йола, практика. 2. Әһлес сөннә — сөнниләр.
**Сөнниләр** *г.* Мөхәммәт пәйгамбәрнең хәдисләрен танучылар.
**Сөрьяни** *г.* Сүриялеләр. (Гарәпләр ассириялеләрне шулай атыйлар.)
**Сөрүр** *г.* Шатлык, куаныч, сөенеч.
**Сөфра** *г.* 1. Юлга ала торган ризык. 2. Аш өстәле.
**Сөһүләт** *г.* Җиңеллек, уңайлык.
**Сүзан** *г.* 1. Яндыручы, көйдерүче, кыздыручы. 2. Янучы, ут белән урап алынган, ялкын урап алган. 3. Зәһәр, көйдереп төбенә төшү.

**Сүрә** *г.* Коръәндәге бүлекләр «сүрәләр» дип аталалар. Бу изге китапта барлыгы 114 сүрә бар. Аларның һәркайсы аерым бер исем белән атала. Иң беренчесе — «Фәтихә» сүрәсе. Мөселманнар аны «Әлхәм» сүрәсе («әлхәмдү» сүзе белән башланганга) дип тә атап йөртәләр.

# Т

**Таб** *ф.* Куәт, хәл, көч.

**Табан** *ф.* Ялтыравыклы, нур чәчә торган. **Бәдритабан** — ай нуры, ай кебек нурлы.

**Табгыханә** *г. ф.* Басмаханә, типография.

**Табиб** *г.* Дәвалаучы, доктор.

**Табигать** *г.* 1. Тереклек дөньясы, табигать. 2. Табигый сыйфат, холык. 3. Табигый үзенчәлек.

**Табигъ** *г.* Басучы. Мөһер (пичәт, штемпель).

**Тавиль** *г.* 1. Озын, озын буйлы. 2. **Әссәбгут тыуалю** — Коръәндәге иң озын җиде сүрә (2—8).

**Тагать** *г.* 1. Тыңлаучанлык, буйсынучанлык. 2. Тәртип.

**Тазә** *ф.* Яшь, яңа, яңа гына...

**Тазыҗ** *г.* Яңа, саф, өр-яңа (*пешеп кенә чыккан, өлгереп кенә җиткән, иске түгел* мәгънәсендә).

**Таифә** *г.* Төркем, җәмәгать, бер диндәгеләр.

**Тайиб** *г.* Яхшы, әйбәт, сау-сәламәт, исән-сау.

**Тайар** *г.* 1. Очучы. 2. Тиз очып, таралып бетә торган.

**Тайәр** *ф.* Әзер, хәзер булу.
**Такать** *г.* Көч-куәт, чыдамлылык, түземлелек.
**Та ке** *ф.* -га кадәр, ... өчен дип.
**Такыя** *г.* Такыя. Кәләпүш, кырпу бүрек.
**Талак** *г.* 1. Ирекле, буш, ачык булу. 2. Хатын аеру.
**Талгать** *г.* Тышкы кыяфәт, күренеш, буй-сын, йөз-бит.
**Талиб, талип** *г.* Эзләүче, укучы, теләүче, таләп итүче.
**Талийга** *г.* 1. Алда булучы, алдынгы сафтагы. Авангард. 2. Пионерлар.
**Таләбә** *г.* Укучылар, студентлар, гыйлемгә омтылучылар.
**Тамаша** *ф.* Спектакль; карап тору, тамаша кылу, күреп тору.
**Танбур** *г.* 1. Кыллы уен коралы, гитара. 2. Техника өлкәсендә «барабан» һәм «цилиндр» мәгънәсендә кулланыла.
**Тараф** *г.* Тараф, як.
**Тарафдар** *г. ф.* Берәр якны яклаучы.
**Тарикать** *г.* Суфыйчылык юлы, суфыйлар тоткан юл.
**Тарикъ** *г.* Юл, ысул, метод.
**Тасвир** *г.* 1. Рәсем ясау. 2. Сурәт ясау, сурәтләп бирү.
**Тасдыйкъ** *г.* 1. Ышаныч. 2. Раслау, дөреслеген әйтү, тану. 3. Ратификацияләү.
**Тасныйф** *г.* 1. Бүлү, аерып кую, аерымлау, сортлау. 2. Әдәби әсәр.
**Тасриф** *г.* 1. Сарыф итү, сатып җибәрү. 2. Суны икенче якка борып җибәрү. 3. Үтәү, башкару. Гыйльмүт тасрыйф — сүзләрнең төрләнешен өйрәнә торган фән (морфология).
**Тасхих** *г.* Төзәтү, төзәтмә кертү, төгәллек кертү.
**Таҗ** *г.* Патшалар кия торган баш киеме (корона).
**Таҗетдин** *г.* Диннең таҗы.
**Таҗир** *г.* Сәүдәгәр, сатучы, купец.

**Таһарәт** *г.* 1. Пакьлек, сафлык, гөнаһсызлык. 2. Сөннәткә утырту.
**Таһир** *г.* Пакь, бозылмаган.
**Тимсаль** *г.* Скульптура әсәре, һәйкәл, монумент, статуя.
**Тимсах** *г.* Крокодил.
**Тирьйәк** *ф.* Әфьюн.
**Тиръйак** *ф.* Агуланута каршы кулланыла торган дару, дәва.
**Тиҗарәт** *г.* Сәүдә, сәүдә эше.
**Тофуләт** *г.* Сабыйлык, балалык, балачак.
**Туран** *ф.* Фарсы телендә төрки халыкларның аталышы.
**Туфан** *г.* Библиядә сөйләнелгән туфан (дөньяны су басу).
**Тыйб** *г.* Медицина.
**Тылсым** *г.* 1. Талисман. 2. Серле язу, бөти.
**Тәблигъ** *г.* Хәбәр итү, җиткерү, белдерү.
**Тәбрик** *г.* Бәхет, яхшы теләк теләү, котлау.
**Тәварих** *г.* Тарих сүзенең күплек сандагы шәкеле.
**Тәвәккәл** *г.* Таяну, ышану, тапшырылу. **Тәвәккәлтү галәллаһи** — үземне Аллаһыга ышанып тапшырдым. Аллаһыга тапшырдым.
**Тәвәҗҗеһ** *г.* (үәҗәһә) Кемгәдер эндәшү, мөрәҗәгать итү. Юнәлү, китеп бару, берәр тарафка таба хәрәкәт итү.
**Тәгаен, тәгайен** 1. *г.* Билгеләү, ачыклау, ачыклану. 2. Тәгәл генә билгеле булу. Тиешле булган нәрсә.
**Тәгалә** *г.* 1. Бөек булу, күтәрелү, югары булу. 2. Аллаһы тәгалә. Бөекләрнең бөеге.
**Тәгам** *г.* Ашамлык, азык-төлек, ризык.
**Тәгареф** *г.* Бер-берең белән танышу.
**Тәгъбир** *г.* 1. Бер мәгънәне белдергән әйтем, сүз, сүзтезмә. 2. Аңлатып бирү, ачыклау. Төш юрау.
**Тәгъбирнамә** *г.* Төш юрау китабы.

**Тәглиб** *г.* 1. Өстенлеккә ирешү, җиңү. Җиңәргә тырышу. 2. Басып алу. Мәгълүб — җиңелгән, тар-мар ителгән.

**Тәгъликъ** *г.* 1. Аңлату, төшендерү. 2. Тәфсилләп аңлату, комментарий бирү. 3. Кичектереп, туктатып тору. 4. Гарәп язуының төре.

**Тәгълимат** *г.* Күрсәтмәләр, кагыйдәләр, белемнәр. Белем юнәлеше.

**Тәгъриф** *г.* Таныштыру, белдерү, аныклау, шәрехләү.

**Тәгътыйль** *г.* 1. Туктатып кую, туктату. Ябып, бикләп кую. 2. Туктап тору. Эшсез тору. 3. Ял, каникул.

**Тәдбир** *г.* 1. Төзү, идарә итү, алып бару (хуҗалыкны, эшне.). 2. Тиешле чара, ысул, юл.

**Тәдрис** *г.* Дәрес бирү, укыту.

**Тәдриҗ** *г.* Әкренлек белән. Бит-тәдриҗ — әкренләп кенә.

**Тәзкирә** *г.* Искә алу, хәтерләү, истәлек дәфтәре.

**Тәкбир** *г.* 1. Зурайту, киңәйтү, көчәйтү. 2. Олылау, зурлау, мактау. Аллаһу Әкбәр — Аллаһ бөекләрнең иң бөеге.

**Тәкрар** *г.* Кабатлау, күп тапкырлар, еш кына булу.

**Тәкрим** *г.* Хөрмәт, ихтирам, олылау, зурлау.

**Тәкъва** *г.* Аллаһ юлында ихласлык белән хезмәт итүче, дин кушканнарны гына үтәүче. Аллаһыдан куркучы.

**Тәкъвим** *г.* 1. Төзәтү, төгәллек кертү. 2. Календарь.

**Тәкъдим** *г.* 1. Алга уздыру (берәр фикерне), мәсьәләне кую. 2. Тәкъдим итү, таныштыру.

**Тәкъдир** *г.* 1. Бәя бирү, бәя кую (эшләгән эшкә). 2. Язмыш.

**Тәкълид** *г.* 1. Иярү, охшатып эшләү. 2. Традиция, гадәт, йола.

**Тәкъсыйр** *г.* 1. Кыскарту, кечерәйтү. 2. Ашык-пошык кына эшләү, вакытны әрәмгә уздыру. Гөнаһлы булу.
**Тәкәббер** *г.* Үз-үзеңне әре тоту, һавалану.
**Тәкәллеф** *г.* 1. Ясалмалык, табигый булмаган кыланыш. 2. Тартыну, церемония.
**Тәкәммел** *г.* Камилләшкән булу, өлгереп җитү.
**Тәләффыз** *г.* Сүзнең әйтелеше, сүзне әйтү, сөйләү.
**Тәмамән** *г.* 1. Бөтенләе белән, тулысынча. 2. Азагы, соңы.
**Тәммуз** *г.* Июль ае.
**Тәммәт тәмам** *г.* Бетте, төгәлләнде, тәмам булды.
**Тәмсил** *г.* 1. Тамаша, уен. 2. Вәкиллек. 3. Охшату, чагыштыру. 4. Үзләштерү, йотылу, эреп бетү, ассимиляция.
**Тән** *ф.* Гәүдә, тән.
**Тәнвин** *г.* Гарәп телендә билгесез хәлдәге исемнең килеш кушымчалары (баш килештә «үн», иялек килешендә «ин», төшем килешендә «ән»).
**Тәнвир** *г.* 1. Яктырту, нурландыру. 2. Агарту, мәгърифәтле итү.
**Тәнзил** *г.* 1. Төшерү, түбәнгә төшерү. 2. Киметү, ташлама ясау.
**Тәнзыйм** *г.* 1. Тәртипкә китерү. 2. Оешканлык.
**Тәнкыйть** *г.* Кимчелекләрне күрсәтү.
**Тәнсиб** *г.* Ярашлы күрү, тигезләү, туганлашу.
**Тәнәффес** *г.* Сулыш алу, сулау, тын алу, ял итеп алу.
**Тәравих** *г.* Рамазан аенда көндәлек фарыз намазлардан тыш өстәмә рәвештә укыла торган намазлар (гыйбадәтләр).
**Тәранә** *ф.* Җыр, көй, аһәң.
**Тәрбия** *г.* 1. Үстерү, карап үстерү, үрчетү. 2. Үсеш. 3. Тәрбия, белем бирү. 4. Әдәплелек, тәрбиялелек.
**Тәрк** *г.* Калдыру, ташлау, ташлап китү.

**Тәркиб** *г.* 1. Җыю, монтажлау, кушу. 2. Төзелеш, сүз тезмәсе.
**Тәрмим** *г.* Төзәтү, төзекләндерү, сипләү.
**Тәрфигъ** *г.* Күтәрү, дәрәҗәне күтәрү.
**Тәрәддед** *г.* Икеләнү, бер карарга килмәү.
**Тәрәккый** *г.* Үсү, алга китү, прогресс.
**Тәрәккыят** *г.* Үсеш, алга китеш, югарыга менү, прогресска ирешү.
**Тәрҗеман** *г.* Тәрҗемәче, тылмач.
**Тәрҗемәи хәл** *г.* Биография.
**Тәрҗигъ** *г.* Кире бору, кире кайтару, кабатлау.
**Тәсаббер** *г.* 1. Сабырлык, чыдамлык күрсәтү. 2. Бар булганы белән килешү, ризалашу, юану, буйсыну.
**Тәсбих** *г.* 1. Мактау, олылау, дан җырлау. 2. Дисбе, тәсбих (җепкә тезелгән төймәләр).
**Тәслим** *г.* 1. Сәламләү. 2. Чигенү, юл бирү (берәр әштә). 3. Кулдан-кулга тапшыру, бирү. 4. Тотып бирү, тапшыру (дошманны). 5. Дошманга бирелү. 6. Тану, бирелү. 7. Әттәслиму — азаннан соң әйтелә торган чакыру, өндәү (намазга өндәү).
**Тәслия** *г.* Күңел ачу, юану, күңелне күтәрү.
**Тәсмия** *г.* Исем бирү, исем кушу, аталу.
**Тәсригъ** *г.* Тизләтү, ашыктыру, кызулату.
**Тәсҗил** *г.* Язып кую, теркәү, регистрация.
**Тәфсир** *г.* 1. Аңлату, үтемле итеп ачыклап бирү. 2. Мәгънә. Коръән сүрәләренең аңлатмасы, тәфсире.
**Тәфсыйль** *г.* 1. Сызым, өлге (кием өлгесе). 2. Җентекләп эчтәлеген аңлату.
**Тәфтиш** *г.* Тентү, тикшерү, ревизия ясау. Ил чиген узганда таможня тикшерүе.
**Тәфәһһем** *г.* Яхшы төшенү, белү, аңлау, үзләштерү.

**Тәхкыйк** *г.* 1. Үтәү, башкарып чыгу. 2. Тикшерү. 3. Өйрәнү, эзләнү.
**Тәхминән** *г.* Чама белән, чамалау, якынча бәяләү.
**Тәхсин** *г.* 1. Яхшылату, камилләшү. 2. Төзәтү.
**Тәхәммел** *г.* Күтәрә алу, өстеңә алу.
**Тәшвиш** *г.* 1. Бозылу, тәртипсезлек, буталу. 2. Шикләнү, курку. 3. Җенси авыру.
**Тәшкил** *г.* 1. Оештыру, төзү, формалаштыру. 2. Бер өлешенең бар булуы. 3. Оешма.
**Тәшәддед** *г.* Көчәю, куәтләнү, ныклык күрсәтү.
**Тәэмин** *г.* 1. Булдыру, җитештерү. 2. Тынычландыру, иминлек бирү.
**Тәэсир** *г.* 1. Йогынты ясау, тәэсир итү. 2. **Тәэсирүл гайн** — күз тидерү.
**Тәяммем** *г.* 1. Ниятләү, ният кылу, әзерләнү. 2. Су булмаганда, (кырда, далада, чүлдә) куллар белән җиргә (комга, туфракка) сугып тәһарәт йоласын башкару, тәяммем кылу.
**Тәүбә** г. Эшләгән гөнаһлар өчен тәүбә итү, кабат эшләмәскә ант итү.
**Тәүрат** *г.* Яһүдләрнең изге китабы. **Әһле тәүрат** — яһүдләр.
**Тәүсыя** *г.* 1. Васыять язып калдыру, васыять итү. 2. Киңәш итү, мәслихәт бирү.
**Тәүфыйк** *г.* 1. Килештерү, туры китерү, ярәштыру, ризалаштыру. 2. Тыйнак, әдәпле булу. 3. Ярдәм. 4. Уңыш, бәхет.
**Тәүхид** *г.* Берләшү, бер Аллага ышану.
**Тәҗвид** *г.* 1. Коръәнне көйләп уку. 2. Иң яхшысын сайлау, дөресен башкару.
**Тәҗрибә** *г.* 1. Сынап карау, тәҗрибә уздыру. 2. Тәҗрибә туплау.

**Тәһлил** *г.* «Лә иләһе илләл ләһ» (Аллаһыдан башка бөек көч юк) сүзләрен күп тапкырлар кабатлап әйтү.
**Төхфәт** *г.* 1. Бүләк. 2. Бик сирәк очрый торган, кадерле.
**Төхфәтулла** *г.* Аллаһының бүләге.
**Төһмәт** *г.* Шикләнү, гаеп ташлау, гаепләү.

# Ф

**Фагыйлиять** *г.* Эш. Тәэсир итү көче. Эшләнгән эшнең мәгънәсе.
**Фазыйл** *г.* Лаеклы, иң яхшы, иң шәп.
**Фаикъ** *г.* 1. Артык. Өстен тору, өстен булу. 2. Бик яхшы, шәп, искитәрлек. 3. Аек акыллы.
**Факиһә** *г.* 1. Җимеш. Җиләк-җимеш. 2. Күңел ачучы, наян туташ, ханым.
**Фал** *г.* 1. Яхшы киләчәк; киләчәкнең яхшы булачагын күрсәтүче бирәр күренеш, билге. 2. Яхшыга юрау.
**Фалиҗ** *г.* Паралич авыруы.
**Фани** *г.* 1. Иске, тузган, искергән. 2. Үтеп, узып китә торган, даими, мәңгелек түгел.
**Фараз** *г.* 1. Шулайдыр дип уйлау, фикер йөртү. 2. ... дип исәпләү, чама белән әйтү, фараз итү.
**Фаразан** *г.* -дыр дип исәпләгәндә, уйлаганда, фараз иткәндә; шулайдыр дип уйласак.
**Фарикъ** *г.* 1. Аерымлык. Аерма, төрлелек. 2. Аера белүче.
**Фарис** *г.* 1. Җайдак, атка атланган. 2. Фарсылар.
**Фарраш** *г.* 1. Хезмәтче, җыештыручы. 2. Каравылчы, сакчы.

**Фарук** *г.* Аера, таный белүче (яхшыны яманнан аеру).
**Фарыз** *г.* 1. Вазифа. Үтәлергә тиешле булган эш. 2. Һичшиксез башкарылырга тиешле бурыч, фарыз булган эш, кагыйдә.
**Фасикъ** *г.* 1. Бозык әхлаклы, юлдан язган. 2. Пычрак, начар гамәл кылучы, азгын кеше. Динсез.
**Фасыл** *г.* 1. Елның фасыллары (яз, җәй, көз, кыш). 2. Бүлек, өлеш.
**Фатих** *г.* 1. Ачучы, башлап җибәрүче. 2. Үз карамагына алучы, яулап, басып алучы. Яңа җир ачучы.
**Фатиха** *г.* 1. Коръәннең беренче сүрәсе. 2. Мәетнең рухына багышлап, фатихә сүрәсен укып дога кылу. 3. Дога уку, дога кылу.
**Фахиранә** *г. ф.* Мактанган кебек, мактанган сыман, шикелле.
**Фахиш** *г.* Бик начар, бозык кеше.
**Фаш** *ф.* Ачылу, мәгълүм булу, билгеле булу.
**Фаҗига** г. Зур бәхетсезлек, кайгы. Аянычлы вакыйга.
**Фида** *г.* 1. Котылу, тынычлык табу. 2. Корбан (итү).
**Фидаил, Фадаил** *г.* Яхшылык эшләүче, яхшы сыйфатлы, дәрәҗәле.
**Фидакяр** *г. ф.* 1. Үз-үзен аямыйча эшләүче. 2. Берәр максатка ирешү өчен үзен корбан итүче.
**Фидан** *г.* («фидаә» сүзенең төшем килешендәге шәкеле) Коткаручы. Максатына ирешү өчен җанын фида итәргә әзер булучы кеше.
**Фидия** *г.* 1. Йолым. 2. Корбан фидиясе. Гөнаһдан арыну өчен бирелә торган мал, йолым.
**Фикъһе** *г.* 1. Аңлау. Белем. 2. Мөселман кануннары. Ислам диненең кануннары, кагыйдәләре, хокук мәсьәләләре турындагы белем (фән).

**Филхакыйкать** *г.* Чынлыкта, чыннан да, дөресен генә әйткәндә.
**Филхаль** *г.* Шундук, шул ук вакытта, бик тиз.
**Фирак** *г.* 1. Аерылу, аерылышу. 2. Калдырып киту, китеп бару.
**Фиргавен** *г.* Борынгы Мисыр патшаларының исеме.
**Фирдәвес** *г.* Җәннәт бакчасы.
**Фирка** *г.* 1. Партия, төркем, труппа, команда. 2. Дини мәзһәб.
**Фируз** *ф.* Бәхетле. Өстенлеккә ирешүче кеше.
**Фитнә** *г.* 1. Күңел күзе белән карау, гашыйк булу, ошату. 2. Чуалыш, башбаштаклык, тәртипсезлек, җәнҗал. 3. Акылсызлык. Адашу, ышанмау.
**Форсат** *г.* 1. Уңайлы, җайлы очрак. 2. Эш вакытындагы өзеклек, эшсез тору, сулыш алу.
**Фәкать** *г.* Ялгыз, тик, бары тик.
**Фәкыйрь** *г.* Ярлы, ярлы кеше.
**Фәкыйрь-фокара** *г.* Ярлы-ябагайлар мәгънәсендә.
**Фәллах** *г.* Игенче, җир эшкәртүче, крәстиән.
**Фәлсәфи** *г.* Философик. Философиягә бәйләнешле.
**Фәләк** *г.* 1. Күк йөзе, күк гөмбәзе. 2. Астрономия.
**Фәлән** *г.* Теге, ни (билгеле, анык булмаган нәрсә турында сөйләгәндә кулланыла). *Фәлән-фәлән кеше, фәлән-төгән.*
**Фәнни** *г.* 1. Фән өлкәсенә караган. 2. Техника өлкәсе.
**Фәрекъ** *г.* 1. Аерымлык, үзгәлек, аерма. 2. Аеру, бүлү.
**Фәрзәнд** *ф.* Ир бала, угыл бала. Нәсел.
**Фәрид** *г.* Бердәнбер, тиңе булмаган.
**Фәрман** *г.* Боерык, күрсәтмә, кушу, әмер.
**Фәрсәх** *г.* Озынлык, ераклык (үлчәме).
**Фәрьяд, фөрьяд** *ф.* Кычкыру, акыру, ялвару, ялыну, зарлану.

**Фәрһәнг** *ф.* 1. Мәдәният, культура, цивилизация. 2. Сүзлек.

**Фәһем** *г.* Аңлау, төшенү.

**Фәһимә** *г.* 1. Аңлаучы; төшенә торган хатын-кыз. 2. Үткен, зиһенле, тапкыр.

# Х

**Хабгяһ** *ф.* Йоклау урыны, йокы бүлмәсе.

**Хадим** *г.* 1. Хезмәт итүче. 2. Хезмәтче, ялчы, хезмәткәр.

**Хадис** *г.* 1. Яңа, өр-яңа. 2. Сөйләшү. 3. Хикәя, вакыйга. 4. Хәдисе шәриф — бөек, олуг сүзләр (Мөхәммәт пәйгамбәрнең сөйләгәннәре һәм эшләгән эшләре турында).

**Хаин** *г.* Сатлыкҗан, хыянәтче.

**Хайвани** *г.* Хайван кебек, хайван белән бәйләнешле.

**Хак** *г.* 1. Дөрес, чын, гадел. 2. Хокук, гаделлек, дөреслек.

**Хаким, хәким** *г.* 1. Идарә итүче, хөкүмәтнеке. 2. Хәким, җитәкче, башлык, мөдир. 3. Хөкем итүче. Судья.

**Хакимият** *г.* Идарә итүче, җитәкче оешмалар.

**Хаккүл вәлидәйн** *г.* Ата-ана хакы.

**Хали** *г.* Буш, ирекле.

**Халикъ** *г.* Бар итүче, яратучы, бар кылучы.

**Халим** *г.* 1. Саф, пакь, чын, ихлас, ясалмалыктан азат булу. 2. Ирекле.

**Халисан** *г.* Саф, пакъ килеш, чын, ихлас, ирекле.

**Халиян** *г.* Хәзерге вакытта, нәкъ менә хәзер.

**Халәт** *г.* Хәл, рәвеш, торыш.

**Хамилә** *г.* 1. Күтәреп яки тартып баручы хатын-кыз. 2. Йөкле хатын.

**Ханә** *ф.* 1. Өй, йорт. 2. Сүз ясаучы кушымча — чәйханә, ашханә, шифаханә.

**Хариҗи** *г.* 1. Тышкы, тыштагы. 2. Чит, ят. 3. Чит илнеке.

**Хасид** *г.* Көнче, көнләшүче.

**Хасыйль** *г.* 1. Нәтиҗә. 2. Керем, файда. 3. Мәгънә. Барлыкка килү, хасил булу.

**Хатем** *г.* Имза урынына хатның азагында басыла торган тамга (пичәт).

**Хафиза** *г.* Саклый белүче, яттан белә торган хатын-кыз.

**Хач** *ф.* Тәре.

**Хаҗи** *г.* Мәккәгә барып хаҗ кылып кайткан кешегә әйтелә.

**Хаҗәт** *г.* 1. Кирәклелек, йомыш, хаҗәт. 2. Теләк. 3. Эш, кирәк нәрсә. 4. Берәр нәрсә, нәрсә дә булса.

**Хикмәт** *г.* 1. Акыллылык, зур акылга ия булу; философия. 2. Мәкаль. 3. Акылга нигезләп эшләү, мәгънәлелек. 4. Медицинаны, табиблык гыйлемен белү.

**Хилаф** *г.* Каршылык, аңлашылмаучылык, бәрелеш, фикерләрнең төрле якка аерылулары.

**Химая** *г.* 1. Берәр яклау астында булу, ярдәмне тоеп яшәү (рухи яки матди ярдәмне тою һ. б. ). 2. Кул астында булу (протекторат).

**Хинзир** *г.* Дуңгыз (дуңгыз ите).

**Хирыс** *г.* 1. Бик көчле, кайнар теләк белән омтылу, теләү. Теләк, омтылыш. 2. Саранлык, комсызлык. 3. Сакчыл, сак эш итүче.

**Хитаб** *г.* 1. Нотык сөйләү, чыгыш ясау, мөрәҗәгать итү. 2. Хат. Хат белән мөрәҗәгать итү.

**Хиҗаб** *г.* 1. Пәрдә, чаршау, өсьяпма (покрывало). 2. Бөти, амулет.

**Хиҗаз** *г.* Гарәбстан ярымутравындагы төбәк (өлкә).
**Хозур** *г.* 1. Катнашу, шунда булу. 2. Килү, килеп җитү, катнашу. 3. Әзер булу.
**Хокукшинас** *г. ф.* Кануннар белгече, юрист.
**Хоруфе шәмсия** *г.* Гарәп алфавитындагы ундүрт «кояш» хәрефенең атамасы. Мондый хәрефкә башланган сүзгә билгелелекне белдерүче «Әлиф», «Ләм» хәрефләреннән ясалган алкушымча кушылганда, аның беренче хәрефе икеләтеп укыла: сәгать — әссәгату, шәмс — әшшәмсү (кояш).
**Хоруфе монфасыйлә** *г.* Аерым языла торган хәрефләр. Алар гарәп язулы татар алфавитында барлыгы алты хәреф (әлиф, дәл, зәл, рә, зи, уау). Мондый хәрефләр бары уң якта гына тоташып язылырга мөмкиннәр, үзләреннән соң килүче хәрефләр белән беркайчан да тоташмыйлар.
**Хосус** *г.* 1. Үзенчәлек, аерымлык. 2. Мөнәсәбәт, очрак.
**Хосусән** *г.* Бигрәк тә, аеруча.
**Хотбә** *г.* 1. Мөнбәрдә басып чыгыш ясау, нотык сөйләү. 2. Никах вакытында укыла торган дога, вәгазь.
**Хуб** *ф.* Яхшы, матур, күркәм, гүзәл.
**Хури** *г.* Җәннәтнеке, җәннәт кызы.
**Хушбуй** *ф.* Ислемай, хуш исле.
**Хушдил** *ф.* Яхшы күңелле.
**Хушнәма** *ф.* Күркәм, матур.
**Хыялый** *г.* 1. Хыялга бәйләнешле, фантастика, күзаллау. 2. Фантазияле кеше.
**Хәбесханә** *г. ф.* Төрмә, тоткын урын, зиндан.
**Хәбиб** *г.* Сөекле, сөелгән, яраткан.
**Хәбибҗамал** *г.* Матурлыкны, гүзәллекне сөюче.
**Хәбибҗиһан** *г. ф.* Дөньяны яратучы, сөюче.
**Хәбәрдар** *г. ф.* Белүче; берәр эш, яңалык, вакыйга турында белү, белеп тору.
**Хәбәши** *г.* Эфиопияле.

Хәд *г.* 1. Чик кую, нокта кую, тәгәлләү. 2. Чик, кырый; үтәргә, узарга ярамый торган сызык, нокта. 3. -га, -гә кадәр.
Хәзинәдар *г. ф.* Казначы, баш кассир.
Хәзрәт *г.* 1. Әфәнде, ханым. Олылап мөрәҗәгать иткәндә, эндәшкәндә исем, титул алдыннан куеп әйтелә (хәзрәте Гали, хәзрәте Хәдичә).
Хәзиран *г.* Июнь ае.
Хәзәр диңгезе *төрк.* Каспий диңгезе.
Хәйдәр *г.* Арыслан.
Хәйләкяр *г. ф.* Хәйләгә оста кеше.
Хәйрият *г.* Яхшылык, изгелек (эшләү).
Хәлеб, Хәләб *г.* Сүриядәге шәһәр.
Хәлил *г.* 1. Сөекле кеше, сөяркә. 2. Дус, иптәш. Хәбибуллаһ — Аллаһының сөеклесе, дусты (Ибраһим галәйһис-сәлам).
Хәлид *г.* Мәңгелек, үлемсез.
Хәлял *г.* 1. Рөхсәт ителгән, кануни. 2. Тәртипле кеше.
Хәлял җефет *г. ф.* Никахлы хатын, хәләл пар.
Хәмди *г.* Мактаучы, рәхмәт укучы, зурлаучы.
Хәмед, Хәмид *г.* 1. Олылау, зурлау. 2. Канәгать булуны белдерү, шөкер итү. Әлхәмдү лиллаһи — Аллаһыга мактау, шөкер.
Хәмер *г.* Шәраб, исерткеч эчемлек.
Хәммаль *г.* Йөк ташучы.
Хәннан *г.* Миһербанлы, шәфкатьле, кызганучан, бик мәрхәмәтле.
Хәрабә *г.* Җимереклек, ватылган, җимерелгән.
Хәрам, хәрәм *г.* 1. Тыелган, тыюлы. 2. Изге. Бәйтүллаһил хәрам — Аллаһының тыелып тору йорты. Кәгъбә. 3. Канунсызлык, гөнаһлылык.
Хәрами *г.* Карак, угры.

**Хәрарәт мийзаны** *г.* Җылылык үлчәве; градусник, термометр.
**Хәраҗат** *г.* Чыгымнар, тотылган, сарыф ителгән акча яки мал.
**Хәрби** *г.* Хәрби, гаскәри. Сугыш белән бәйләнешле.
**Хәрдәл** *г.* Горчица.
**Хәридар** *ф.* Сатып алучы.
**Хәрикъ** *г.* Ут, янгын.
**Хәрир** *г.* Ефәк.
**Хәркъ** *г.* 1. Яндыру. 2. Төртеп яндыру.
**Хәсар, хәсарәт** *г.* 1. Югалту, зарар, зыян. 2. Һәлакәт, оттыру, югалту.
**Хәсис** *г.* Түбән җанлы, бозык, әшәке, кабахәт.
**Хәсрәт** *г.* Кайгы-хәсрәт, әрнү.
**Хәстә** *ф.* 1. Арыган, талчыккан. 2. Җәрәхәтле, авыру.
**Хәсән** *г.* 1. Матур, гүзәл. 2. Яхшы, игелекле.
**Хәтем ән-нәбийә** *г.* Пәйгамбәрләрнең соңгысы.
**Хәтим** *г.* Бик юмарт кеше.
**Хәттат** *г.* Матур язучы, каллиграф.
**Хәшиш** *г.* 1. Чүп үләне, печән. 2. Наркотик матдәле үсемлек.
**Хәшәрат** *г.* 1. Бөҗәкләр. 2. Җирәнгечләр, хәшәрәтләр.
**Хәят** *г.* Тормыш, тереклек.
**Хәятел хәяван** *г.* Хайваннар тереклеге, тормышы.
**Хәүф** *г.* Хәвеф, курку.
**Хәҗем** *г.* Үлчәм, күләм, зурлык.
**Хөкемдар** *г. ф.* Хөкем итүче, ил башы.
**Хөкемнамә** *г. ф.* Хөкем карары язылган дәфтәр, кәгазь.
**Хөр** *г.* Ирекле.
**Хөрсәнд** *ф.* Канәгать (булу).
**Хөсне тәрбия** *г.* Яхшы тәрбия.

**Хөсне хат** *г.* Матур язу, каллиграфия.
**Хөсни** *г.* Иң яхшы, иң күркәм.
**Хөҗрә** *г.* Кечкенә генә бүлмә.
**Хөҗҗәт** *г.* 1. Дәлил, раслаучы дәлил. Аклану өчен сәбәп. 2. Рәсми документ.

# Ч

**Чабук** *ф.* Тиз, йөгерек, хәрәкәтчән.
**Чап** *ф.* Сул тараф, сул як.
**Чапханә** *ф.* Матбугат йорты, басмаханә, нәшрият.
**Чапча, чапчи** *төрк.* Ялганчы, азгын, шарлатан.
**Чарводәр** *ф.* Терлек асраучылар, терлекчеләр.
**Чар-начар** *ф.* Теләр-теләмәс.
**Чарә** *ф.* Берәр халәттән чыгу юлы.
**Челлә** *ф.* 25 июньнән 5 августка кадәр кырык көн дәвам итә торган вакыт (эсселек).
**Чиаләк** *ф.* Җир җиләге, клубника.
**Чин** *ф.* Кытай.
**Чин вә ма Чин** *ф.* Кытай һәм Япония.
**Чит** *ф.* Ситсы (ситец тукыма).
**Чичәк** *ф.* Әспе авыруы.
**Чәрик** *ф.* Черек, черегән нәрсә.
**Чәмән** *ф.* Үсемлек, үлән.
**Чәмәнзар** *ф.* Болынлык.
**Чәнг** *ф.* Арфага охшаган уен коралы.
**Чәнгәл** *ф.* Урман.
**Чәнд** *ф.* Берникадәр, беркадәр, берничә, кайбер.

**Чәшем** *ф.* Күз.
**Чәшмә** *ф.* Чишмә, болак, кизләү.
**Чаһрә, чәһрә** *ф.* Төс, йөз, кыяфәт. Гөлчәһрә — гөлгә охшаш, гөлгә тиң, гөл йөзле.
**Чәһаршәмбе** *ф.* Чәршәмбе. Атнаның дүртенче көне.
**Чәһәл** *ф.* Кырык саны.
**Чәһәлсотун** *ф.* Колонналы йорт. Исфаһан шәһәрендәге Шаһ Габбасның йорты («кырык колонналы, баганалы» дип тәрҗемә ителә).

## Ш

**Шагыйранә** *г. ф.* Шагыйрьләрчә, шигъри итеп.
**Шадия** *ф.* Шат, күтәренке күңелле.
**Шадман** *ф.* Шатлыклы, күңелле. Шатландыручы.
**Шайистә** *ф.* Лаек, ярашлы, ярый торган, кабул ителерлек.
**Шакир** *г.* Рәхмәт әйтүче, рәхмәтле кеше. Канәгатьлек белән рәхмәт әйтүче, шөкер кылучы.
**Шам** *г.* Сүрия. Бәләдү Шам — Сүриянең гарәпчә исеме.
**Шамил** *г.* Барысын да туплаган, колачлаган, универсаль.
**Шан** *ф.* Дан. Шанлы — данлы.
**Шаһид** *г.* Берәр эшнең шаһиты, күреп калучы.
**Шаһиншаһ** *ф.* Иран шаһларының титулы. Шаһларның шаһы.
**Шаһнамә** *ф.* Патшалар турындагы китап. Әбүлкасыйм Фирдәүсинең шул исемдәге поэмасы.
**Шивә** *ф.* Җирле сөйләм, диалект.
**Шигарь** *г.* Өндәмә, лозунг, байрак.

**Шигый** *г.* Ислам динендәге мәзһәб, юнәлеш. Бу юнәлешкә Гали хәзрәт нигез салган дип исәпләнә.
**Шиддәт** *г.* Көч, куәт, ныклылык, көчлелек.
**Шикасте** *ф.* Сынык, җимерек. Фарсы язуының бер төре.
**Шикаять** *г.* Нәрсәгәдер зарлану, сукрану. Берәүгә зарлану, канәгатьсезлек белдерү. Жалоба.
**Шималь** *г.* Төньяк.
**Шинас** *ф.* Белгеч, оста.
**Шир** *ф.* Арыслан.
**Ширкәт** *г.* Оешма, берләшмә, катнашу.
**Ширр** *г.* Усаллык, явызлык.
**Шифаһия** *г.* Телдән сөйләнгән.
**Шәмаил** *г.* 1. Тумыштан булган сыйфат, холык, яхшы холык. 2. Рам эченә куелган дини эчтәлекле текст яисә изге урыннарның рәсеме.
**Шәкел** *г.* Шәкел, форма, вариант.
**Шәмгъ** *г.* 1. Балавыз. 2. Шәм.
**Шәмес** *г.* Кояш.
**Шәмсия** *г.* 1. Кояштан ышыклану әйбере (зонт), тукымадан корып куелган ышыклану гөмбәзе, ышыклану урыны. 2. Кояш йөзле.
**Шәмшад** *ф.* 1. Һәрвакыт яшел, һәрвакыт яз. 2. «Әлиф» хәрефе кебек туп-туры тору.
**Шәмшир** *ф.* Кылыч.
**Шәраб** *г.* 1. Эчемлек; баллы, татлы эчемлек. 2. Исерткеч эчемлек (вино).
**Шәргый** *г.* Кануннар, кагыйдәләр. Шәригать кануннары.
**Шәрех** *г.* Аңлатма, комментарий.
**Шәрик** *г.* Иптәш, компаньон, берәр эшне бергә башкаручы.
**Шәрир** *г.* Усал, бик явыз, талаучы, явызлык эшләүче.
**Шәриф** *г.* 1. Танылган, данлыклы, билгеле, кадерле.

2. Зыялы, яхшы, олы җанлы, намуслы, пакь. 3. Пәйгамбәр нәселеннән булганнарның исемнәреннән соң әйтелә торган титул.

**Шәркый** *г.* 1. Көнчыгышныкы, көнчыгыш белән бәйләнешле. 2. Көнчыгыш кешесе.

**Шәрмәндә** *ф.* 1. Оялучан, оятны белүче. 2. Оят, хурлык.

**Шәрык** *г.* Көнчыгыш.

**Шәрәф** *г.* 1. Кадер, хөрмәт, дан. 2. Затлы нәселдән булу, дәрәҗәлелек, аксөяклек. 3. Югары дәрәҗә.

**Шәтранҗ** *ф.* Шахмат уены.

**Шәфагать** *г.* Ярдәмлекле булу, ярдәмчеллек, арадашчылык, берәр эштә, тормышта таяныч булу, булышлык күрсәтү.

**Шәфигаль өммәт** *г.* Өммәтенең яклаучысы, сакчысы.

**Шәфикъ** *г.* Шәфкатьле, мәрхәмәтле.

**Шәфәкъваш** *г. ф.* Шәфәкъ яктылыгы кебек, кызыл.

**Шәфталу** *ф.* Шәфтал җимеше (персик).

**Шәфәкъ** *г.* Күк йөзендәге кичке кызыллык (кояш батыр алдыннан була торган күктәге кызыллык).

**Шәхсый** *г.* 1. Үзеңнеке генә..., персональ. 2. Сөйләгәндә *менә мин үзем, мин үзем исә, шәхсән мин үзем* мәгънәсендә кулланыла.

**Шәүәл, шәүвәл** *г.* Һиҗри календарьның унынчы ае.

**Шәүкъ** *г.* 1. Дәрт, көчле теләк. 2. Сагыну, юксыну.

**Шәүкәт** *г.* 1. Көч, куәт, дан, бөеклек, шөһрәт. 2. Чәнечкеле, очлы. Инә. 3. Чәнечке.

**Шәҗәгать** *г.* Батырлык, кыюлык, куркусызлык.

**Шәҗәрә** *г.* 1. Агач, куак. 2. Нәсел-ыругның тамырларын күрсәтүче схема. Нәсел агачы.

**Шәһадәт** *г.* 1. Таныклык бирү, күрсәтү. 2. Аттестат, диплом. 3. Шәһит булу, кеше кулыннан шәһит булу, үтерелү. 4. Куркынычлык янаганда «лә илаһе илләллаһи үә

**Мөхәммәдүр-рәсүлүллаһ»** — Аллаһыдан башка бөек көч иясе юк һәм Мөхәммәт — Аллаһының илчесе дип таныклык бирү.

**Шәһадәтнамә** *г. ф.* Таныклык язуы, мәктәпне тәмамлаганлык турында аттестат. Диплом.

**Шәһрияр** *ф.* Патша, мәлик, монарх, дәүләт башлыгы.

**Шөбат** *г.* Сирйани календареның ай исеме (февраль).

**Шөбһә** *г.* Икеләнү, шөбһәләнү, шикләнү.

**Шөгъбә** *г.* 1. Бүлек, тармак. 2. Бүлекчә, филиал.

**Шөһрәт** *г.* 1. Танылу, атказану, дан алу. 2. Яхшы яисә яман, начар сыйфат белән танылу, яманатлы булу, дан чыгу. 3. Шәһийр, мәшһүр (билгеле, танылган) сүзләре дә бер үк тамырдан ясалганнар.

**Шүрчәшм** *ф.* Каты күзле кеше, күзе тия торган кеше, начар, усал күзле кеше.

## Ә

«Әлиф» хәрефе иске татар язуында «А», «Ә», «Э», «О», «И» хәрефләрен ясауда катнаша.

**Әбүаб** *г.* («баб» сүзенең күплек сан шәкеле) 1. Ишекләр, керү урыннары. 2. Бүлекләр, өлешләр.

**Әбләһ** *г.* Ахмак, җүләр.

**Әбәд** *г.* Мәңге, соңы булмаган, мәңгелек.

**Әбҗәд** *г.* Гарәп язуында хәрефләр саннарны да белдерә. Мондый хәрефләр шартлы рәвештә сигез сүзгә берләштерелгәннәр. Әбҗәд шуларның беренчесе (Ә — 1, Би — 2, Җим — 3, Дәл — 4 һ. б. ).

**Әварә** *ф.* 1. Йорт-җиреннән аерылып чит җирләрдә (зимагурлыкта) йөрүче. 2. Берәр эш белән мавыгу.
**Әгузе** *г.* Ярдәм, яклау сорап ялвару, сыену.
**Әгъдад** *г.* Саннар.
**Әгъзам** *г.* Бик бөек, иң зур, иң мөһим.
**Әгъла** *г.* 1. Иң бөек, иң югары. 2. Бик югары, дәрәҗәле.
**Әгъләм** *г.* Шәригать кануннарын белүче зур галим.
**Әдвар** *г.* Дәверләр, заманалар.
**Әдиб** *г.* 1. Тәрбияле. 2. Мәгърифәтле, укымышлы.
**Әзәл** *г.* Мәңгелек, башлангычы булмаган заман.
**Әзһәр** *г.* Ялтыравыклы, күз явын алырлык якты, ачык.
**Әкабир** *г.* 1. Иң бөек, иң зурлар. 2. Мөһим(нәр). 3. Өлкәннәр, олылар, зурлар.
**Әкалим** *г.* 1. Пояслар, өлкәләр, районнар. 2. Климат.
**Әкъваль** *г.* Әйткәннәр, әйтелгәннәр... Әйтемнәр.
**Әкъдәм** *г.* Иң борынгы, иң әүвәлге, элеккерәк.
**Әкърибаә** *г.* Туганнар, якыннар, якын кешеләр.
**Әлвидаг** *г.* Саубуллашу, аерылу, озату.
**Әлкыйсса** *г.* Сөйләү, хикәяләү. Риваятьләр, экиятләр башында языла торган сүз (*сөйләнелә, сөйлиләр, сөйләүләренчә* мәгънәсендә кулланыла).
**Әллисанү йәһликүл инсанә** *г.* Тел кешене һәлак итә.
**Әлфирак** *г.* Аерылышу, китеп бару, китү.
**Әлхасыйль** *г.* Нәтиҗә; җыеп, йомгаклап әйткәндә, кыскасы.
**Әманәт** *г.* 1. Ышанычлылык, бирелгәнлек, намуслылык. 2. Мираска калган берәр әйбер, мал. 3. Сакларга бирелгән әйбер.
**Әмер** *г.* Эш, хәл, халәт, мәсьәлә.
**Әмир** *г.* 1. Башлык, җитәкче. 2. Кенәз, принц.
**Әмира** *г.* Принцесса.

**Əмирал** *г.* Адмирал.
**Əмиранə** *г.* Патшаларча, патшаларга хас сыйфатлар белəн, ханнар кебек, шикелле.
**Əмма бəгъд** *г.* Шуннан соң, ... һəм шулай итеп.
**Əмр** *г.* Боерык, күрсəтмə бирү, кушу.
**Əмсаль** *г.* 1. Мисаллар, үрнəклəр. 2. Шуның кебеклəр, шундыйлар. 3. Мəсəллəр.
**Əнвəр** *г.* Иң якты, бик нурлы.
**Əнгам** *г.* Хайваннар.
**Əндазə** *ф.* Күлəм, үлчəм, калып.
**Əндишə** *ф.* 1. Уй, төшенчə. 2. Шиклəнү, борчылу, шөбһəлəнү. 3. Кайгы-хəсрəт.
**Əнсар** *г.* 1. Ярдəм итүчелəр, ярдəмчелəр, көрəшчелəр, яклылар. 2. Мөхəммəт пəйгамбəрнең Мəккə шəһəрендəге ярдəмчелəре.
**Əнтə бəдрүн** *г.* Тулган ай син.
**Əнтə нурүн фəүка нур** *г.* Нур өстендəге нур син.
**Əрбаб** *г.* 1. Раббе сүзенең күплек сан шəкеле. 2. Башлыклар, хуҗалар, җитəкчелəр. 3. **Əрбабе калəм** — калəм əһеллəре, язучылар.
**Əрвах** *г.* Рухлар, җаннар.
**Əрхəм** *г.* Иң мəрхəмəтле, иң шəфкатьле, иң миһербанлы.
**Əрхəмəррахимийн** *г.* Иң шəфкатьле һəм миһербанлыларның да шəфкатьлерəге.
**Əсас** *г.* Нигез, төп, фундамент.
**Əсбаб** *г.* 1. Сəбəплəр. 2. Юл, чара, ысул, җай.
**Əсир** *г.* Кулга алынган, əсир, тоткын.
**Əсрар** *г.* Серлəр.
**Əссəламү галəйкүм** *г.* Сезгə тынычлык, иминлек булсын.
**Əстəгъфируллаһ** *г.* Аллаһ, үзең сакла.
**Əсəд** *г.* Арыслан.

**Әтраф** *г.* 1. Карашлар, әйләнә-тирә. 2. Күзләр. 3. Азак, кырый, очы-кырые.
**Әттәхият** *г.* 1. Котлау, тәбрикләү. 2. Сәлам бирү. Тезләнеп баш ию.
**Әтфаль** *г.* Сабыйлар, балалар.
**Әфзаль, Әфдаль** *г.* Иң яхшы.
**Әфзун** *г.* Күп, бик күп, артык күп.
**Әфкяр** *г.* Уйлар, фикерләр.
**Әхбаб** *г.* Сөекләләр, дуслар, ярлар.
**Әхбар** *г.* Хәбәрләр.
**Әхбәс** *г.* Иң әшәке, начар.
**Әхкям** *г.* Кануннар, боерыклар.
**Әхмар** *г.* Кызыл (төс).
**Әхтар** *ф.* Йолдыз.
**Әшкярә** *ф.* Ачыклану, ачылу, яшермәстән әйтү, ачыктан-ачык.
**Әшрәфәл бәдрү** *г.* Иң якты, тулган ай.
**Әшәддә** *г.* 1. Бик көчле, бигрәк тә, бик каты. 2. Аеруча, бик куәтле, бик нык.
**Әшуфтә** *ф.* 1. Дулкынланган, борчылган. 2. Гашыйк булган.
**Әүлия** *г.* Изгеләр, яхшылык эшләүчеләр.
**Әҗер** *г.* 1. Бер эш өчен бирелгән хак, түләү. 2. Савап.
**Әҗмәгыйн** *г.* Барысы да, барысы бергәлектә.
**Әҗнәби** *г.* Чит, ят. Чит ил кешесе.
**Әҗәл** *г.* Соңгы чик. Үлем вакыты.
**Әһел** *г.* Кеше, хуҗа, халык.
**Әһле ислам** *г.* Мөселманнар.
**Әһле китап** *г.* Тәүрат, Инҗил, Коръән китапларының кайсына булса да иярүчеләр.
**Әһлән вә сәһлән** *г.* Хуш киләсез, рәхим итегез.

# Ө

**Өлфәт** *г.* 1. Килешеп яшәү, бердәмлек. 2. Дуслык, ярату, мәхәббәт.
**Өлүф** *г.* Меңнәр.
**Өмид** *ф.* Өмет, өметләнү, ышаныч баглау.
**Өмиддар** *ф.* Өметле, өмет тотучы, ышанган.
**Өммүн** *г.* Ана, әни.
**Өммәт** *г.* 1. Милләт, халык. **Әбнәәүл уммә** — ватандашлар. 2. **Уммәтү, өммәтү Мухаммәд** — Мөхәммәт өммәте, мөселманнар. 3. **Җәмгыятүл умәми** — Милләтләр оешмасы. **Муназзамәт умәмил мөттәхидә** — Берләшкән Милләтләр Оешмасы.
**Өммәһат** *г.* Аналар, әниләр.
**Өмур, умур** *г.* Эшләр, гамәлләр, хәлләр, мәсъәләләр.
**Өмуре зарурия** *г.* Кирәкле, зарур булган эшләр.
**Өмараэ** *г.* Башлыклар, патшалар, әмирләр.
**Өнса** *г.* Хатын-кыз.
**Өстад, устад** *г.* 1. Укытучы, остаз. 2. Профессор. 3. Оста, өйрәтүче. Маһир кеше.
**Өсараэ** *г.* Әсирләр, тоткыннар.
**Өҗур** *г.* Әҗерләр, саваплар, яхшы эшләр.

# Җ

**Җабир** *г.* 1. Каймыккан яисә урыныннан чыккан кул-аякларны утыртучы. 2. Җәберләүче, кыерсытучы, тиран.
**Җавабе катгый** *г.* Кискен җавап, өздереп әйтү.

Җавабнамә *г. ф.* Җавап хаты.
Җавабән *г.* Җавап итеп, җавап буларак.
Җавид *ф.* Мәңге, мәңгелек.
Җаду *ф.* Сихерче, күз буучы, күрәзәче.
Җазибә *г.* Үзенә тартучы, җәлеп итүче, яраттыра торган.
Җамигъ *г.* Җыючы, күп халык сыйдыра ала торган җамигъ мәчет.
Җаниб *г.* Як, тараф.
Җар *г.* Күрше, янәшә торучы.
Җария *г.* 1. Коллыктагы хатын-кыз. 2. Хезмәтче хатын-кыз. 3. Кыз кеше.
Җасус *г.* Шымчы, шпион, эзәрлекләп йөрүче.
Җаһил *г.* 1. Бернәрсәдән хәбәре булмаган, тупас, надан кеше. 2. Ахмак, белемсез, караңгы кеше.
Җефет *ф.* Җөп, пар.
Җигәр, җегәр *ф.* Бавыр.
Җидди *г.* Җитди, мөһим дип карау.
Җилд *г.* 1. Тире. 2. Төпләнгән китап. 3. Китапның бер бүлеге, өлеше.
Җисем *г.* 1. Бәдән, тән. 2. Җисем, тышча (корпус).
Җиһад *г.* Көрәш. Җиһад фи сәбийлид дин — Дин өчен сугыш.
Җиһан *ф.* Дөнья, галәм.
Җиһангир *ф.* Дөньяга ия булучы, дөнья хуҗасы.
Җиһәт *г.* Як, тараф, юнәлеш.
Җәббар *г.* 1. Бик көчле, куәтле, зур көчкә ия булучы, тиран.
Җәбраил *г.* Җәбраил фәрештә. Аллаһ белән Пәйгамбәр арасындагы арадашчы, Аллаһының вәхиләрен пәйгамбәргә ирештерүче.
Җәбәли *г.* Таулы, таугa бәйләнешле.

**Җәбәрут** г. Көч, куәт, бөек көч.
**Җәвад** *г.* 1. Киң күңелле, олы җанлы, юмарт кеше. 2. Аргамак, нәселле ат.
**Җәван** *ф.* Яшь кеше, яшь егет.
**Җәванмәрд** *ф.* 1. Олы җанлы, затлы, киң күңелле кеше. 2. Батыр, курку белмәс кеше.
**Җәдвәл** *г.* Таблица, схема.
**Җәдид** *г.* Яңа, яңалык.
**Җәдир** *г.* Лаеклы, игътибарга лаек.
**Җәдирүн биззикр** *г.* Искә алырга, әйтеп үтәргә лаек булган, игътибарга лаек булган.
**Җәззар** *г.* Ит чабучы, ит тураучы, сугымчы.
**Җәзибәле** *г.* Үзенә тартучан, җәлеп итүчән. Тарту көче, матурлык.
**Җәйш** *г.* Гаскәр, армия.
**Җәйхун** *г.* Амударья елгасының гарәпчә исеме.
**Җәлеб** *г.* 1. Китерү, алып килү, китереп җиткерү. 2. Җәлеп итү, карату, кызыктыру, тарту.
**Җәлил** *г.* 1. Зур, дәү, бөек, мөһим. 2. Мәһабәтле, данлы, атаклы. 3. Танылган, мөхтәрәм.
**Җәлляд** *г.* 1. Баш кисүче, палач. 2. Тире белән сәүдә итүче.
**Җәлсә** *г.* Утырыш, мәҗлес.
**Җәлял** *г.* Бөеклек, олылык.
**Җәмал** *г.* Матурлык, гүзәллек, күркәмлек.
**Җәмәгать** *г.* 1. Җыелган халык төркеме. Берләшмә. 2. Гаилә, хатын.
**Җәмгъ, җәмгысы** *г.* 1. Җыю, туплау. 2. Барлыгы, барысы бергә.
**Җәмгыяте хәйрия** *г.* Ярдәм итүче, яхшы эшләр башкаручы оешма.

**Җәнаб** *г.* Кешенең исеменә кушып әйтелә торган хөрмәтләү сүзе. **Җәнабе гали, яисә галиҗәнаб** — олы зат, асыл зат, зыялы мәгънәсендә кулланыла.
**Җеназа** *г.* 1. Күмү, үлгән кешене җиргә иңдерү вакыты. Салатүл җеназа — мәеткә җеназа уку. 2. Мәетне алып бара торган җайланма, катафалк.
**Җәнах, җүнах** *г.* Канат.
**Җәнк, җәнг** *г.* Сугыш-кырылыш. Бәрелеш.
**Җәнүб** *г.* Көньяк.
**Җәнҗал** *ф.* Гауга, шау-шу.
**Җәрахәт, җәрәхәт** *г.* Яра.
**Җәридә** *г.* Гәҗит.
**Җәримә** *г.* Начар, гөнаһлы эш; җинаять.
**Җәсарәт** *г.* Батырлык, куркусызлык, йөрәклелек, егетлек.
**Җәсур** *г.* Батыр, курку белмәс.
**Җәсәд** *г.* Гәүдә.
**Җәүһәр** *г.* 1. Асыл, төп яратылыш, әйбер, материя. 2. Кыйммәтле таш. Кыйммәтле әйбер. Бу сүз инглиз теленә гарәп теленнән үтеп кергән һәм «җевелләри» дип әйтелә, урыс телендә — «ювелирия».
**Җәүһәрфруш** *г. ф.* Кыйммәтле ташлар белән сәүдә итүче.
**Җәһәннәм** *г.* Тәмуг.
**Җәһәт** *г.* Як, тараф.
**Җөббә** *г.* Киң җиңле озын күлмәк (ирләр күлмәге).
**Җөзъи** *г.* 1. Өлеш, кисәк. 2. Вак, кечкенә. Коръәннең утыздан бер өлеше.
**Җөзьүн лә йәтәҗәззә** *г.* Бүленми торган бер бөтен. Аерылмый торган бер бөтен.
**Җөлүс** *г.* Утырулар, утырышулар.

Учебное издание

Джамиль Габдулхакович Зайнуллин

СЛОВАРЬ АРАБО-ПЕРСИДСКИХ ЗАИМСТВОВАНИЙ

Редакция мөдире Р. И. Раскулова
Редакторы Г. Г. Шәрифуллина
Бизәлеш редакторы Л. С. Золондинова
Тышлык рәссамы Д. Н. Җәләлетдинов
Техник редакторы Н. Х. Гомәрбаева
Компьютерда Г. Г. Шәйхетдинова эшләде
Корректоры Р. С. Хәмидуллина

ИБ № 220

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 23.11.94. Форматы 60×90 1/32.
Офсет кәгазе № 2. «Академическая» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 4,5. Шартлы буяу-оттиск 9,25.
Нәшер-хисап табагы 5,59. Тиражы 17 700 данә.
Заказ А-322. С-81.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Издательство «Магариф». 420111. Казань, ул. Баумана, 19.

Татарстан газета-журналлар нәшрияты типографиясе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.